А. Г. ЯХИН

Әдәбият

7

А. Г. ЯХИН Әдәбият 7

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

7

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

ХОЛЫКЛАР ОХШАШЛЫГЫ

ПРОБЛЕМА
ЖАНЫҢ НИ ТЕЛИ?!

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
7 нче сыйныфы өчен дәреслек

Яңадан эшләнгән өченче басма

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
рөхсәте белән басыла

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2006

УДК 373.167.1 : 821.512.145*07
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Я89

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

УКЫТУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Шушы дәреслек белән эшләү өчен, А. Г. Яхинның «7 нче сыйныфта әдәбият дәресләре: Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

«Мәгариф» нәшрияты чыгарган методик кулланмаларны сатып алу өчен, түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итегез:

420111. Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. «Мәгариф» нәшрияты.
Телефоннар: 292-60-19, 292-39-14.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 7 нче с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— Яңадан эшләнгән өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2006.— 255 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1042-4

ISBN 5-7761-1042-4

© «Мәгариф» нәшрияты, 2006, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

КЕРЕШ

Дәреслеккә ике тема керде. Берсе — **әдәби жанрлар.**

Искә төшерик. Әдәби әсәрләр искиткеч күп. Фән андый күплекне бик яратып бетерми, охшаш сыйфатларын таба да, гомумиләштерә-гомумиләштерә, мөмкин кадәр азга калдырырга тырыша. Әдәби жанрлар да шулай барлыкка килгән.

> Жанр эченә кергән әсәрләрнең, ким дигәндә, ике-өч бик җитди охшаш сыйфатлары бар. Әнә шул охшаш сыйфатларга **жанрның үзенчәлеге** диләр.

7 нче сыйныфта да күп санлы әсәрләр белән танышачакбыз. Аларга анализ ясауны дәвам итәчәкбез. Ләкин быел безне беренче чиратта аларның охшаш сыйфатлары кызыксындырачак.

Әдәби жанрларны өйрәнү нигә кирәк?

Жанрлар эченә охшаш әсәрләр керә, дидек. Шулай булгач, бериш әсәрләргә анализны бер үк ысуллар белән ясап була дигән сүз. Димәк, жанр үзенчәлекләрен белү безнең эшне бик нык җиңеләйтәчәк.

Дәреслекнең икенче зур темасы — **язучы иҗаты.**

Жанр үзенчәлекләре бик борынгы заманда ук табылган. Ә язучы иҗатының үзенчәлеген табу тулысынча безнең фәнни эш нәтиҗәсе булачак.

Әдипләрнең үзләре яратып яза торган жанрлары була. Берәүләр лирик шигырьләр язарга ярата. Андый әдипләргә **шагыйрь** диләр. Ә кайбер әдип гомере буена драма әсәрләренә тугрылыклы булып кала. Аларны **драматург**, ә чәчмә әсәрләр язучыларны **прозаик**, диләр.

Язучы иҗатының бу үзенчәлеге бик җиңел табыла. Мәсәлән, Хәсән Туфан — шагыйрь, Галимҗан Ибраһимов — прозаик, Туфан Миңнуллин — драматург, дибез.

Ләкин быелгы уку елында безне әдипнең башкаларга охшамаган үз табышлары кызыксындырачак.

Әдипләр үзләре яраткан жанрның кагыйдәләренә буйсынып иҗат итәләр. Ләкин шул ук вакытта әсәрләрен башка әдипләр язган

әсәрләргә охшатмаска тырышалар. Чыннан да, барысы да бертөрле язсалар, аларның әсәрләрен берәү дә укымас иде.

Өстәвенә әдипләр үз әсәрләрен дә берсе икенчесенә охшамаслык итеп иҗат итәләр. Ләкин алай да язучының үзе белгән һәм яраткан темасы, кабат-кабат файдалана торган сурәтләү чаралары була. Быелгы уку елында без, аерым әдипләрнең берничә әсәренә анализ ясап, ул әсәрләрнең охшаш сыйфатларын табарбыз. Әнә шул уртак сыйфатларга **язучы иҗатының үзенчәлеге** диячәкбез.

Шушы эшне башкарганда гына без, язучы иҗатына дөрес бәя биреп, аның татар әдәбиятында тоткан урынын билгели алачакбыз. Өстәвенә язучылар иҗатын берәм-берәм өйрәнми торып, әдәбият тарихын күз алдына китерү мөмкин түгел.

Сезнең кулда, хөрмәтле укучылар, менә шундый бик мөһим ике темага багышланган дәреслек. Аңа татар халкының берсеннән-берсе кызыклы әкиятләре, мәзәкләре, гыйбрәтле мәкаль-әйтемнәре, күренекле язучыларның әсәрләре керде. Сез аларны яратып укырсыз дип ышанабыз. Дәреслек сезне уйларга, әсәргә анализ ясарга, иҗат итәргә, матурлыкны күрә белергә өйрәтер.

Әдәбият дәреслекләренең һәркайсы алдагы сыйныф дәреслекләренә бәйләнешле итеп төзелде. Бу китап та — беренчедән алып алтынчы сыйныфка кадәр булган дәреслекләрнең дәвамы. Татар әдәбиятын сез елдан-ел тирәнрәк итеп өйрәнәчәксез. Әдәбиятны тирәнрәк белү өчен, үткән сыйныфларда үзләштергән белемгә таянырга кирәк булачак.

КАБАТЛАУ

Без әсәрне өлешләргә бүлдек, өлешләр арасындагы бәйләнешне таптык. Әсәрләрнең күбесе ике өлешкә бүленүен белдек.

Фәнни фикерләүнең төп максаты — катлаулы күренешне күз алдына китерерлек итеп гадиләштерү. Ә моның өчен әсәрне башта вак-вак өлешләргә бүлеп өйрәнергә тиеш булабыз.

Кагыйдәләр ышандырырлык булсын өчен, Борынгы Греция галиме Аристотель сүзләре белән танышыйк: «Теләсә нинди әйберне баштагы сәбәпләрен белми торып һәм аны ваквак кисәкләренә кадәр таркатып өйрәнмичә белеп булмый».

Бирем

Бөек галим сүзләрен, үзегез аңлаганча, дәфтәрләрегезгә языгыз.

Моңа кадәр сез анализ ясауны әсәрне таркатудан башладыгыз. Охшаш сыйфатлары булган кисәкләрне кушып, бер өлеш иттегез. Башка төрле сыйфатлары белән бер-берсенә охшаган кисәкләр икенче өлеш булды. Әсәр күз алдына китерерлек булып гадиләште. Аннары ике яки өчкә генә калган өлешләргә исем бирдегез. Исемне ничек табарга кирәклеген дә белдегез. «Ни турында?» соравына иң кыска итеп җавап бирү өлешләрнең исемнәре була.

Әдәби әсәр — фикер һәм тойгы җимеше ул. Шуңа күрә аны фикерләп һәм хискә бирелеп кенә аңларга мөмкин.

Әйдәгез, хәзер моңа кадәр өйрәнгәннәрне искә төшерү өчен, әсәрләргә анализ ясыйк.

Җанлы кояшлар

Безнең яклар Зифага да,
Сылуга да бай иде,
Карлыгачтай кодачалар,
Тумачалар бар иде.

Кашлар кыйгач! Йөзләр көләч! —
«Кояштыр бу!» диярлек,
Аяк баскан эзләренә
Алсу гөлләр сибәрлек.

Эшчән алар — «Алтын кул» дип,
Кушаматлар бирерлек.
Җитез алар — Мәскәүләрдә
Декадада биерлек.

Кайгы килсә, илереп-тилереп,
Халык исемен сатмыйлар,
Тешне кысып, яшьне йотып,
Илдән әдәп саклыйлар.

...Ул чактагы заманалар
Фаҗигагә бай иде:
Убылганнар, җуелганнар,
Куылганнар бар иде.

Аерылдылар, каерылдылар
Сугыш давылларында,
Берсе — илдән әллә кайда,
Берсе — Идел ярында.—

Ялгыз калды. Интексә дә,
Иле исмен сатмады,
Яшен йотып, тешен кысып,
Йөрәгендә саклады.

Кайсын алма, шунысы көләч —
«Кояшмы бу?!» диярлек,
Үзенә түгел, эзләренә
Башларыңны иярлек.

Хатларында таныла иде,
Исән-саулык язса да:
Вәгъдәсенә туры яши,
Башларга таш яуса да...

Күргән-белгән сөйли һаман:
Көтте, мескен, бизмәде,
Гомерләре өзелгәнче,
Өметләрен өзмәде.

Тулысынча бирде илгә:
Көнен, төнен — барын да.
Донор булып, канын бирде,
Һәм... ахырда, җанын да.

Татар хатын-кызларының
Раслагансың, гүзәлем,
Янып, көлгә калса калыр,—
Авырлыкка түзгәнен...

Ишетә алса әйтер идек:
«Үзеңне дә сөяргә
Кирәк иде...» Соңга калдык
Менә шулай диярга:

«Алларым син, гөлем син,—
Сөеклем син, тиңем син! —
Башларыма таш яуса да,
Ташлар ярым түгел син».

И сез, безнең сеңелкәйләр,
Кашларыгыз кыйгачлар,
Илнең гомер юлларына
Нур сибүче кояшлар,

Менә шулай сөя сезнең
Йөздән туксан җидегез!
Әй егетләр, шундыйларның
Кадерләрен белегез.

Бирем

Шигырь Хәсән Туфанның соклануы, горурлануы, кызгануы, үкенүе турында. Шуны исбат итегез.

Сибгат Хәким

Егетләре Казан артының

Сүз башланып китә буш арада
Сагынып язган сәлам хатыннан,
Моңлы җырчы узган урманнардан,
Безнең мәшһүр Казан артыннан.

Берсе аның Сәгъди күршесеннән,
Өчиледән очрый, Куәмнән,
Күтәрелгән халык зур сугышка
Ерак авыллардан — түбәннән.

Кузгалаклар җыйган болыннардан,
Мәктәпләргә йөргән юллардан,
Егылып, елап кайткан урыннардан,
Тальяннарга сеңгән моңнардан,
Әкиятләрдән, безнең мәхәббәтнең
Уелып эзе калган җирләрдән,
Бабайлардан килгән нигезләрдән,
Җырлап туйлар иткән өйләрдән,
Туган җирдән безне кем аерыр!
Туган ил һәм туган тел өчен
Гомерләрне хәтта кызганмадык,
Дошманнарның бик күп төрлесен
Мәскәү читендәге сугышларда,
Белгород һәм Харьков янында,—
Дала фронтында, илнең тирән
Елгаларын кичкән чагында —
Онытмаслык итеп кыйнадык без —
Егетләре Казан артының.
Кер төшмәсен барыр юлларына,
Намусына татар халкының.

Прут, 1944 ел

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

Малайлыкта кунакта

(Хикәя)

Мин әкрен генә авыл урамыннан барам. Бу — минем туган авылым Карамалы. Исәнме, Карамалы, исән генә тордыңмы? Исәнмесез, кәҗәле, каэлы, бозаулы урамнар! Янбашыма әләгеп торасы килмәгән ыштанны, күтәрә-күтәрә, кайчандыр мин чабып йөргән урамнар, исәнмесез! Исәнмесез, тау башлары, иген кырлары! Кайда соң сез, яшьлегемнең күңелле иптәшләре, җил тегермәннәре? Тау башында никтер мин сезне күрмим?

...Без дә үзебезчә бәхетле идек. Баш очында әйләндереп-әйләндереп торганнан соң, шарт иттереп чыбыркы шартлату рәхәте үзе генә дә ни тора!

Әйе, без дә үзебезчә бәхетле идек. Авылга тәрәзә куючы килгәч, аның артыннан көнозын ияреп чабып йөрү бәхет түгелмени? Пыяла куючы җәяү килмәгән, ат җигеп тә килмәгән, калайлары елтыр-елтыр итеп тора торган ак велосипедка атланып килгән! Ә велосипедны безнең беренче күрүебез. Велосипедка безнең бармак белән орынып карыйсыбыз килә. Атланып карыйсыбыз, егылып карыйсыбыз килә...

Бүрәнә өстендә әкият сөйләшүләр, яңгыр боткасы пешерүләр, кызлар белән әйлән-бәйлән, сукыр бүкән, таккаравыл, бишташ уеннары, атка атланып, болында җилдәй чабып йөрүләр, иреннәребез күгәргәнче су коенулар...— болар үзенә күрә малайлар өчен зур рәхәт түгелмени?..

Аннары беренче тапкыр китап тоту рәхәте. Хәзерге заманда гына ул китап күп. Без малай чакта алай түгел иде. Китап бик кадерле иде. Әти, базарга чыгып киткәндә, «Китап алып кайтырмын» дисә, ул көнне җанга тынычлык бетә иде инде. Әтинең каршысына чыгып торулар, кулга китап эләккәч, куанычтан сикеренүләр, китапны тышлаулар, кадерләп кенә укулар... Хәзерге яшьләр андый рәхәтне беләләрме икән?

Мин әкрен генә авыл урамыннан барам. Бу — минем туган авылым Карамалы. Миңа инде алтмыш яшь. Мин үземнең малай чагымны эзләп кайттым. Күземне йомсам, күз алдыма тузанлы урамнан чабып баручы чандыр гына бер малай килә... Өстендә әнисе суккан күк күлмәк, ботында алача[1] ыштан. Аяклары чебиләнгән. Бу — мин, шулай үз хыялымда чабып

---

[1] Алача — төрле төстән буй-буй сугылган киндер.

йөрим. Чабарга дигәндә мин бик оста идем шул... Исәнме, тузан туздырып чабып йөрүче түбәтәйле яшьлегем! Исәнмесез, тал агачлары! Кызыл авызлы тирән ермаклар, исәнмесез!

— Исән әле, бик исән,— диләр кебек тагын да тирәнәя төшкән ермаклар.— Үзең исәнме? Без сине бик хәтерлибез. Язгы ташу кайткач, ермак төпләреннән шома ташлар җыеп, аларны уенчык итеп уйнап йөри идең син, шук малай!

— Исән әле, бик исән,— диләр кебек яр буендагы карт өянкеләр.— Без дә сине онытмадык, безнең ботаклардагы карга ояларына көн күрсәтми торган идең син!

— Исән әле,— диләр кебек миңа тузанлы юллар.— Карамалы юлларын онытмагансың, кайткансың... Син киткәннән соң, бу юллардан күпме кеше китте, күпмесе кире кайтмады...

— Ә мин менә кайттым... Карамалы юлларын бик яхшы беләм. Шушы юллар бит инде минем әтине шахталарга алып киткән, алып кайтмаган. Шушы юллар минем әнине алып китте дә кайтарып куймады. Шушы юллар үземне дә алып китеп, балалар йортына илтеп бирде...

Менә бүген дә... Һаман шул ук кояш. Ай да шул ук. Йолдызлар да. Ике тау арасындагы чишмәләр дә... Агайлардан тау башында каберләр генә калган. Олы күлдәге су анасы да күптән вафат, шүрәлеләр дә, бичуралар да вафат... Чыпчыклар да бүген яшь чыпчыклар, каргалар да... Тормыш бүтән.

Ләкин мин Иске Карамалыны, яшь чагымдагы ал истәлекләргә төренгән Карамалыны, бөтен иске матурлыклары белән һаман күреп торам. Җәлил абый да исән. Гапсаттар абый да... Тау башындагы җил тегермәннәре дә...

Тирән яр эченнән миңа күк йөзенең бер кыйпылчыгы зәпзәңгәр булып күренеп кала. Мин туктап, гаҗәпләнеп карап торам: нинди нәрсә ул зәп-зәңгәр күк йөзе, ак болытлар, кояш, йолдызлар? Очып барган ап-ак болыт кисәгенә минем бармак белән төртеп карыйсым килә...

Ә кошлар? Бер генә көнгә кош булып торсаң иде, бер генә көнгә, бер генә сәгатькә... Әнә теге тилгән кебек, канат какмыйча, көн буе һавада әйләнеп йөрсәң иде. Бик рәхәттер югарыдан авылда ниләр барын, кемнәрнең нишләвен карап йөрү...

Аннары минем тагын малай чакта көнбагыш булып, сары чәчәк атып, кояшка карап утырасым килә иде.

Хәзер дә әле мин каршы булмас идем, чөнки ул чәчәкләрнең нәрсә хис иткәннәрен, нәрсә уйлаганнарын бик беләсем килә...

Бүрәнәгә аркылы такта куеп, таган атынабыз... Әллә нәрсә шунда, гел шушы Гөлниса белән уйныйсым килә. Юкса инде бүтән кызлар да бетмәгән ич...

Кайвакыт мин читән тишегеннән Галиәскәр абзыйларның ишегалларына карап торам. Гөлниса чебешләр туйдыра. Чикерткә сыйрагы кебек озындыр сыйраклары, ә куллары... Кояшта янган кара куллары неп-нечкә. Икмәк катысын чәйни дә чебешләргә ата. Чебешләр талаша-талаша ашыйлар да, ашап бетергәч, Гөлнисаның артыннан өйалды баскычына менеп китәләр.

Ә бер тапкыр сукыр тәкә уены уйнаганда, Челән Шакир Гөлнисаның әлеге неп-нечкә кулларыннан тотты. Шундый ачуым чыкты... Аның ни хакы бар Гөлнисаның кулыннан тотарга! Гөлниса Челән Шакир күршесе түгел, минем күршем!

...Үтте күп еллар. Гөлнисаның инде әллә ничә баласы бар. Җиткән кызлары, малайлары. Менә мин тагын авыл урамында йөрим. Бу — минем туган авылым Карамалы. Кулларымны картларча артка куеп, әкрен генә барам. Җәйге матур кич. Багана башларында электр лампалары кабынды.

Каршымда әлеге мин яшь чакта кабына торган йодрык хәтле йолдыз тагын чәчрәп кабынды. Бу матур йолдызга кайчандыр минем әти дә, мөгаен, карап торгандыр, әни дә, күрше Җәлил абзый да... Менә хәзер мин дә, нәкъ безнең авыл өстендә кабына торган шушы якты йолдызга карый-карый, югары очка таба әкрен генә менеп барам. Миннән соң да бу күркәм йолдызга сокланып карап торучылар күп булыр әле...

1966 ел

Биремнәр һәм сораулар

1. Әсәрнең темасын әйтегез. Темасын белү өчен, үз-үзеңә «Әсәр ни турында?» соравын бирергә кирәк. Кыска итеп әйтелгән җавап тема була.
2. Хикәя, балачак хис-хыяллары һәм өлкән агай хис-хыяллары дип, ике өлешкә бүленә. Исбат итегез.
3. Авыл өстендә чәчрәп кабынган йолдыз әсәрдә ике тапкыр кабатлана: башта һәм ахырда. Мондый кабатлануга аеруча әһәмият итәргә кирәклеген сез инде беләсез. Автор безгә күктәге йолдызның мәгънәсен табарга куша. Бу йолдызга әти-әни дә, башкалар да карап торганнардыр. Мин дә карап торам. Миннән соң яшәячәк кешеләр дә карап торачаклар, ди.

Төрле заман кешеләренең игътибарын җәлеп итәрлек бу даими яктылыкның мәгънәсен әйтегез. Ул ни өчен үзгәрми? Аңа кешеләр ни өчен карыйлар?

Марсель Галиев

Шүрәле гаепмеме?

Ялкау гына искән Җилне
тотып алган Шүрәле.
Җилнең моңарчы булмаган
мондый җанвар күргәне.

Башта каушап калган, ди,
Җил,
дер-дер килеп калтырап.
Йомшак дәшкән Шүрәлегә
карап торган аптырап.

Алай усал түгел икән
Ялгыз урман сарыгы.
Кети-кети уйнарга дип,
иптәш көткән зарыгып.

Рәхәт булып киткән Җилгә
шомлы урман куены.
Ризалашкан бик ошатып
Шүрәленең уенын.

Ә Шүрәле иплән кенә
Кытыкларга тотынган.
Тамашаны карар өчен,
кошлар, агачлар тынган.

Җилнең көлү капчыклары
берәм-берәм чишелгән.
Шарлавыктай аккан көлү —
гүя күкләр ишелгән.

Әй көлә Җил, әй көлә, ди,
сикергәли, әйләнә.
Тик бераздан аңлап алган
капканын бу хәйләгә...

Шүрәленең бармаклары
кыза гына бара, ди.
Җилнең инде көлә торгач,
эчен каты ала, ди.

Кинәт...
елауга күчеп, Җил
бөтерелә башлаган.
Ярсып бөтен тирә-юньне
актарып та ташлаган.

Шүрәлене койрыгыннан
агачларга ураган.
Хәтәр көчле давыл булып
Күтәрелгән урманнан.

Ачуыннан дер селкетеп
урап йөргән дөньяны.
Бүтән бер дә көлмәскә дип
сүз биргән диләр аны.

Аннан тәмам хәлдән таеп
төшкән упкын төбенә.
Кырык көн һәм кырык
төннән
чыккан дөнья йөзенә.
Ул инде нәкъ элеккечә —
давыл түгел, Җил генә...

Шуннан бирле исми, ди,
Җил,
урман эченә кереп.
Агач башларыннан чыгып
уза икән җилдереп...
....

Эти сөйләгән әкият —
балачакның ядкаре.
Шундый хәлгә тарган Җилне
кызганып, күз яшьләре
түккән идем. Хәзер инде
Шүрәлене кызганам.
Әкиятләргә ышанулар
бетеп тә барган заман.

Сорау

Лирик герой сабый чакта Җилне, ә еллар үткәч, Шүрәлене кызгана. Ни өчен аларга карашын үзгәртә?

Резеда Вәлиева

Дуслык

Зәңгәр күк кояш белән дус,
Иген — кыр белән.
Җәйләр — җылы яңгыр белән,
Чишмә — җыр белән.

Күлләр аккошлар белән дус,
Май — сирень белән.
Төн — якты йолдызлар белән,
Мин — синең белән.

Бирем һәм сорау

1. **Шигырь дуслык турында. Автор ни өчен «Мин синең белән дус» дип шигыренең эчтәлеген бер генә юл белән әйтми, әллә ничә мисал китерә?**
2. **Беренче һәм икенче строфа арасына куярлык тагын бер строфа уйлап табыгыз. Мәсәлән,** ***ат чана белән дус, чана...*** **(Дәвам итегез.)**

ХАЛЫК ИҖАТЫ ЖАНРЛАРЫ

Әсәрләрне әдипләр иҗат итәләр, дибез. Ләкин күп кеше катнашында иҗат ителгән әсәрләр дә бар. Мәсәлән, әкиятләр, мәзәкләр, дастаннар, мәкальләр, әйтемнәр һәм табышмакларның бик күп кешеләр тарафыннан иҗат ителгәннәре бар. Аларны кайчандыр, кемдер уйлап тапкан. Аннары уйлап тапкан мәкален башкаларга әйткән, җыр чыгарса җырлап күрсәткән, әкият иҗат итсә сөйләгән. Тыңлап торучылар ишеткәннәрен якыннарына сөйләгәннәр, җырлап күрсәткәннәр, үз якыннары башкаларга сөйләгән... Шулай итеп, башлап иҗат итүче бөтенләй онытылган. Аның иҗат җимешен башкалар үзгәрткәннәр, шомартканнар, рифмалар, каршылыклар уйлап тапканнар. Табышның уңышлысы халык иҗаты әсәренә әйләнгән. Ул әсәрләр, буыннан буынга күчеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Бу әсәрләрне берәү дә язмаган. Ничек язсын, алар арасында бик борынгылары да бар бит. Ул чакта әле кешеләр яза да белмәгәннәр. Әкиятләр, мәзәкләр һәм башка төр әсәрләр авыздан авызга күчкән. Шуңа күрә аларны **халык авыз иҗаты** дип атый башлаганнар.

Халык иҗаты әсәрләренең барысы да кешеләрнең яшәешен җиңеләйтү вазифасын үти. Чыннан да, файдасы булмаган яки зыянлы әсәрнең кемгә кирәге булсын, ди.

Халык авыз иҗаты әсәрләре дә, матур әдәбият кебек, жанрларга бүленә. Хәзер халык иҗаты жанрларының берничәсен өйрәник.

ӘЙТЕМНӘР

Уртак сыйфатлары булганга күрә, кып-кыска әйтемнәр дә бөтен бер жанр булып оешалар.

Искә төшерик. Әйбер сыйфаты дигәндә, нәрсәнеңдер бер ягын күз алдында тоталар. Әйтемнәрнең күзгә күренеп торган уртак сыйфаты бар: алар — кыска. Ләкин кыскалык әле аның җитди, ягъни асыл сыйфаты түгел.

Асыл сыйфатларының берсе — алар, мөстәкыйль жанр булсалар да, мөстәкыйль яши алмыйлар.

Тиктомалга берәү дә: «Күзгә төртсәң күренми»,— дими. Алай дию өчен, ким дигәндә, караңгы төн булуы шарт.

> Әйтемнәр, тормыш вакыйгасына бәя биргәндә генә, эчтәлеккә ия булалар.

Мәзәкне, мәсәлне, әкиятне сөйләп тә, укып та була. Аларның эчтәлекләре үз эчләрендә. «Телеңне йотарсың» әйтеменең эчендә мәгънә юк. Телне йотмыйлар. Табын алдында берәү, коймак ашый-ашый, икенче кешегә «телеңне йотарсың» дисә, ризыкның тәменә бик тәмле, дип бәя биргән була. Әйтем, ризык һәм ризыкка бәя бирүче кеше белән бәйләнешкә кергәч, шунда ук эчтәлеккә ия булды.

Галимҗан Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә шәкерт, укуын тәмамлап, ялга кайта. Улының кайтуы әнисе өчен зур бәйрәм була. Шәкерт әнисенең шатлык дәрәҗәсен әйтем аша бәяли: «Халыкча әйткәндә, *өрмәгән җиргә утыртмый*». Әдип шул ук вакытта әйтемнең мәгънәсен дә ачып бирә: «Әни ... шул дәрәҗәдә якын һәм үз тота иде. Мин шул ялкында яна, эри идем». Шәкерт, урамга чыккач, дуслары белән очраша. Очрашу шатлыгын тасвирлау өчен, башка әйтем куллана: «Хәзер генә кавышкан бу иске танышларым эчендә ... һәрнәрсә матур, сөйкемле кебек булып, *шатлыгым эчкә сыймый, күңел әллә кая сикерә, әллә нәрсәм әллә ни белән тула да ташып түгелергә тора төсле хис ителәә иде*».

Эчтәлекләре тормыш вакыйгалары белән бәйләнешкә кергәндә генә ачыла торган жанрлар бер әйтем генә түгел. Мондый сыйфат мәкальдә дә, табышмакларда да, халык җырларында да бар.

> Әйтемнең төп сыйфаты — нәрсәнеңдер берәр ягына, аның да фәкать дәрәҗәсенә генә бәя бирүендә.

Мәсәлән, кешенең наданлык сыйфатына бәя биргәндә, әйтем, бу сыйфатның иясен оялтырлык итеп, «Акыл өләшкәндә мич башында утырып калгансың»,— ди. Оялдым диясе урынга «Җир ярыгына керерлек булдым»,— ди. Ике кешенең дуслык дәрәҗәсен күрсәтү өчен, «Бер кашыктан ашыйлар»,— ди.

Берничә әйтем белән танышыйк.

* Аяк өсте йоклап йөри.

* Баскан җиреннән ут чыга.
* Аягы җиргә тими.
* Җир тишегенә керердәй булдым.
* Мәчесе дә куян тота.
* Ике күзем дүрт булды.
* Мыек та селкетми.
* Агач атка атландыру.
* Инәдән дөя ясау.
* Бүрәнә аркылы бүре куган.

Бирем һәм сорау

1. Югарыдагы әйтемнәр кешеләрнең нинди сыйфатларына бәя бирәләр?
2. Әйтемнәрнең теләсә кайсын үзегез уйлап тапкан берәр вакыйга эченә кертегез.

МӘКАЛЬЛӘР

Тормышта бик күп вакыйгалар кабатлана. Ялгышлар-хаталар да кабатлана, үкенечләр дә. Борынгы әби-бабайларыбыз үзләре өчен генә яшәмәгәннәр. Уллары, оныклары, аларның уллары, оныклары өчен дә борчылганнар. «Тукта әле, мин ясаган ялгышны ни өчен минем балам да, аның балалары да кабатларга тиеш?» — дип, ялгыш гамәлне алдан кисәтү чарасын күргәннәр. Мәсәлән, гади генә бер мисал: уллары, утын яргач, балтасын ярган урынында калдырып киткән. Әти-әни исә, улын бу гадәтеннән биздерү өчен, чара, сүз эзләгәннәр.

«Ерак куйсаң — якыннан алырсың, якын куйсаң — ерактан алырсың»,— дип, улларын шаккатырганнар.

Уллары аңлы егет булган, ерак куйсаң якыннан алып булмый. Димәк, бу сүзгә башка мәгънә салынган булырга тиеш. Бүкәнгә чабылып калган балтасына күз ташлагач аңлап алган: «Ә-ә-ә! Балтаңны җыеп куй, урларлар. Ә урласалар, башкасын сатып алырга туры киләчәк, дип кисәткәннәр икән өлкәннәр». Егет мәкальнең мәгънәсен табуына сөенгән. Балтасын шунда ук келәткә илтеп, келәт ишеген йозак белән бикләгән. Ә хикмәтле үгетне хәтеренә салып куйган. Билгеле, ул аның мәкаль булуын белмәгән. Мәкаль исә егетнең ваемсызлыгын көтеп кенә торган. Кирәк нәрсәсен үз урынына куймавын күрү белән, кылт итеп исенә төшкән. «Ерактан барып аласыңны онытма»,— дип бармак янаган. Ә егетебез үз чиратында мәкале белән улларын акылга утырткан.

Безнең борынгы бабаларыбыз, билгеле, сәнгатьнең каршылык алымын белмәгәннәр. Алымны алар шулай ук үзләре уйлап тапканнар.

Бер аксакал кешеләрне эт белән бүрегә алыштырган. «Эт өрер, бүре йөрер» дигән мәкаль белән теләсә кем сүзенә карап, кәефең кырылмасын, син алардан өстен бит, дип башта үзен, аннан соң балаларын юанырга өйрәткән. Өстәвенә үгетен рифма һәм ритм белән бизәгән. Кем белә, бәлки безнең сәнгать алымнарын мәкаль иҗат итүчеләр уйлап тапкандыр.

Күп еллар, гасырлар үткән. Мәкальнең тормыш итү өчен искиткеч файдалы ярдәмче булуын белеп алгач, халык кабатланган вакыйгаларның һәркайсына мәкаль уйлап тапкан. Мәкальләрне күбрәк белгән кешегә яшәү дә җиңелрәк, чөнки мәкаль кешеләргә үз-үзләрен дә, башкаларны да тәрбияләргә ярдәм итә. Ни кылсаң да, башта ахырын уйла, дип кисәтеп тора. Ә инде ялгышып өлгергән кешегә: «Ни чәчсәң, шуны урырсың»,— дип, ялгышын бүтән кабатламасын өчен, сәбәбен әйтеп оялта.

Менә шундый мактаулы вазифасын үтәр өчен, мәкаль ике өлештән торырга һәм өлешләрнең берсе — сәбәп, икенчесе нәтиҗә булырга тиеш.

Мәкальләрнең асыл үзенчәлеге шуннан гыйбарәт.

Мөстәкыйль эш

* Карт чыпчык кибәккә алданмый.
* Ертык зурайса, ямаулык җитмәс.
* Чебен дулап тәрәзә вата алмый.
* Җил исми, кура башы селкенми.
* Алма агачыннан ерак төшми.
* Ялгыз агач янтык үсәр.
* Юләр купса, зур куба.
* Дусның таягы ачы булыр.
* Көче җитмәгән зур күтәрер.
* Сөтсез сыер күбрәк мөгри.
* Кешегә баз казысаң, үзең буе казы.
* Күп кытаклаган тавык йомырканы аз сала.

Биремнәр һәм сорау

1. 2—6 нчы мәкальләрне үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз. Мәсәлән, беренче мәкальне болай әйтик: *Әгәр чыпчык карт булса, ул беркайчан да кибәккә алданмый.* (Дәвам итегез.)

2. **Шул ук биш мәкальнең мәгънәсен аңлатып языгыз. Мәсәлән, беренче мәкальнең мәгънәсе болай языла:** ***Күпне күргән өлкән кешене юк-бар белән алдый алмассың.*** **(Дәвам итегез.)**

3. **Дәреслектәге мәкальләрне ике-өч тапкыр укыгыз. Хәтерегездә калдырырга тырышыгыз. Аннан соң дәреслегегезне ябыгыз да үзегезне үзегез сынап карагыз. Ничәсе хәтерегездә калуына карап үзегезгә эчтән генә билге куегыз.**

4. **Кайсыгыз дәреслектә булмаган мәкальләр белә? Барысын да дәфтәрләрегезгә языгыз.**

ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Габдулла Тукай халык җырларын бик яраткан. Аларның уртак эчтәлеген иң элек ул күрсәткән. Фәнни фикерен шагыйрь менә ничек матур итеп әйткән: «Халык җырлары — халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан[1] көзгеседер».

Тормышта бик күп вакыйгалар кабатлана. Кешеләргә кайгы яки шатлык китерә торган сәбәпләрнең кабатлануы да шуңа керә. Якын кешеңнән, туган җирдән аерылу аеруча күп кабатланган һәм кешеләрнең даими хәсрәтенә әйләнгән.

Халык җырлары күңелнең әнә шул даими хис-кичерешләрен үзенең төп эчтәлеге иткән. Җырны да кешеләр борынгы заманнарда ук иҗат иткәннәр һәм үзләрен үзләре юату өчен җырлаганнар. Татар халык җырларының күбесе аерылу турындагы җырлар.

Халкыбыз үзенең җырларында хәсрәтен сөйли-сөйли, елый-елый юанган.

Сандугачлар басып сайрап
Сындырган гөлләремне;
Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган көннәремне,—

дип җырлаган.

Шушы дүрт кенә юлда да җырлар өчен уртак булган һәм аларны жанр иткән асыл сыйфат бар. Бу дүртьюллык җыр да аерылу турында. Ул артык гомуми кебек. Анда кемнең кемнән һәм ни сәбәпле аерылуы турында бер сүз дә әйтелмәгән. Безнең җырлар шундый гомумилекләре белән эчтәлекле дә. Эченә чиксез күп эчтәлек, мәгънә сыйдыра ала. Шуңа күрә

---

[1] Раушан — якты.

һәркем җырлаганда андагы сүзләргә үз хәсрәтенең сәбәбен сала. Берәүләр туган якларын күз алдында тота, икенчеләр исә туганнарыннан, сөйгән ярларыннан, якыннарыннан аерылу турында җырлый.

Димәк, халык җырлары да эчтәлекләрен тормыш вакыйгалары белән турыдан-туры бәйләнешкә кергәндә генә ачалар икән. Ә тормыш вакыйгасы — бу очракта җырлаучы кешенең рухи халәте. Ул үзе турында җырлый, үзен үзе юата. Җырлаучы кеше җырга күңелендәге хисләрен сала. Үзе авторга әйләнә. Шулай итеп, кечкенә генә бер дүртьюллык чиксез күп төрле эчтәлек белән баый.

Аерылу вакыйгасы кабатланса да, кешеләр аерылу турындагы җырларын мөмкин кадәр төрле-төрле итеп иҗат иткәннәр. Аерылуны һаман бүтәнчә итеп әйткәннәр. Өстәвенә дүртьюллыкның баштагы ике юлында табигать күренешен сурәтләгәннәр. Дүртьюллык строфаның баштагы ике юлы белән соңгы ике юлы (ике өлеше), үзара бәйләнешкә кереп, җырга өстәмә эчтәлек бүләк иткән.

Ай яктыкайлары бигрәк якты,
Су өсләре тигез юл кебек:
Сез дускайларымнан аерылгач,
Бер көн тоелды миңа ел булып,—

дип җырлаган халык, хәсрәтенең сәбәбен дә, дәрәҗәсен дә бергә кушып әйткән. Ләкин, гадәттә, аерылу бер дүртьюллыкта, хис дәрәҗәсе икенче дүртьюллыкта була.

Агып китте, агып китте
Яулыгым кар суына;
Ах, җаныем, чыдый алмыйм
Йөрәгем ярсуына,—

дип, җырчы хәсрәтенең дәрәҗәсен арттырган.

Гомер буена хәсрәт белән яшәргә мөмкин түгел. Шуңа күрә халык, хәсрәте белән килешеп, үзен юатырга тиеш булган.

Ак балыклар уйный, ай, иркендә,
Агыйдел суының төбендә;
Бер кайгыга батам, бер юанам —
Миндәйләр күп дөнья йөзендә,—

дип, җырын тәмамлаган.

Шулай итеп, кешеләр үз күңелләрендәге хисләренә бәя биргәннәр. Башка кешеләрнең хәсрәтләре белән чагыштырганнар һәм юанганнар.

Эчтәлегендәге өч өлеш — шулай ук җыр жанрының асыл сыйфаты.

Биремнәр һәм сорау

1. «Җырлар» турындагы кереш өлешен укып, конспект языгыз. Аны өлешләргә бүлегез. Өлешләрнең һәркайсы җырның бер сыйфатын аңлатуга багышланган булырга тиеш.
2. Сез нинди халык җыры беләсез? Дәфтәрләрегезгә языгыз. Җырыгызга анализ ясагыз.
3. Тәкъдим ителгән дүртьюллыклар арасыннан хиснең сәбәбе, дәрәҗәсе, юану турындагы өч дүртьюллык сайларга кирәк.

Иртә торып тышка чыксам,
Кошлар кунган миләшкә;
Мин моңаймый кем моңайсын
Бер кешем юк киңәшкә.

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны;
Су сипсәң дә басылмыйдыр
Янган йөрәк ялкыны.

Агыйделдән йөзеп бара
Мамык кебек ак күбек;
Икебез ике якларда
Каерылган гөлләр кебек.

Яшь вакытта күкрәгемә
Чәчәкләр кадамадым,
Чөнки яшьлегемнән матур
Чәчәкләр таба алмадым.

Урман артларында күлләр булыр,
Күл янында гөлләр дә булыр;
Гөл саргая диеп, без саргаймыйк,
Бәлки рәхәт көннәр дә булыр.

МӨНӘҖӘТЛӘР

Мөнәҗәт — җырның бер төре. Димәк, аңа җырларның барлык җитди сыйфатлары да хас. Ләкин мөнәҗәтне үзенә бер төр жанр дип йөртәләр. Димәк, аның җырдан аермасы да бар.

Беренче аерма: мөнәҗәтләрнең дә эчтәлеге хис, хиснең сәбәбе дә җырларныкы кебек аерылу, ләкин мөнәҗәт гомумиләштерү ягыннан җырлардан калыша. Аның темасы таррак. Персонажлары өлкән буын вәкиленең якты дөньядан аерылуы һәм туганнарыннан (улларыннан) аерылуы белән чикләнә.

Икенче аерма: мөнәҗәтләр җырлардан күләмлерәк була. Шуңа күрә һәр әсәрдә хиснең сәбәбе дә, дәрәҗәсе дә, юануы да берничә урында кабатлана.

Мөнәҗәтләр дә — лирик әсәрләр. Шуңа күрә аларның эчтәлеген табу өчен, хис сәбәпләрен, дәрәҗәсен ачыкларга кирәк.

Анага бала — күкрәк сагышы

Чыгып китүе авыр булгандыр,
Киткән вакытта күңеле тулгандыр.

Кала, дигәндер, туган илләрем,
Шатланып уйнап йөргән җирләрем.

Чәчәкләр коя үскән гөлләр дә,
Бик авыр булды киткән көннәрдә.

Үстергән идем ятимлек белән,
Авыр елларда ялгызлык белән.

Урман буенда үсә тирәкләр,
Ялкынлы утта яна йөрәкләр.

Сунәрлек түгел, сулар сипсәң дә,
Өзелә үзәкләр искә төшкәндә.

Салкын суларның эчтем суларын,
Сүрелдермәде йөрәк ялкынын.

Гөрли күгәрчен, гөлләргә басып,
Кайгылы башым китмәсен шашып.

Авырлыкларга сабырлык кирәк,
Сабыр итәргә түземлек кирәк.

Биремнәр

1. Мөнәҗәттәге ананың һәм улының хис сәбәпләрен әйтегез.
2. Ананың һәм улының хис дәрәҗәләре булган урыннарны күрсәтегез.
3. Мөнәҗәттә юану турындагы юлларны күрсәтегез.

Ялгыз ана

Ялгыз ана, ялгыз ана, күзендин яшьләре ага,
Әтиләре яшьләй үлгәч, балалары җыелып кала.

Кызганыч ул ялгыз ана, тормышлары авыр бара,
Балалары үсеп җиткәч, һаман да ул ялгыз кала.

Аһ, йөрәгемнең башында кеше күрмәгән ут яна.
Кайтыр диеп көтә ана, һаман ераклана бала.

Балалары үсеп җитә, бары да таралып бетә,
Ананың нурлы йөзенә сары төшеп нуры китә.

Ялгыз ана ялгыз өйдә, ялгызлыгын уйлый һаман,
Ялгызлык бит авыр аңа, гакылыннан шаша барган.

Ялгыз ана үзе уйлый, үзе елый, үзе көйли:
Балаларның барысына да Ходайдан ул бәхет тели.

Ялгыз ана ялгыз йортта, аның җисеме яна утта,
Ни хәл итсен ялгыз ана, сабыр бирсен үзе Алла.

Сагыну хәле

Тәтешнең юллары киңдер, ак иделләр белән тиңдер,
Өзелеп язам мөнәҗәтем, адашкан анагыз миндер.

Кашың кара сызылмыштыр, тешең энҗе тезелмештер,
Йөрәгемнең бәгырьләре синең өчен өзелмештер.

Сагыну хәле кыен эштер, йөзләремне сары алмыштыр,
Балалардин аерылу пигамбәрләрдин калмыштыр.

Биремнәр

1. Мөнәҗәтләргә анализ ясагыз.
2. Мөнәҗәтнең җырлардан аермасын аңлатыгыз.

БӘЕТЛӘР

Бәет тә — җырның бер төре. Аңа да җырдагы һәм мөнәҗәтләрдәге сыйфатлар хас. Шуңа да карамастан бәетләр дә аерым жанр булып яшиләр. Димәк, аларның да үзләренә генә хас үзенчәлекләре бар.

Җырлар — иң гомуми вакыйгалар турында гына сөйләүче жанр, дидек. Мөнәҗәтләр җырларның чиксез күп аерылу сәбәпләрен чиклиләр: лирик геройның балаларыннан, иреннән һәм якты дөньядан аерылуы турында гына сөйлиләр. Ләкин мөнәҗәтләрдә дә ананың улы аерым бер бала түгел. Гомумән бала. Ире дә гомумән ир.

Бәетләрдә катнашучылар саны тагын да азая. Бәет йә бер кеше, йә бер гаилә, йә авыл язмышы турында сөйли. Фаҗигале бер вакыйганы катнашучыларның исемнәрен, авыл исемен, хәтта вакыйганың вакытын да әйтә.

Бәетнең үзенчәлеге шунда: ул булган бер вакыйга турында сөйли. Тормыштагы йә фаҗигале, йә көлкеле вакыйганы сайлап сурәтли.

Гайшә матур белән гашыйк Камил бәете

Гайшә матур үсә торгач Агыйделнең буенда,
Басма сынып суга аккан язгы Сабан туенда.

Уналтыга җиткән икән Гайшә кызның яшьләре,
Агыйделдә кер юганда, суга киткән башлары.

Чәршәмбе көн кер юадыр, атна кичкә туй икән,
Озын чәчле, кара кашлы, нечкә зифа буйлы икән.

Алтынлаган яфрак алка елтыр-елтыр калкадыр,
Артындагы чулпысы авыр, су төбенә тартадыр.

Язгы сулар салкынлыкдин Гайшә мескен түзәлми,
Түзмәс хәлгә җиткәнлектән, кулын җәеп йөзәлми.

Идел тавы башларында ачык ишек бер кибет,
Шул кибеттән йөгереп төште, Гайшәм, диеп бер егет.

Ул егетнең барса-килсә, Гайшәдә генә күзе икән,
Гайшә белән туйлашырга булган егет үзе икән.

Килеп җиткәч, зирәк егет чумган җирен күзлидер,
Тәвәккәлләп суга кереп, чумып-чумып эзлидер.

Мескен егет күп йөргәч, арып талды хәлендин,
Җан сөйгәнен эзли-эзли, аерылды җанындин.

Гашыйк Камил — булган егет, кызганмаган малын да,
Ахырында сөйгәне өчен кызганмаган җанын да.

Гашыйк мәгъшук бер-берсенә кавыша алмый калдылар,
Тәкъдир буйлә икесе дә башны суга салдылар.

Нинди үкенечле үлем, буйга үсеп җиткәндә!
Икесе дә суда вафат, туй була дип көткәндә.

Гайшә белән яшь егетне судан эзләп алдылар,
Моны күреп авыл халкы бар да хәйран калдылар.

Биремнәр

1. Бәеттәге тормыш вакыйгасын үз сүзләрегез белән сөйләгез.
2. Бәет егетнең фаҗигале мәхәббәте турында. Мәхәббәт хисенең дәрәҗәсен, сәбәбен кыска итеп дәфтәрләрегезгә языгыз.
3. Бәет авторының хисе турында да мөмкин кадәр кыска итеп языгыз.

Тукай бәете

Тарих мең дә тугыз йөз дә унөч елы бу вакыт,
Унбишенче апрелендә җырчыбыз Тукай вафат.

Яшьли китте шагыйрь Тукай тәкъдиренең әмеренә,
Аллы-гөлле күп чәчәкләр куйды халык каберенә.

Мең-мең халык җеназа укып, куйдылар зурлап күмеп,
Чит калалардан килделәр, Тукайны якын күреп.

Кичте дөньяны, бичара, моңланып та сызланып,
Ничә мең кеше күзеннән яшен түкте кызганып.

Шагыйрьләргә шагыйрь иде ул Тукай заманында,
Куркып тормый әйтер иде яхшысын, яманын да.

Бик күп шигырь чыгарды ул, халкы өчен сызланып,
Халкым артка калмасын дип, яратып һәм кызганып.

Мохтаҗлыкта яшәде ул, байга бурычка батып,
Сәүдәгәрләр баедылар, аның китабын сатып.

Хезмәт итте ул халыкка, авыру көе тырышып,
Гаделлекне язды мактап, яманлыкны орышып.

Бирем

Бәеткә анализ ясагыз.

Йомгак ясыйк

Дәфтәрегездә язылганнарны чагыштырып карасагыз, җырның да, мөнәҗәтнең дә, бәетнең дә төп темалары уртак булуын белерсез. Аларның барысы да якын кешедән аерылу турында.

Бу жанрларга кергән әсәрләрнең төзелешләрендә дә охшашлык зур. Алар хиснең өч өлешенә бүленәләр. Ләкин аларның үзенчәлекләре дә бар. Мәсәлән, **җырда** кемнең кемнән аерылуы, лирик геройның яше турында да, ир кешеме ул, хатын-кызмы — берсе дә әйтелмәгән. Бу җырны теләсә кем аерылу белән бәйле булган теләсә нинди вакыйганы күз алдында тотып җырларга мөмкин. Җыр башка әсәрләрдән үзенең гомумилеге белән аерылып тора.

Мөнәҗәттә әнисеннән аерылып сугышка китүченең егет булуы да, яше дә, бердәнбер бала булуы да әйтелгән. Мөнәҗәттәге башка катнашучылар турында да мәгълүмат бирелә. Ләкин монда әле катнашучыларның исемнәре дә, кайдан булулары да әйтелмәгән.

Ә менә **бәеттә** бар да бар: шагыйрьнең исеме дә, катнашучының үлгән елы да, үлгән көне дә әйтелгән, кайда үлүен язарга да онытмаганнар. Мөнәҗәтне улыннан аерылган һәр ана җырлый алса, Габдулла Тукайга багышланган бәет фәкать Тукай турында гына. Аның эчтәлеге бер конкрет вакыйга белән генә чикләнә.

Димәк, җыр, мөнәҗәт һәм бәет үзара гомумилек дәрәҗәсе белән аерыла икән. Без аларның барысын да җыр дип әйтә алабыз, һәм алар җырланалар да. Ләкин конкрет вакыйгага корылган җырга — **бәет**, туганнар арасындагы мөнәсәбәткә корылганына — **мөнәҗәт**, гомуми вакыйгага корылганына **җыр** диләр.

ӘКИЯТЛӘР

Әкиятләрне дә халык иҗат иткән. Бу жанр мифтан кала иң борынгы сәнгать жанрларыннан санала.

Әкиятләрне укый башлау белән, адәм ышанмаслык вакыйгалар эченә кереп адашасың. Колак ишетмәгән, күз күрмәгән дию пәриләре, елан патшалар, аждаһалар белән очрашып куркып каласың. Бушлай ашатучы ашъяулыкларның юктан бар иткән ризыкларына карап сокланасың. Нәрсә генә юк ул әкиятләрдә!

> Әкиятләрнең уртак сыйфатлары — эчтәлекләренең хыял тудырган бөтенләй башка дөнья булуында. Әкият жанрының бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт.

Хыялның да төрле дәрәҗәсе була. Әкиятләрнең кайберләрендә хыял тормыш вакыйгаларыннан аерылмый. Ә кайсыберләрендә хыял безне хайваннар, кош-кортлар дөньясына алып керә. Әтәчләр, төлкеләр, сыерлар анда кешечә сөйләшеп йөриләр. Холыклары үзләренекенә дә, кешеләр холкына да охшаган. Мондый әкиятләргә **хайваннар турындагы әкиятләр** диләр. Бу төркемгә кергән әкиятләрдә һәрвакыт рәнҗетелгән көчсез персонаж үзен рәнҗеткән көчле персонажны җиңә.

Тормыш-көнкүреш әкиятләре дә була. Исеменнән үк күренгәнчә, аларның эчтәлекләре тормышка якын. Мондагы төп каһарман комсыз, ялганчы байлар белән көрәшә, ялганчыларны, мактанчыкларны, куркакларны, сараннарны хур итә.

Әкиятләрнең тагын бер зур төркеменә **тылсымлы әкиятләр** диләр. Бу төр әкиятләрнең эче тулы тылсым. Монда сиңа ничек кенә ярдәм итим, дип торучы әбиләр белән бабайлар, ялгыз егет белән көрәшүче унике башлы диюләр, берсеннән-берсе чибәр сихерче кызлар, су асты патшалыгында яшәүче кешеләр, таплау белән урманга әйләнә торган тараклар, оча торган паласлар һ. б.

Өч төркемгә бүленсәләр дә, әкиятләр жанрының тагын бер мөһим үзенчәлеге бар: әкиятләрнең барысы да хаклыкның тантана итүе белән тәмамлана. Аларда рәнҗетелгән көчсез үзен рәнҗетүче көчлене җиңми калмый.

КӨНКҮРЕШ ӘКИЯТЛӘРЕ

Тормышта ярлы хокуксыз халык элек-электән үзен изүчеләрне, хаксызга рәнҗетүчеләрне җиңү хыялы белән яшәгән. Хыялларын әкият итеп сөйләгән һәм үзләре уйлап чыгарган әкиятләренә ышанып юанган. Көнкүреш әкиятләрендә төп каһарман хаксыз байларны, түрәләрне төп башына утырта, сараннарга җәза бирә, ялкауларны мыскыл итә, тел бистәләреннән көлә. Халык, үзе уйлап чыгарган әкиятләрендә генә булса да, гаделлек хөкем сөргән дөньяда яшәп ала.

Мактанчык бай

Әүвәл заманда булган, ди, бер байның картаеп беткән бер сыеры. Бай сыерны берзаман ашатмый башлаган, ди, шунлыктан сыер да сөт бирүне туктаткан, ди. Ә бу бай мактанырга бик ярата икән, ди. Көннәрдән бер көнне уйлый, ди, бу: «Тукта,— ди,— сыерны болай гына чыгарып җибәрсәм, үземне мактап сөйләмәсләрме»,— ди. Икенче көнне көтү куганда, сыерны кырга чыгарып җибәрә дә халык алдында әйтә:

— Бар, сыер, мине егерме ел туйдырдың, хәзер үзеңне үзең кара, суймыйм сине,— ди.

Сыер, шулай итеп, кырда берүзе тукланып йөри башлый. Кыш җитә. Авылның бер ярлы карты тота да сыерны үзенә алып кайта. Алып кайта да карчыгына:

— Тәрбияләп карыйк, бәлки үзебезгә дә файдасы тияр,— ди.

Боларның бүтән мал-туарлары булмый. Сыерны бик әйбәтләп ашата башлыйлар. Сыер да чиләк-чиләк сөт бирергә тотына. Моны бай ишетә. Ишетә дә бабай янына килә.

— Бу минем сыер, ник алдың аны? — ди.

Бабай:

— Ник, бөтен авыл белә, син аны куалап чыгардың, үзеңне үзең кара диден, без тотып асрагач, ул сөт бирә башлады,— ди.

— Үземә кайтарыгыз, юкса казыйга барам,— ди бай.

— Барсаң барырсың, сыерны сиңа кайтарыр өчен асрамадык,— ди бабай.

Болар бик каты тарткалашып казыйга китәләр. Казый эшне тыңлый да:

— Кайсыгыз минем өч соравыма туры җавап бирер, сыер шуныкы булыр,— ди.— Ә сораулар мондый,— ди,— дөньяда нәрсә иң симез, нәрсә иң матур, нәрсә иң акыллы? Иртәгә җавабын табып килегез,— ди.

Бай әйтә:

— Бу минем өчен чүп! — ди.

Ә бабай кайгыга кала: «Мин каян белим аны?» — дип уйлый. Кайтып карчыгына хәлне сөйләп бирә:

— Сыерсыз калдык, ахры,— ди.

Карчыгы:

— И юләр,— ди,— казыйның сорауларыннан да җиңел сорау буламы соң? — ди.— Син аңа әйт: «Дөньяда иң симезе — җир булыр, иң матуры — яхшы кеше күңеле булыр, ә иң акыллысы әнә безнең Сарыбай булыр»,— диген. Шулай дисәң, бәхәсне отарсың,— ди.

Икенче көнне казыйга киләләр.

Бай:

— Дөньяда иң симезе — минем хатын,— ди,— аңардан да симез зат күргәнем юк,— ди.— Иң матуры — минем айгыр, андый айгыр бөтен Казан губернасында юк,— ди,— ә иң акыллысы — мин үзем. Сыер миңа,— ди.

Чират бабайга җитә. Бу әйтә:

— Дөньяда иң симезе — җир, бөтен әйбер майны шуннан ала,— ди.— Иң матуры — яхшы кеше күңеле, аңа бөтен дөньяның яме тулган,— ди.— Ә иң акыллысы — минем этем Сарыбай,— ди.

Казый әйтә:

— Ике җавабың туры синең. Ә ни өчен синең Сарыбаең иң акыллысы? — ди.

— Алайса, карап тор,— ди бабай. Теге бай белән эткә берьюлы эндәшә: — Китегез моннан, чәбә! — ди. Эт китә, бай шаккатып тик тора. Бабайның:

— Килегез бире! — дип сызгыруы була, эт килә, бай кымшанмый да.

— Кайсы акыллырак соң боларның, казый, үзең уйла,— ди бабай. Казый әйтә:

— Дөрес, синең этең акыллырак,— ди.

Шулай итеп, бабай, бәхәстә җиңеп, сыерны үзенә ала, ә мактанчык бай хур була.

Әкияткә анализ ясыйк

Әкиятне, «хаксыз бай» һәм «хаклы бабай» турында дип, ике өлешкә бүләбез. Бәйләнешләре конфликт дәрәҗәсендәге каршылык, чөнки ике арада сыер өчен көрәш бара.

Хаклык бу әкияттә бабай карчыгының зирәклеге белән җиңә. Әйтергә кирәк, көнкүреш әкиятләренең күбесендә көчсез персонаж көчле персонажны зирәклеге белән җиңә.

Бирем

Әкияттәге тормышта була алмый торган вакыйгаларны табыгыз.

Саран белән Юмарт

Борын-борын заманда, карга казначы, козгын азанчы булып торган чагында, булган икән, ди, бер Саран белән бер Юмарт. Көннәрдән бер көнне болар икесе бергә юлга чыкканнар. Кич булгач, бер җиргә ашарга утырганнар, Саран әйткән:

— Минем капчыкның авызы чишелми, синең ризыкларыңны ашап торыйк әле,— дигән.

— Ярый,— дигән Юмарт,— ашасак ашыйк соң.

Ашаганнар Юмарт азыгын. Бер көн ашаганнар болар, ике көн ашаганнар Юмарт азыгын, өченче көнне аның азыгы беткән. Кич булгач, Саран Юмартның йокыга киткәнен саклап кына яткан да торып качкан. Юмарт йокысыннан торса, Саран юк. Бу да бер юл белән киткән.

Бара торгач, Юмарт бер йортка килеп җиткән, йортка керсә, анда һичкем күренми, өстәл өстендә бер ярты калач кына ята, ди. Юмарт шул калачтан бер телем генә кисеп ашаган да: «Бу өйнең иясе бардыр әле»,— дип, сәке астына кереп яткан.

Бервакытны бу өйгә Аю, Төлке, Тычкан килеп кергәннәр. Тычкан иптәшләренә әйткән:

— Минем мич башында бер чүлмәк көмешем бар иде, мич башыннан сикереп төшкәндә, ул чалтырт итеп кала торган иде,— дигән.

Аю:

— Минем казылмалы кара юл буенда ат башыдай алтыным бар иде, аны берәү казып караган, аз гына төшеп җитмәгән,— дигән.

Төлке:

— Минем дә казылмалы кара юл янында куй башыдай көмешем бар иде, аны кемдер казып караган, аз гына төшеп җитмәгән,— дигән.

Аю, Төлке, Тычкан, бу өйдә төн кунып, иртә белән тагын чыгып киткәннәр. Әлеге Юмарт мич янына барган икән, анда

бер чүлмәк көмеш утыра, ди. Аны алган бу. Аннан киткән казылмалы кара юл белән. Казылмалы юл буендагы ат башыдай алтынны да казып алган. Бераз киткәч, тагын да бер казыла башлаган җир күргән. Казып караса, анда куй башыдай көмеш ята, ди. Аны да алган.

Бу Юмарт, бара торгач, бер урманга барып кергән. Шул урманда, юан агач төбендә, тапталган бер урын күргән.

— Тукта әле,— дигән,— агач башына менеп утырыйм әле, нәрсә булыр икән? — дигән. Шулай дигән дә агач башына менеп утырган. Кич булып, кояш баегач, бу агач төбенә җенпәриләр җыела башлаган. Байтагысы җыелгач, җеннәр башлыгы уртага килеп утырган да әйткән:

— Сукыр җен кайда? — дигән. Сукыр җен килеп җитмәгән икән, аны алып килергә дип ике җенне җибәргән. Тегеләр барып сукыр җенне бик хөрмәтләп күтәреп алып килгәннәр. Әлеге җеннәр башлыгы бу сукыр җеннән сораган:

— Син нигә соңга калдың? — дигән. Сукыр җен торып әйткән:

— Минем кичегүемнең сәбәбе бар,— дигән.— Мин бер хан кызын сихерләп утырдым, аны инде миннән башка беркем дә дәвалый алмас,— дигән.

— Шулай да ничек дәвалыйсың, сөйләп бир,— дигән җеннәрнең олысы. Сукыр җен әйткән:

— Ул ханның,— дигән,— өч ел буена кысыр йөргән бер кара сыеры бар. Әгәр хан, шул сыерын суеп, аның ите белән үзенең бөтен халкын сыйласа, бу кыз, һичшиксез, савыгыр,— дигән.

Таң атуга, җеннәр тагын таралып беткәннәр.

Бу Юмарт туп-туры әлеге хан шәһәренә киткән. Барып җиткәч, шәһәр читендәге бер ялгыз йортка кергән. Исәнлек-саулык сорашкач:

— Йә, хуҗа, сезнең шәһәрдә нинди яңалыклар бар? — дип сораган.

— Яңалыклар шул,— дигән,— безнең ханның кызы бик нык авырып китте, аның авыруына дару тапкан кешегә хан үзенең ханлыгын да, кызын да бирергә булды,— дигән.

— Ярый,— дигән Юмарт,— мин хан янына барып карыйм әле,— дигән.

Барган бу сарайга. Ханга үзенең дәвалаучы икәнен белдереп, аннан керергә рөхсәт сораган. Хан бу кешене сарайга кертергә кушкан. Кергәннән соң, Юмарт үзенең китабын караган була икән. Китабына карап торганнан соң, бу әйткән:

— Синең көтүеңдә өч ел кысыр калган бер кара сыерың булыр, шул сыерны суеп, шәһәр халкын ашатып-эчертсәң, кызың терелер,— дигән. Хан, моңа риза булып, нәкъ Юмарт әйткәнчә эшләгән. Күп тә узмаган, берничә көннән соң, ханның кызы терелгән. Хан Юмартка үзенең кызын да, ханлыгын да биргән.

Көннәрдән бер көнне әлеге Саран да, йөри торгач, шушы шәһәргә килеп чыккан. Юмарт янына кереп, аннан ничек хан булуы, ничек патша кызына өйләнүе турында сораша башлаган. Юмарт моңа, ул качып киткәннән соң, бер өйгә килеп керүен, аннан чыккач, алтын-көмешләр табуын, аннан соң урманда бер агач башында утыруларын бәйнә-бәйнә барысын да сөйләп биргән.

Саран моның болай тиз баюына бик кызыккан. Ул да чыгып киткән, теге йортны эзләп. Барып кергән бу әлеге өй эченә. Барып керсә, өстәлдә баягыча ярты калач ята, ди. Саран ул калачны алган да үзенең капчыгына салган. Үзе, Юмарт өйрәтүенчә, сәке астына кереп яткан. Бервакытны кайтып кергән иң беренче булып Тычкан, аннан соң Төлке, иң соңыннан, лап-лап басып, Аю кайтып кергән.

Карасалар, өстәлдә калач юк. Боларга шик төшкән.

— Мөгаен, монда кем дә булса кергәндер,— дип сөйләшкәннәр. Аю Тычканга әйткән:

— Эзләп кара әле, кем бар икән монда? — дигән. Тычкан мич башын караган, анда һичкем күренмәгән.

Аю әйткән:

— Сәке астына кереп кара! — дигән. Тычкан сәке астына кереп киткән дә әлеге Саранны тартып чыгарган. Тычкан Саранның өстенә сикергән, Төлке битен тырнап ерткан, Аю моны сугып еккан.

Шулай итеп, Саран, үзенең саранлыгы аркасында, шулай хур булган, баемаган да, артмаган да.

Биремнәр

1. Әкияткә анализ ясагыз.
2. Тормышта була алмый торган вакыйгаларны табыгыз.
3. Әкият авторының безгә әйтәсе килгән теләген (идеясен) әйтегез.

ХАЙВАННАР ТУРЫНДАГЫ ӘКИЯТЛӘР

Исеменнән үк күренгәнчә, әкиятләрнең бу төрендә төп персонажлар — кош-кортлар, хайваннар, җәнлекләр. Алар кешечә сөйләшәләр. Ә холыклары белән үзләре булып калалар һәм шул ук вакытта кешегә дә охшыйлар.

Әтәч патша

Элек заманда булган икән, ди, бер Әтәч. Бу Әтәч, ишегалдына чыгып, тәртип саклагандай, як-ягына каранып, эре генә атлап йөри икән, ди. Шулай кукраеп йөргән-йөргән дә, ди, бу, биек койма башына менеп кунаклаган, ди.

— Кикри-күк! Кикри-күк! Мин — шаһ Әтәч, патша Әтәч, мин хан Әтәч, солтан Әтәч! — дип, кычкыра икән,— ди.— Чибәркәйләрем, сөекле тавыккайларым, Карабикәләрем, Чуарбикәләрем, Акбикәләрем! Әйтегезче, матурлардан матур кем матур, батырлардан батыр кем батыр? — дип сорый икән, ди.

Шул тирәдә булган барлык Карабикәләр, Чуарбикәләр, Акбикәләр йөгерә-йөгерә җыелдылар, ди, үзләренең шаһлары, бөек падишаһлары, мактаулы ханнары, куәтле солтаннары янына. Җыелдылар да, ди, болар җырлый башладылар, ди.

— Кая инде, кая инде ул безнең ханыбызга тиң кеше, кая инде, кая инде ул безнең мактаулы шаһыбыз, кая инде, кая инде ул безнең сөекле падишаһыбыз белән тиңләшерлек кеше? Юк, юк, юк, инде ул, ханым-солтаным! Синнән дә акыллы, синнән дә матур, синнән дә батыр юк инде бу дөньяда,— диләр моңа тавыклар.

Әтәч, тагын да көчлерәк итеп:

— Кикри-күк! Кикри-күк! — дип кычкырды да, ди, тагын сорады, ди, болардан:

— Арыслан тавышыннан да көчлерәк тавыш кемдә бар? Кемнең аягы куәтлерәк тә, кемнең кием-салымы зиннәтлерәк?

— Кемнеке булсын, синең киемең зиннәтлерәк, падишаһыбыз, синең аякларың тимердән дә ныграк, солтаныбыз, арыслан дигәннәре синең белән тиңләшә аламы соң, синең тавышың арыслан тавышыннан да гайрәтлерәк! — дип җырлаштылар, ди, тавыклар.

Әтәч масаюыннан шартларга җитте, ди. Шуннан соң кикриген тагын да югарырак чөеп җибәрде дә, ди:

— Кикри-күк! Кикри-күк! Карагыз әле, хатыннар, дөньяда кемнең тәхете биегрәк тә, кемнең башындагы таҗы затлырак? — дип сорады, ди.

Тавыклар, йөгерә-йөгерә, биек койманың янына ук килделәр дә, ди, кукраеп утырган Әтәчкә башларын иеп:

— Тәхетләрдән биек синең тәхетең биек, таҗлардан затлы синең таҗың затлы, синең таҗың бит ул җем-җем итеп тора. Син бит безнең бердәнбер шаһыбыз, син бит безнең бердәнбер падишаһыбыз! — дип әйттеләр, ди.

Шул арада юан пешекче койма артыннан аяк очларына гына басып килде дә, ди, Әтәчне эләктереп тә алды, ди.

— Менә бәла! Менә кайгы!

Пешекче куәтле патшаны, аягыннан тотып алып, койма башыннан сөйрәп төшерде дә, билениннән пычагын алып, бөек шаһның башын чабып өзде дә, ди, мактаулы ханның зиннәтле киемнәрен йолкып ташлап, җиңелмәс солтанның итеннән тәмле шулпа пешерде, ди.

Кунаклар ашыйлар-ашыйлар икән дә ашны мактап куялар икән:

— Ай-яй, тәмле дә икән әтәч шулпасы! Ай-яй, симез икән бу әтәч! — дип әйтәләр икән, ди.

Биремнәр һәм сорау

1. Әкияттәге әтәч образының чын әтәчкә охшаган сыйфатларын табыгыз.
2. Әкияттәге әтәчнең кешеләргә охшаган сыйфатларын әйтегез.
3. Әкият авторы безгә нәрсә әйтә?

Кыңгыраулы тычкан баласы

Борын-борын заманда Чичи исемле бер тычкан баласы яшәгән. Ул муенына асып кечкенә генә кыңгырау йөртә икән. Йөгергәндә кыңгырау чың-чың-чың чыңлый торган булган.

Бермәлне Чичи, бодай ашарга дип, салам чүмәләсе астына кергән. Тамагын туйдыруын туйдырган, ләкин кыңгыравын югалткан. Бик борчылган тычкан баласы. Кыңгыравымны ничек табыйм, дип озак баш ваткан. Табарсың, тапмый ни, кыңгырау менә моның кадәр генә, ә чүмәлә әнә никадәр бит! Шулай дип уфтанган да, Учак янына киткән.

— Учак, Учак күмереңне бир әле!

— Нишлисең ул күмер белән?

Салам чүмәләсе астында кыңгыравымны югалттым. Чүмәләне яндырам.

Учак Чичигә кул гына болгаган.

— Синдәй бала-чага кулына утлы күмер тоттырырга ярыймы соң? — дигән.

Чичи Елга янына килгән.

— Елга, Елга, бер генә уч су бир әле!

— Нишләмәк буласың бер уч су белән? Учак күмер бирмәде, утын сүндермәкче булам.

— Юк-юк, синең ише бала-чагага су бирмим мин.

Шуннан соң Чичи далада утлап йөрүче ишәкләрне эзләп тапкан.

— Ишәкләр, ишәкләр, Елга суын болганчык итегез әле?

Аптыраганнар ишәкләр:

— Нигә дип болгатыйк чиста Елганы? — дип сораганнар.

— Елгадан бер уч су сораган идем, бирмәде!

— Үзебез суын эчә торган елганы болгатып пычратырга тилеме әллә без!

Тәмам хәлдән тайган тычкын баласы. Балалардан ярдәм сораган:

— Малайлар, малайлар, таякларыгыз белән шул ишәкләрне тәпәләгез әле. Елга суын болганчык итегез әле, дип үтенгән идем, баш тарттылар.

— И ахмак. Тычкан баласы сорый дип ишәкләребезне кыйнарга син безне кем дип беләсең? Алар безгә урманнан утын ташыйлар бит.

Чичи, аптырагач, малайларның әниләренә:

— Апалар, апалар. Улларыгызны ачуланыгыз әле. Алар ишәкләрен тукмамыйлар,— дип ялварган.

— Бер нәни тычкан баласы сорый дип балаларыбызны ачуланырга тиле түгел бит без,— дип җавап биргәннәр балаларның аналары.

Биремнәр

1. Тычкан баласының хатасын әйтегез.

2. Әкиятне тәмамлагыз.

ТЫЛСЫМЛЫ ӘКИЯТЛӘР

Тылсымнар катнашы белән иҗат ителгән әкиятләргә **тылсымлы әкиятләр** диләр. Ә «тылсым» сүзе уйлап чыгарылган могҗизаны аңлата. Әкиятләрнең бу төрендә уңай каһарман үзеннән күпкә көчле дошманнарын җиңеп чыга. Һәм аңа күп очракта бер карт, бер карчык, елан, песи, балык, хайваннар, җәнлекләр яки кош-кортлар ярдәм итә.

Унөч

Бер кешенең булган, ди, унөч улы. Кечесенә кушкан бу Унөч дигән ат. Көннәрдән бер көнне уллары әтиләреннән эшкә китәргә рөхсәт сорыйлар. Әтиләре рөхсәт бирә, болар китәләр. Йөриләр, йөриләр, йөри торгач, гел икенче патшалык җиренә чыгып китәләр. Ялла, чалар бу патшага утын кисәргә. Хезмәт хаклары кеше башына бер тиен ярым була. Абыйлары көнетөне урман кисәләр, ә безнең Унөч патша йортында кала. Пешекченең юынтык суларын түгә, бәрәңге әрчи, утын кисә, ашый-эчә бу туйганчы, тазара. Абыйлары моннан көнләшә башлыйлар.

— Без монда чебен-черки, озынаяк арасында иза чигәбез, ул симереп ята,— диләр болар.— Әйдәгез, Унөчне булдыра алмастай берәр эшкә кушыйк.

Болар патшага кереп әйтәләр:

— Безнең Унөч дию пәриенең айгырын алып кайтып бирә ала, җибәр шунда,— диләр.

Патша Унөчне чакыра да әйтә:

— Син,— ди,— шундый-шундый батыр икәнсең, дию пәриенең айгырын алып кайтып бир әле,— ди.— Югыйсә сиңа асылу да киселү,— ди.

Унөч елап-елап чыгып китә. Бара торгач, очрый бу бер әбигә. Әби сорый моннан:

— Улым, нигә болай елыйсың? — ди.

— Әй әби, ничек еламыйсың, миңа патша дию пәриенең айгырын алып кайтырга кушты. Алып кайтмасаң, асылу да киселү сиңа, диде. Мин ул айгырны ничек алып кайтыйм? — ди.

Әби әйтә:

— Елама, улым, елама. Менә сиңа бер көзге, менә сиңа бер тарак. Барырсың да керерсең. Сине күрүгә, айгыр кешнәр дә акырыр. Шулвакыт син печән астына керерсең. Дию пәрие чыгар, ул кереп киткәч, айгырны барып тотарсың.

Унөч боларны ишеткәннән соң сөенә-сөенә чыгып китә.

Барып керә дию пәриенең айгыры янына. Айгыр бик яман кешнәргә тотына. Безнең Унөч елт печән астына. Килеп чыга дию пәрие. Карый, беркем дә юк. Дию пәрие керә дә китә. Унөч чыга да айгырны тотмакчы була. Айгыр тагын кешнәргә тотына, дию пәрие тагын килеп чыга. Карый, бернәрсә юк. Дию пәрие бик каты ачулана:

— Нәрсәгә шулхәтле акырасың, беркем дә юк бит! — ди.— Алдакчы икәнсең син. Моннан соң кешнәсәң дә чыкмам инде,— ди. Унөчкә шул гына кирәк тә инде. Айгырны тотып атлана да чыгып чаба бу. Дию пәрие сизә бит моны. Иң шәп атларына атлана да куа китә. Дию пәрие куып җитәм генә дигәндә, таракны ыргыта бу. Тарак калын урман була. Дию урманда буталып яткан арада, тагын байтак юл ала безнең Унөч. Икенче тапкыр куып җитәм дигәндә, ыргыта бу көзгене. Көзге була бик зур дәрья. Дию пәрие бу дәрьядан чыга алмый, теге якта Унөчкә бармак янап кала.

Хәзер безнең Унөч патшага айгырны алып кайтып бирә дә, котылдым, дип тыныч кына яши инде.

Шулай рәхәт кенә торганда, абыйларының башына тагын бер уй төшә. Тагын патшага керәп әләклиләр:

— Безнең Унөч сиңа дию пәриенең юрганын алып кайтып бирәм дип әйтә бит,— диләр. Патша Унөчкә әйтә:

— Син миңа дию пәриенең юрганын алып кайтып бирәм дип әйтәсең икән. Озакка сузма, тизрәк алып кайт,— ди.

Унөч чыгып китә елый-елый. Юлда тагын теге әби очрый.

— Ник елыйсың, улым? — ди.

— Әй әбекәем,— ди Унөч,— ничек еламыйсың? Патша миңа дию пәриенең юрганын алып кайтырга куша бит,— ди.

Әби әйтә:

— Елап эш чыкмас, улым,— ди,— елама син,— ди.— Менә сиңа бер капчык. Шул капчыкка кырмыска түмгәген тутыр да дию пәриенең өй эченә аудар,— ди.

Безнең Унөч китте шулай капчыгына кырмыска тутырып. Барып җитте дию пәриенең йортына. Йорты читәннән үргән икән. Читән ярыгыннан өйалдына керде дә, сиздермичә генә өй ишеген ачып, капчыкның авызын чиште. Бөтен өй эченә кырмыска тулды. Дию пәриенең йоклар-йокламас яткан чагы икән, менә тотынды хатынына ачуланырга:

— Юрган борчалап беткән, йокы мазасы бирми, көне буе тик ятасың, шуны да карамыйсың,— ди, юрганны тибеп

төшерә. Тик алай гына котыла алмый бу. Моны кырмыска бөтенләй сарып ала. Шуннан соң ул ачуланып юрганны өйалдына чыгарып ташларга куша.

Безнең Үнечкә шул гына кирәк тә бит. Ул юрганны элә дә, әйдә патша сараена. Моның абыйлары бик гаҗәпләнәләр. «Бу нинди утта янмас, суда батмас малай булды бу!» — диләр. Патшага кереп әйтәләр:

— Безнең Үнеч сиңа бу юлы дию пәриенең үзен алып кайтып бирәм дип шапырына,— диләр.

Патша тагын моны чакыра да әйтә:

— Син миңа дию пәриен алып кайтып бирәм дип әйтәсең икән, андый ниятең булгач, озакка сузма инде син аны,— ди.

Үнеч тагын чыгып китә елый-елый. Тагын моңа әлеге әби очрый.

— Ник елыйсың, улым? — ди.

— Әй әбекәем, ничек еламыйсың,— ди Үнеч әйтә,— миңа патша дию пәриенең үзен алып кайтырга куша бит,— ди.

Әби әйтә:

— Елап эш чыкмас, улым,— ди,— елама син,— ди.— Менә сиңа балта. Дию пәриенең урманына бар да агач кисә башла. Дию пәрие чыккач, Үнеч үлгән, шуңа табут ясыйм, диярсең. Ул да сиңа булышыр. Син шунда аны табутка кертергә тырыш,— ди.

Безнең Үнеч сөенә-сөенә чыгып китте. Дию пәриенең урманына барып җитте дә шак-шок агач кисә башлады. Килеп чыкты дию пәрие. Кычкыра моңа:

— Нишлисең? Нигә рөхсәтсез минем урманымны кисәсең?

Үнеч әйтә:

— Син кычкырма, Үнеч үлгән бит. Шуңа табут ясыйм,— ди.

Дию пәрие моңа бик шатлана. «Мин дә ясашам!» — дип, балталар, пычкылар алып чыга. Болар икәүләшеп табут ясарга тотыналар. Табутны бик нык итеп ясыйлар. Ясап бетергәннән соң, Үнеч әйтә:

— Беләсеңме, Үнеч синнән куәтлерәк бит. Син кереп ятып кара әле. Сиңа түзмәсә, Үнечкә түзми дә түзми инде ул,— ди.

Дию пәрие кергә, табутны шартлатып кадаклап куя бу. Дию пәрие эшне сизенеп ала да менә тотына акырырга, менә ерләшә. Тик барыбер табутны ватып чыга алмый. Үнеч табутны арбага сала да кайтырга чыга. Дию пәрие һаман тавышлана, һаман тыпырчына...

Табутны тарттырып кайтып китә Унөч патша сараена. Патшаны чакырып чыгара да әйтә:

— Менә, синең кушуың буенча, дию парием алып кайттым, хәзер табутны ачып чыгарам,— ди.

Патшаның коты чыга:

— Юк, юк, чыгарма, кирәкми! — ди.

Унөч әйтә:

— Син үзең алып кайтырга куштың бит, хәзер чыгарам,— ди.

Патша хәзер ялына башлый:

— Унөчкәем, зинһар, чыгара күрмә. Кызымны бирәм, ярты патшалыгымны бирәм, дию парием генә чыгарма,— ди.

Шулай итеп, патша Унөчкә кызын биреп, ярты патшалыгын бирде, ди. Абыйлары үзләренең көнчелек белән энеләрен харап итәргә йөрүләренә бик үкенгәннәр, калган гомерләрен үзара бик тату яшәгәннәр.

Бүген бардым, кичә кайттым, уйнадык-көлдек, ашадык-эчтек, мыеклар майланды, тамакка эләкмәде.

Әкияткә анализ ясыйк

Әкият вакыйгаларга бүленә. Унөч баланың эшкә чыгып китүе — әсәрнең кереше генә. Ә төп вакыйга — абыйларының, Унөчтән көнләшеп, патша аркылы аңа үтәп булмаслык эш кушуы. Бу вакыйга өч тапкыр кабатлана, шуңа күрә аңа «Көнчелек» яки «Явызлык вакыйгасы» дип исем кушыйк.

Әкияттә бер әби Унөчкә өч тапкыр ярдәм итә. Бу вакыйга да — мөһим вакыйга, чөнки әби ярдәм итмәсә, каһарманыбыз патша кушканнарны үти алмас иде. Өч ярдәм вакыйгасын бергә генә калдырып кушыйк та аңа «Ярдәм» дип исем бирик.

Өченче мөһим вакыйга — Унөчнең диюне өч тапкыр җиңүе. Аларны да кушып бергә генә калдырыйк һәм «Җиңү» дип исем бирик.

Әкиятләр һәрвакыт явызлыкка җәза биреп тәмамлана, дигән идек. Бу әкияттә Унөч артык юаш холыклы егет булган, күрәсең, абыйларын оялту белән генә канәгатьләнгән. Ә абыйлары, әкияттә әйтелгәнчә, «энеләрен харап итәргә йөрүләренә бик үкенгәннәр». Уйлый белгән кешегә анысы да шактый авыр җәза.

Әкият дүрт өлешкә бүленде. Кабатланган вакыйгаларны бергә генә калдырып гомумиләштерәбез дә тылсымлы әкиятләрнең төзелеше явызлык — ярдәмчеләр — җиңү — җәза өлешләреннән гыйбарәт, дип нәтиҗә ясыйбыз.

Алтын алма

Бер патшаның алтын алма үстерә торган бакчасы булган. Ул алтын алма ел саен булмый, ә өч, ун елга бер генә була икән. Алтын алма бит ул, мондый гына түгел. Бу патшаның өч малае бар. Бик зур патша бу. Бу патша, мин сиңайтим, алтын алма өлгергәч, каравылчы куйды. Алтын алманы патша санап карый, ике алмасы югалган була. Каравылчы алманы югалтты бит. Патша каравылчыны дүрт-биш елга төрмәгә япты.

Патша хәзер инде бөтен халкын җыйды, мин сиңайтим.

— Менә,— ди,— безнең каравылчы ике алманы урлатты,— ди.— Кем дә кем,— ди,— шушы алманы урлатмаса, без аңа ярты патшалыкны бирәбез,— ди.

Ярый, патшаның өч малае бар, патша малайлары әйтә инде хәзер:

— Без,— ди,— патшалыкны чит кешегә бирмибез, без үзебез каравыл торабыз,— ди.

Патшаның олы малае каравыл тора башлый алмага. Бу малай таң беленгәнче бер дә йокламады. Таң аткач, алманы санады да ятып йоклады. Йокыдан уянгач, алманы яңадан санап карады, элек икәү юк иде, хәзер өчәү юк. Патша малае куркып чыгып качты. Патша, йокысыннан торгач, алманы үзе санап карады: тагын бер алма юк. Алма да юк, малай да юк. Патша бик гаҗәпкә калды да яңадан халкын җыйды.

— Кем дә кем алманы урлатмаса, ярты патшалыкны бирәбез,— ди. Каравыл торучы юк. Хәзер кермиләр, куркалар. Патшаның уртанчы малае тормакчы булды.

— Без өчәү бит,— ди,— патшалыкны кешегә бирмибез,— ди. Патшаның уртанчы улы тора хәзер каравылда. Бу хәзер кичтән таң беленгәнче торды, алманы урларга килүче булмады. Таң беленгәч ятып йоклады бу. Уянгач санап карады, тагын бер алма юк. Моннан соң уртанчы улы да чыгып качты. Алма да юк, малай да юк хәзер. Патша йокыдан торды да алманы санады: алма да юк, малай да юк.

Патша бу эшкә бик гаҗәпләнде. Үзенең кулы астындагы һәркемне — олыны-кечене җыйды. Җыйды да халыктан каравылчы сорый.

— Без,— ди,— патша әйтә, алманы урлатмаган кешегә ярты патшалыгыбызны бирәбез,— ди. Халык риза булмый. Патшаның кече малае әйтә:

— Без,— ди,— патшалыкны кешегә бирмик инде,— ди, — мин үзем керәм, алманы урлатмыйм, каракны тотам,— ди. Патша бу сүзгә ышанмый.

— Икегез тордыгыз бит инде,— ди,— ике абыең да югалды, син дә тора алмассың,— ди. Патшаның кече малае әйтә:

— Мин торам,— ди,— миңа үзем сораган әйберне генә эшләтеп бир,— ди. Бу бик нык сөйләшә.— Миңа унбиш потлы гер ташы койдырып китерт,— ди,— үземнең исемем булсын, синең исемең булсын гер ташында,— ди. Патша малае бик зур куәт иясе инде.

Патша гер ташын койдыртып китерде малайга. Әүвәле башта егет гер ташын, нык микән дип, тез башына сугып карады. Тезенә дә, гер ташына да бернәрсә дә булмады. Аннары сукты ташка: таш тузаннар булды, гер ташына бернәрсә булмады.

Шулай итеп, патшаның кече малае тора башлады хәзер, мин сиңайтим. Ул тегеләрчә тормый. Ул алмаларны санады да ятып йоклады. Таң беленгәч, торды да бу алманы тагын санады, алма шул дүртәү юк көенчә. Кызарып кояш чыга башлагач, мин сиңайтим, бер кош килә моңа. Очып килә, үзе адәм сурәтендә, үзе — кош. Бик зур бу. Очып килә дә алмагачка куна бу. Алмагачка куна да алманы ала башлый. Алманы ала башлагач, гер ташы белән җибәрде егет, гер ташы барып тиде дә егылып төште бу кош, яраланып. Алтын алманы ала алмады. Егылып төште дә кош кеше сурәтенә кереп йөгерә башлады. Моның артыннан, унбиш потлы гер ташы тотып, егет тә йөгерде. Йөгерә торгач, урманда моңа олы абыйсы очрады.

— Менә безнең алманы урлаган каракны тоттым, йөгерик,— ди бу. Болар хәзер икесе бергә куалар инде. Киттеләр, бара-бара боларга уртанчы туганнары очрады.

— Әйдә, алма бурын тоттым,— ди кече туганнары. Болар хәзер өчәү йөгерәләр инде алма карагы артыннан. Бик күп җирләрне узгач, алма карагы кереп китте бер тишеккә. Ул — зур юл икән, шомарып беткән. Болар калдылар шунда. Менә, мин сиңайтим, бер болан йөри шунда. Боланны тотып алдылар да суйдылар болар. Тиресен тунадылар да, нечкәләп телеп, шуны ялгадылар. Ялгап бетергәч, бу җир астына җитәр-җитмәс кенә булып калды. Хәзер патша малайлары киңәш итә. Олы малае әйтә:

— Мин төшәм,— ди.

Уртанчы малае:

— Мин төшәм,— ди. Теге унбиш потлы гер күтәреп килгәне әйтә:

— Сезне төшереп булмый, сез бернәрсә дә булдыра алмыйсыз,— ди. Бу хәзер, мин сиңайтим, унбиш потлы гер ташын тотып йөгергән малай, үзе төшмәкче була: — Төшәм,— ди,— каракны үтерәм,— ди.

Төшеп китте бу хәзер. Төште дә бу як-ягына карана: өч якка киткән юл чаты бар. Өчесенә дә язу кадакланган. Берсенә — «үлем юлы», берсенә — «туклык», тагын берсенә «ачлык юлы» дип язылган. Бу китте «үлем юлы» дип язылганыннан. Кереп китте дә барып җитте бу бер зур йортка. Түрдә бик матур бер кыз утыра икән. Ул кыз белән сөйләштеләр.

Кыз әйтә:

— Каян килдең син, ничек килдең син? — ди, гаҗәпсенә моның килүенә.

Бу патша малае әйтә:

— Мин шундый-шундый юл белән килдем: безнең алтын алма бар, шуны берәү урлый, мин шул алтын алма карагы артыннан аны үтерергә килдем,— ди. Аңарга каршы кыз әйтә:

— Безнең патша, дию патшасы, каядыр барып яраланып кайтты, алманы урлаганын белмим мин аның,— ди,— ул хәзер ярасын бәйләтергә китте,— ди. Малай әйтә:

— Безнең алманы урлаган шул дию инде, мин үтерәм аны,— ди,— мин яраладым аны,— ди. Бу кыз әйтә:

— Без җир астындагы бөтен бакыр хәзинәсенә патша булып торабыз,— ди,— дию — безнең патша ул,— ди. Бу кызга әйтә егет:

— Мин ул диюегезне барыбер үтерәм,— ди. Кыз аның үтергәненә әйбер әйтми, бер кысрыкка китереп, диюнең эшләпәсе эченә яшерә. Кыз әйтә:

— Дию кайтып ятты,— ди,— диюнең башын куеп яткан җире дә таш, кулын куеп яткан җире дә таш,— ди.— Син аңар кереп бер генә сук, ул таралыр да китәр,— ди.— Ул таралуын таралыр, тик таралгач, тагын җыелыр,— ди,— җыелгач, сиңа: «Егет тагын бер сук»,—дип әйтер, син бүтән сукма, җитте шушы, дип кенә әйт,— ди.— Син шулай дип әйткәч, тагын таралып җыелыр, тагын сук дип әйтер, син, җитте, дип әйт. Тагын чәчелеп китәр ул,— ди.

Егет дию йоклаган бүлмәгә керде дә җибәрде гер ташы белән. Диюнең башы тузан булып чәчелеп китте, тагын җыелды. Башы җыелгач, дию әйтә:

— Егет, тагын бер сук,— ди. Егет әйтә:

— Җитте инде сиңа шушы,— ди. Егет болай дигәч, диюнең башы тагын таралды, тагын җыелды, баш булды да, мин синайтим, дию тагын моңа әйтте:

— Тагын сук,— дип. Егет:

— Җитте шушы,— ди. Җитте шушы дигәч, таралып китте моның башы. Диюдән кан ага башлады. Кан бу егетнең тубыгына җитте. Теге кыз әйтә моңа:

— Егет, чык инде,— ди,— хәзер дию үлде инде,— ди. Үтерде бу дию патшасын. Кыз сөйли моңа хәзер:

— Мин,— ди,— җирдәге бөтен бакыр хәзинәсенең патшасы булып торам. Мин сиңа дионе үтергәнлегеңә бакыр мөһер бирәм. Ул бакыр мөһердә синең диюне ничек үтергәнлегең язылган булыр,— ди.— Син шул мөһерне югалтма,— ди,— үзеңә кирәк булыр,— ди. Хәзер бу егеткә тагын әйтә инде кыз:

— Минем апам бар,— ди,— ул җирдәге бөтен көмеш хәзинәсенә патша булып тора,— ди.— Син аңа шушы мөһерне күрсәтерсең, диюне үтергәнлегеңне әйтерсең, ул сиңа, шушының шикелле итеп, көмеш мөһер бирер,— ди.

Бу көмеш патшасына бара:

— Мин сезнең патшагызны үтердем,— ди. Теге кыз бакыр мөһерне укып карый. Монда диюнең ничек үтерелүе, алма урлавы — барысы да язылган. Кыз хәзер моның кулына көмеш мөһер бирде. Анда, бакыр мөһердәгечә, барысы да язылган. Бу кыз әйтә:

— Безнең җирдәге бөтен алтын хәзинәсенә патша булып торучы апабыз бар. Ул сиңа алтын мөһер бирер, нишләргә кирәген дә әйтер,— ди.

Егет хәзер алтын патшасы булып торган кызга бара. Кыз мөһерләрдән карый, барысын да күрә инде. Бу хәзер моңа алтын мөһер бирә. Егеткә әйтә теге кыз:

— Хәзер безнең патша бетте инде, син безне моннан алып чык,— ди. Егет боларның өчесен дә алып китте.

Болар чыга торган юлга килделәр. Тегеннән патша малайлары бау төшерделәр. Иң элек менгерделәр бакыр патшасының кызын. Патша малайлары, моны күргәч:

— Миңа да миңа,— диләр инде. Тик егет түбәннән кычкырды:

— Тагын җибәр бауны,— ди. Тагын җибәрделәр бауны. Хәзер менгереп җибәрде бу көмеш патшасының кызын.

Моны да тартып алдылар, монысы менгәч, тагын, мин сиңайтим, ызгыш-талаш китте. Бусысы бигрәк тә матур бит. Тагын җибәрделәр моңа бауны. Егет менгереп җибәрде алтын патшасының кызын. Бик матур кыз инде бу. Бу чыккач, патша малайлары арасында тагын талаш-ызгыш китте: «Бусы миңа, бусы миңа»,— дип. Болар хәзер бөтенләй калдырып китәләр инде егетне, алмыйлар. Өч кызны алдылар да киттеләр. Кызларга энеләренең монда калганын әйтергә кушмыйлар инде. Егетләр кайткач әйтәләр:

— Алманы урлаган диюне без тоттык, аны үтердек, менә шундагы патша кызларын коткардык,— диләр.

Ярар, бу егет калды бит инде җир астында. Язуны укып карады да хәзер «ачлык юлы» белән китте. Барадыр иде, бер зур йортка барып җитте. Бер сукыр карчык белән сукыр карт кына бу йортта, башка беркем дә юк. Егет сукыр карчык белән сукыр картка әйтә:

— Сез ялласагыз, мин сезгә хезмәткә керәм,— ди. Сукыр карчык белән сукыр карт әйтәләр:

— Без сине ялларбыз, бик яхшы хезмәт итәрсең, безнең сүзне тыңларсың,— диләр. Бу әйтә:

— Мин сүзегезне тыңлармын, яхшы хезмәт итәрмен,— ди. Боларның мал-туарлары күп икән. Егетне хәзер көтүче итәләр. Сукыр карт өйрәтә:

— Син, улым,— ди,— уңга киткән юлга да барма, турыга киткән юлга да барма, син,— ди,— сулга киткән юлга бар,— ди.— Тегеләре безнең җир түгел, дию патшасының җире,— ди.

Мал-туарны алып чыгып китте егет. Картның барма дигәненә карамады, туры юлдан китте. Бара торгач, моның сыерлары дию патшасының иген басуына барып чыкты.

Кич булды да, бу малларын алып кайтты. Малларының чит җиргә барганын картлар белделәр:

— Син ялгыш дию патшасының җиренә чыккансың, безне гаепле итәрләр, төрмәгә ябарлар,— дип, бик курыкты болар.

Егет аларга:

— Курыкмагыз, бернәрсә дә булмас,— ди. Дию патшасын үтергәнен әйтми әле. Икенче көнне бу тагын алып чыгып китә малларны. Карт ачулана:

— Син, чит патша җиренә кереп, безгә зур түләүләр салдырырсың. Ник без әйткәнне тыңламыйсың? — ди.

Хәзер егет өченче көнне әйтә теге картка:

— Сез, бабай, ник сукыр булдыгыз,— ди,— сезне терелтергә дәва юкмы икән соң? — ди.

Карт әйтә:

— Моңа дару бар барын,— ди.— Син уңга да китмә, сулга да китмә, туры юлдан бар. Бер зур йортка барып җитәрсең. Ул йорт астыннан ике чишмә чыгар, аның берсе — үле суы, берсе тере суы булыр. Без шул тере суы белән юынсак, әүвәлгедән дә матур булып терелербез, күзләребез ачылыр иде,— ди.

Бу егет, мин сиңайтим, картка әйтә:

— Мин, бабай, бүген малларны алып бармыйм инде, тере суы алып кайтыйм да сезне терелтим,— ди.

Бу зур йортка барып җитте, йорт астыннан ике чишмә чыгып тора. Моның берсе — үле суы, икенчесе — тере суы. Анда каравылчылар бар иде. Каравылчыларны бәреп екты да тере суыннан су алды, битен юды: әүвәлгедән дә әйбәтрәк, матуррак егет булды. Суларны тутырып алды, мин сиңайтим, икесен дә.

Кайтырга чыкты. Кайтып килә иде бу, моның кайткан юлында, кеше дә түгел, агач та түгел, шундый нәрсәләр бар. Бу, боларга гаҗәпсенеп, берсенең тамырына пычак тидереп караган иде, кан чыкты. Шул канга тере суын тидергән иде, бу агач солдат булды. Солдат болай ди:

— Без,— ди,— бу сукыр картның гаскәре, бу сукыр карт безнең патшабыз иде. Дию патшасы аны сукырайтты. Менә мондагы агачлар барысы да патшаның гаскәрләре, аларны дию сихерләп шулай итте,— диде. Бу егет әйтте:

— Мин дию патшасын үтердем, бетте ул хәзер дию,— диде. Болар хәзер солдат белән икесе агачларга тере су тидереп йөриләр, тидергән берсе солдат була. Шулай итеп, монда бер полк гаскәр терелде.

Гаскәр белән болар инде, мин сиңайтим, сукыр картка киттеләр. Моны ишетеп, сукыр карт куркып качты. Бу барып керде. Карчык әйтә:

— И улым, харап иттең син безне,— ди. Егет әйтә:

— Юк, әби, курыкма, бу сезнең үзегезнең гаскәрегез,— ди,— мин сезгә тере суы алып кайттым, юыныгыз,— ди.

Болар юындылар. Хәзер әүвәлгедән дә матуррак булып терелделәр. Егет әйтә:

— Мин дию патшасын үтердем,— ди. Тегеләргә мөһерләрен күрсәтә. Бу патша хәзер әйтә:

— Син,— ди,— бу җиргә патша булып тор, дию патшасы урынына,— ди. Егет әйтә:

— Юк,— ди,— мин патша булмыйм, мин үзем патша малае,— ди,— мине бу җирдән чыгаруыгызны үтенәм,— ди. Хәзер моңа карт әйтә:

— Без сине чыгарырбыз чыгаруын,— ди,— нәрсә белән разый итеп чыгарыйк икән соң? — ди. Егет әйтә:

— Миңа сезнең бернәрсәгез дә кирәк түгел,— ди,— мине чыгарыгыз гына,— ди. Бу карт әйтә моңар:

— Менә сиңа алты колачлы ала бия. Син шуңа «алты колачлы ала биям» дип әйтсәң, ул синең дөньяда нинди мохтаҗың бар, һәммәсен дә үтәячәк,— ди.— Син,— ди,— атка атлангач, «алты колачлы ала биям» дисәң, күз ачып йомганчы үзегезнең җирегездә булырсың,— ди.

Егет алты колачлы ала биягә менеп атланды. Күзен ачып йому белән, үзенең җиренә кайтып җиткән булды. Үзләренең шәһәрләрендәге иң кырыйдагы өйдә яшәүче бер тегүчегә керде бу. Тегүчеләргә әйтә:

— Мин сезгә ялланып, үтүк кыздырып-нитеп торыйм,— ди. Тамак ялына керә инде бу шунда.

Патша туйга хәзерләнә икән. Ул малайларына тегеннән кайткан кызларны алмакчы була. Бу кызлар тегендә киеп йөргән киемнәрен сорыйлар икән:

— Шундый киемнәр булмаса бармыйбыз,— диләр икән. Болар сораганны, мондый киемне бер тегүче дә тегә алмады. Патша шәһәр читендәге тегүчеләргә килде. Патша малае әйтте тегүчеләргә:

— Патша тегү тектерергә килгәч, иң элек сез ул китергән әйбердән үзегезгә нинди кием кирәк, шуны тегеп киегез,— ди.

Патша килә боларга. Китергән бер әйбердән үзләренә тегәләр болар. Егет хәзер әйтә:

— Сезгә кием җиттеме хәзер? — ди. Тегеләр әйтәләр:

— Безгә бер кат булды инде,— диләр.

— Сез,— ди,— патша килгәч, акчаны куркып сорамагыз, хезмәт хакын икеләтә-өчләтә сорагыз,— ди.

Хәзер бу әйтә алты колачлы ала биягә:

— Хәзер син,— ди,— көмеш патшасының, бакыр патшасының, алтын патшасының үзләренең тегендәге киемнәрен китер,— ди. Алты колачлы ала бия алып кайтты тегеләрнең киемнәрен. Кайтарып элеп куйды.

Хәзер патша килүгә, өч кызның өч киеме әзер. Бик яхшы киемнәр инде болар. Патша киемнәрне алып кайтып күрсәтә инде. Кызлар киемне яраттылар, егетнең кайтканын сизделәр болар. Бу киемнәрне башка кеше алып кайта алмый бит инде. Хәзер патша туй ясый. Кызлар, кием булгач, бармакчы булалар булуын, шулай да көттерәләр. Шәһәрдәге халык җыела. Ләкин кызлар һаман:

— Килмәгән кеше бар әле,— диләр. Шуннан әйтәләр тегүчеләргә:

— Сездә бер тегүче егет бар иде, ул килдеме? — диләр.

Тегүчеләр әйтә:

— Килмәгән әле,— диләр. Хәзер, мин сиңайтим, патшаның килен буласы кызлары кеше җибәртеп алдыралар бу егетне.

Бу егет яхшы киемнәрен киеп кереп утырды. Бөтен мәҗлес шаккатты моңа. Теге кызлар барысы берьюлы эчемлекләрен китереп бирәләр моңа. Туйга җыелган халык бик гаҗәпсенде. Монда чит патшалар да бар бит инде. Бер патша әйтә:

— Нинди патшалар килде, бу кызлар берсен дә болай сыйламадылар, соңга калган егет килеп керүгә, өчесе берьюлы эчемлек китереп бирделәр. Бу нинди кеше аралау? — ди, үпкәлисе килә инде тегенең. Аңарга алтын патшасы булып торган кыз җавап бирә:

— Сез, моңа шаккатмагыз,— ди,— бу егет дию пәриен үтереп, шушы кадәр җирләрдән безне коткарып алып чыкты. Бу — безнең аталарыбыз, аналарыбыз кебек кадерле кеше. Ул егет риза булмаса, без патша малайларына бармыйбыз,— ди.

Хәзер бу егет әйтә:

— Мин,— ди,— бу кызларны нинди азаплар күреп коткардым,— ди.— Мин болай азап та күрмәс идем, абыйлар мине шушы кызлар белән бергә чыгарсалар,— ди.— Мине чокырда калдырып кайтып киттеләр. Алтын алма карагын үтерүче мин,— ди.— Мин аларга үзләре шикелле катылык кылмыйм, алтын патшасы булып торган кыз миңа, көмеш патшасы булып торган олы абыйга, бакыр патшасы булып торган кыз кече абыйга. Шулай булганда, туй ясарга риза булам,— ди.

Моңа патша ышанып бетми. Егет алтын мөһерне, көмеш мөһерне, бакыр мөһерне чыгарып салды: мөһердәге язуларны бөтенесе укып карадылар. Дөрес, дию патшасын үтергәнлеге язылган. Атасы моннан соң да ышанмый. Моңар тегүчеләр-

дәге унбиш потлы гер ташын китерделәр, анда аның үзенең дә, улының да исеме язылган. Патша шуннан соң гына ышанды. Бу туйны ясап, өч кыз өч малайга булды. Патша урынына кече малай калды.

Биремнәр

1. Әкиятнең төзелешен табыгыз: дүрт кенә вакыйгага калдырып гомумиләштерегез.
2. Тагын да гомумиләштерә төшеп, ике генә өлешкә калдырыгыз.
3. Әкиятне иҗат итүчеләр уйлап тапкан тылсымнар турында сөйләгез.
4. Өйдә үзегез әкият уйлап языгыз. Бер дә булмаса, туганнарыгыздан, алар әкият белмәсәләр, башка өлкән кешеләрдән әкият сөйләтегез һәм алар сөйләгәнне мөмкин кадәр тулырак итеп язып алыгыз.

   Үзегез язсагыз, төп каһарманны уйлап табыгыз. Ул хикмәтле булырга тиеш. Камырдан дияр идек — андый әкият бар. Тимер каһарман бар, оста йөгерүче дә, оста атучы да, үзе кешегә, үзе сарыкка охшаган шүрәле дә бар... ә сез хикмәтле әкият каһарманын үзегез уйлап табыгыз. Әкияттә кемдер, нәрсәдер югалтырга тиеш. Төп каһарманның аны эзләргә китүен беләсез. Хәер, сез бит башкача да уйлый аласыз.

Нәтиҗә:

Без ике тылсымлы әкият белән таныштык. Икесендә дә бөтенләй бүтән дөнья вакыйгалары матурлыгын күрдек. Әкиятләрнең сюжетлары төрле булсалар да, төзелешләре уртак икән. Әкиятләрнең икесендә дә явызлык җиңелде, хаклык тантана итте.

ӘДӘБИ ЖАНРЛАР

МӘСӘЛЛӘР

Күпчелек мәсәлнең катнашучылары: хайваннар, кошлар, бөҗәкләр. Алар, үз сыйфатларын саклап калган хәлдә, кешечә сөйләшәләр, кешеләр кебек җырлыйлар, хәйләлиләр, алдашалар. Без, хайваннар, кошлар турында укысак та, аларда кешеләр холкын күрәбез. Мәсәл жанрының бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт. Башка үзенчәлекләрен мәсәлләргә анализ ясап табыйк.

Габдулла Тукай

Ике эт

Баеның хезмәтеннән бер дә ялыкмаган хыянәтсез Муйнак, иске дусты Актырнакның һәйбәт мендәрдә, тәрәзә төбендә утырганын күргәч, янына килеп, каннары кайнап, күзләрен яшьләндереп, тәрәзә янында койрыгын болгап, сикереп куя.

Актырнакның рәхәтенә көнләшеп сораша башлый:

— Йә дус, нихәл? Кәефләр хушмы? Карап-карап торам: сине бөтенләй боярлар шикелле кадерли башлаганнар. Исеңдәме? Кайчан гына әле син дә, мин дә, ачлыктан аз гына үлмичә, абзар каравыллый торган идек,— дигәч, Актырнак, җавапка керешеп:

— И дус! Мин хәзер бик бәхетле, миннән Хуҗа һәм аның хатыны үзләренең җаннарын да кызганмыйлар; шөкер Ходага, байлыкта, рәхәттә торамын, алтын-көмеш табаклардан гына ашыймын, ашап туйгач кәефләнәм, Хуҗа хатыны белән уйный башлыйм. Арысам, хәтфә паласларда, йомшак көрсиләрдә[1] ятып ауныймын,— дип, үз бәхетен сөйләп тәмам иткәч: — Ә син, Муйнак, ни хәлдә торасың? — диде. Муйнак та үз хәлен сөйләде:

---

[1] Көрси — диван.

— Минем тормышым һаман үзең күргәндәге шикелле: суыкка да түзәм, ачлыкка да чыдыйм, Хуҗамның йортын саклап, ачык һавада яңгырларга да чыланам. Әгәр вакытсызрак өрсәм, башыма таяк та кабул итәм. Мин гаҗәпләнәм, Актырнак дус, син үзең көчсез һәм кечкенә булып та, бу кадәр бәхеткә, бу чаклы рәхәткә ничек ирештең? — дигәч, Актырнак, янә сүзгә керешеп, көлемсерәп:

— И дустым! Кеше бәхетенә көнләшү гөнаһтыр. Беләмсең, мин, арт аяк белән йөри алганым өчен, шулай бәхетле булдым,— диде.

Мәсәлгә анализ ясыйк

Мәсәл, «Бәхетле эт» һәм «Бәхетсез эт» дип, каршы якларга бүленә. Хәзер өлешләрне берәм-берәм өйрәнәбез.

Актырнак ни өчен бәхетле?

«Мин бәхетле» дип, Актырнак үз тормышына үзе бәя биреп мактана.

Бәхетенең сәбәпләрен санап чыга. Ләкин мактанган саен дәрәҗәсе төшә бара, чөнки Актырнак санап күрсәткән сәбәпләр аның эшсезлеге, ялкаулыгы, ялагайлыгы турында сөйлиләр. Шулай итеп, Актырнак әйткән уңай сыйфатлар кире сыйфатларга әйләнәләр.

Муйнак сыйфатларын өйрәник.

Муйнак, киресенчә, авыр тормышта яшәвен сөйләп зарлана. Зарланган саен укучы өчен аның дәрәҗәсе күтәрелә генә бара. Ул урамда туңса да, ачлы-туклы яшәсә дә эшли. Эт башкарырга тиешле вазифасын башкара.

Күрәбез, мәсәлнең төзелеше үзенчәлекле: аның беренче өлешендә төп каһарман мактана да мактана. Мактанган саен үзен үзе фаш итә. Икенче өлештәге персонаж, киресенчә, мескенлеге турында дәлилләр китерә-китерә зарлана. Ләкин зарланган саен үзенең хуҗасына тугрылыклы хезмәт итүче эт булуын раслый.

Нәтиҗә:

1. Мәсәл жанрының иң мөһим үзенчәлеге — яхшылык эчендә начарлык, начарлык эчендә яхшылык ятуын күрсәтеп бирү.

2. Мәсәлнең тагын бер үзенчәлеге: автор соңыннан мәсәл эчтәлеген үзе әйтеп бирә.

3. Кайбер мәсәлләрдә хайваннар белән бергә кешеләр дә катнаша. Ләкин мәсәлнең яраткан персонажлары: хайваннар, кошлар. Мәсәлчеләр җансыз предметларны да төп каһарманнар итүдән баш тартмыйлар.

Кемнәр, нәрсәләр турында язса да, мәсәлче барыбер шулар аша кешеләрнең нинди дә булса кимчелегеннән көлә.

Гадәттә, мондый мәгънә күчешенә **аллегория** диләр.

Габдулла Тукай

Мәрхәмәтле Төлке

Аучы яз көнендә Карлыгачны атып үтерде. Бу бәхетсезлек Карлыгачның үлүе белән генә бетмичә, бичараның артында ике-өч баш яңа гына йомыркадан чыккан балалары калды.

Мескен балачыклар, аянычлы вә авырттыра торган тавышлары илә черелдәп, уянмас йокыга киткән аналарын уятырга тырышалар иде...

Берзаман Төлке бу ятимнәрнең оясына якын килеп, шул оя яныннан үткән һәрбер коштан бу үксезләргә мәрхәмәт итүләрен сорап, суфиланып утыра иде.

Югары очкан Тургайга карап: «И син, Тургай! Юкка буш һаваларда канат талдырып әйләнгәнче, бу атасыз-анасыз балаларга игенлекләрдән, кырлардан бер-ике бөртек орлык булса да китереп бирсәң, нинди савап булыр иде!» — дия иде.

Шул тирәдә генә йөргән бер Чәүкәгә дә: «И Чәүкә дус! Синең балаларың үсеп, әллә кайчан зур булдылар, инде алар үзләре үзләренә җитәрлек азык таба алырлар. Син инде менә бу тәрбиячеләре булмаган Карлыгач балаларына ана бул, аларны җылы мамыгың белән җылыт».

Шуннан пырхылдап очкан Чыпчыкка да: «Юкка чырылдап, пырылдап йөргәнче, күз алдындагы бәхетсез кошчыкларга чебен, чикерткә аулап ашатсаң, хисапсыз әҗерләр алыр идең. Анасызларга ана булып торсаң, боларның анасызлык кайгыларын оныттырыр идең»,— дия иде.

Кыскасы, көннәр үтә. Белмим, Төлкенең нәсыйхәтләрен тыңлаучы булдымы, юкмы? Әмма баягы ятим кошчыклар берзаман Төлкенең авыз төбенә үк егылып төштеләр. Төлке үзенең авызына төшкән бичара кошчыкларны кычкыртып, черелдәтеп ашады да китте.

«Укучы! Исең китмәсен, кем ки, яхшылык хакында сөйләп, кешеләрнең колагын тондырса, бел ки, ул кеше икенче берәүнең кесәсеннән генә яхшылык итәргә яратучы буладыр.

Ул яхшы белә ки, аның үзенә ул яхшылыктан бер тиен дә зарар килми, әмма үз өлешенә бер изгелек итәргә тугры килсә, ул бөтенләй ушбу Төлке кеби буладыр».

Бирем

Мәсәлгә анализ ясагыз.

ХИКӘЯЛӘР

Хикәяләр — мәсәл кебек кечкенә күләмле, ләкин повесть кебек сюжетлы әсәрләр.

Бөек татар шагыйре Һади Такташның «Хикәяне ничек язарга?» дигән мәкаләсен (6 нчы сыйныф дәреслеге) хәтерлисездер. Мәкаләдә ул хикәя язучыга түбәндәге шартларны куя: хикәядә сурәтләнгән төп геройның үзенчәлекле холкы булырга тиеш. Ә аның холкы сюжет эчендә, сәнгать чаралары ярдәмендә ачыла, ди Һади Такташ.

Димәк, сюжет иң беренче чиратта ул геройның холкын һәм дөньяга карашын ачу өчен кирәк икән.

> **Искә төшерик:**
>
> Кешенең **холкы** дип аның даими сыйфатларына әйтәләр. **Сюжетның** дәвамлы вакыйга булуын да яхшы беләсез.
>
> Сюжеттагы вакыйгалар башлана, төенләнә, киеренкелеге арта-арта иң югары ноктасына җитә һәм кинәт чишелә, дип өйрәндек.

Хикәя сюжетындагы үзгәрешләр персонажлар хисен дә үзгәртә. Ә үзгәргән хисне без күңелдәге хисләр вакыйгасы дия алабыз. Әйдәгез, сюжет вакыйгасын — **тышкы вакыйга**, ә күңелдәге хисләр үзгәрешен **эчке вакыйга** дип атыйк.

> Хикәя жанрының тагын бер мөһим үзенчәлеге анда сюжет вакыйгалары тудырган эчке вакыйгалар булудан гыйбарәт.

Хикәядә дә, шигырьдәге лирик герой кебек, үзе турында сөйләүче персонаж катнашырга мөмкин. Шигырьдә аны **лирик герой** диләр. Ә хикәядә ул үз кичерешләре турында сөйләү белән генә канәгатьләнми. Вакыйгалар агышын да, башка

персонажларның холкын, кичерешләрен дә аның сөйләме аша беләбез. Шуңа күрә аны **хикәяләүче** дип атыйлар.

Хикәя жанрының үзенчәлеген истә тотып, Фатих Әмирханның бик матур хикәясенә бергәләп анализ ясыйк.

Фатих Әмирхан

Ул үксез бала шул!

Гает көнне мин ишегалдына яңа киемнәремне киенеп чыктым. Күлмәк, кәләпүш һәм читекләрем генә түгел, минем казакием[1] дә өр-яңа. Шушы гаеткә генә тектерелгән казаки иде.

Безнең ишегалдында минем белән яшьтәш малайлар аз түгел иде. Алар да бүген яңа киемнәр киенгәннәр, үзләренчә купшыланганнар, матурланышканнар иде. Бары бер генә, бер кечкенә генә малай бүген безнең шикелле киенмәгән, үзенең һәрвакыттагы иске киемендә иде. Бу малай,— былтыр атаанасы үлгәнлектән, бу ел берәүдә хезмәт итеп торган асрау малай Нури.

Без уйнарга тотындык: ат-ат уйнадык, пароход-пароход уйнадык, бу уеннардан туйгач, Сабан туе атлары булып, чабышып карамакчы булдык.

Мин яланаяк вакытта бик чибәр йөгерә, Сабан туе атлары булып уйнаганда, һәрвакытта беренче булып килә идем. Ләкин бу юлы алай булмады: минем үкчәле яңа читекләрем үзләренең авырлыклары, уңайсызлыклары белән миңа беренче килергә ирек бирмәделәр.

Һәрвакытта беренче килергә өйрәнгәнгә күрә, Нуриның мине узуы кәефемне җибәрде, мин, шул кәефсезлегемне бераз киметер өчен, иптәшләргә карабрак:

— Миңа читекләрем генә уңайсызладылар, булмаса, мин Нурины уздырмыйдыр идем,— дип сөйләнергә тотындым.

Нури үзенең узуын болай җилгә җибәрергә риза булмады:

— Узгач узган инде. Читекләрең уңайсызларлык булгач, аларны салып чабыш идең соң!

Нуриның болай мактануы минем ачуымны китерә башлады:

— Үзеңнең яңа читегең булмагач, шулай дигән буласың инде. Минеке шикелле яңа читекләрең булса, син дә яланаяк

---

[1] Казаки — кечерәк кенә утыртма якалы озын итәкле, җиңле өске кием.

чабышмас идең, бәйрәм көнне киеп йөрергә читегең дә юк бит син бичараның! — дим.

Минем бу сүзләрне башка читекле малайлар да эләктереп киттеләр.

— Үзенең читеге булмагач.

— Бәйрәм көнне дә яланаяк йөри, ә үзе алдан килүе белән мактанган була тагын!

— Аның әле юньле кәләпүше дә юк, ә үзе алдан килүе белән мактанган була тагын.

Без, яңа киемле малайлар, Нурины инде бик чынлап мыскылларга тотындык. Ул әүвәл:

— Байлыгыгыз белән мактанмагыз, байлык — бер айлык ул,— дип, безгә каршы торып караса да, эш зурга киткәч туктады. Бераз читкәрәк китеп, бер коймага сөялде дә, бер сүз дә дәшмичә, күзләрен әллә ничек кенә мөлдерәтеп, безгә карап тора башлады. Без һаман туктамадык, аны мыскыл итә бирдек; ул һаман, бер сүз дә дәшмичә, сөялгән җирендә тора бирде.

Аның болай сүзсез торуы миңа ошамады. Мин, аның ачуын китерер өчен:

— И бетләш! — дип кычкырып җибәрдем.

Бу сүздән аның күзенең мөлдерәүләре тагы да куәтләнеп китте. Ул, минем шушы сүземне генә көтеп торган шикелле, кинәт кенә коймага таба әйләнде, йөзен койманың бер тактасына сөяде дә кычкырып елап җибәрде:

— Мин үксез бала шул! Әти-әнием булса, минем дә читеккәвешем булыр иде.

Без, мыскыллаучы балалар, Нури елап җибәргәч, тып-тын калдык. Берәр минут сүзсез-тынсыз гына бер-беребезнең күзләребезгә караштык. Аннан соң Нурига карадык, аннан соң тагы бер-беребезгә караштык.

Арадан бер малай:

— Үксез баланы ник алай рәнҗетәсез? — дип кычкырды да үзе безнең төркемебездән читкәрәк китте.

— Үзең дә мыскыллаштың бит әле!..— дип, без ул малайга таба әйләндек, аннан соң тагы Нурига карадык. Ул һаман йөзен коймага сөягән хәлдә тора, инде кычкырып еламаса да, аның эченең селкенешеннән һаман әле елый икәнлеге беленә иде.

Мин дә малайлар төркеменнән читкәрәк киттем: бу вакытта минем йөрәгемне әллә нәрсә тырнаган шикелле итә

башлады, Нури миңа чиксез-чамасыз кызганыч тоела башлады. Аның:

— Мин үксез бала шул! — дип кычкырып елап җибәргән тавышы минем колакларым төбендә һаман-һаман яңгырап торган шикелле булды: — Мин үксез бала шул!

Әгәр ул үксез бала булмаса, аның да яңа читекләре булыр иде, әгәр ул үксез, фәкыйрь бала булмаса, без аны болай мыскыл итә алмас идек; әгәр ул үксез бала булмаса, болай коймага йөзен сөяп еламас иде.

— Ул үксез бала шул!

1913 ел

Хикәягә анализ ясыйк

Персонажлар холкын белү өчен, анализны сюжет өлешләрен ачыклаудан башлыйк.

Бәйрәм көн. Авыл малайлары, гадәттәгечә, уйнарга чыкканнар.

Күбесе яңа матур киемнән. Ятим малай Нури гына иске киеме белән килгән. Ләкин башкалар бу хәлгә күнеккәннәр. Шуңа күрә бар да шат.

Хикәянең бу өлешендә бернинди каршылык юк. Шуңа күрә аны **сюжетның башламы** дибез. Вакыйганың бу өлешенә «Шатлык» дип исем бирә алабыз.

Хәзер каршылык башлана, башкача аны **киеренкелек** диләр.

Балалар, гадәттәгечә, уйныйлар. Йөгереп узышалар. Моңа кадәр Нури артта кала торган булган. Ләкин бу юлы ул бөтенесен дә уза. Башкалар бу хәлгә гарьләнәләр. Узучыны мыскыл итә башлыйлар.

Вакыйга төенләнде. Дуслар арасында каршылык туды. Шатлыкны гарьлек хисе алыштырды. Сюжетның бу өзегенә «Гарьлек» дип исем бирә алабыз.

Вакыйга дәвам итә. Киеренкелек **югары ноктасына** күтәрелә.

Нуриның каршы әйтүе матур киенгән малайларның ачуын китерә. Бердәм ябырылып аны яман сүзләр белән мәсхәрә итәләр. Ә хикәяләүче малайның «Бетләш» дип кычкыруы мәсхәрәнең соңгы чигенә җитә. Нури елый башлый. Мыскыл итүчеләрнең гарьлек хисе ачуга алмашынды.

Бу өзеккә «Ачу» дип исем бирәбез.

Нуриның: «Мин үксез бала шул! Әтием-әнием булса, минем дә читекләрем булыр иде»,— дип елавы барысын да

тетрәндерә. Алар ятим малайны рәнҗетүләрен шуннан соң гына аңлыйлар һәм яман хисләренә артык ирек бирүләре өчен үкенәләр. Гарьлек, ачу хисләре кызгану, үкенү хисенә алмашына.

Киеренкелек кинәт чишелә. Өзекнең исеме «Кызгану» яки «Үкенү» була ала.

Тышкы вакыйга (сюжет) малайлар хисен үзгәртте. Көнчелек, ачу хисләре белән кызгану, оялу хисләр арасында каршылык туды. Кызгану хисе җиңде.

Истә калдырыйк:

Хикәяләрнең эчтәлеге башлыча эчке вакыйга каршылыгында табыла. Автор безне акыл белән эш итегез, хисегезгә өстенлек бирсәгез хур булырсыз дип кисәтә.

Бирем

Хәзер хикәянең төп героена бәя бирә алабыз. Бәя бирегез.

Фатих Әмирхан

Корбан

Язның бер иртәсендә, йокыдан торуга, миңа үземне карый торган малаем Хәйрулла: «Бүген төнлә безнең сарык бәтиләде»,— дип хәбәр бирсә дә, мин, артык әһәмият бирмичә, тыныч кына мәктәпкә киттем. Мин кечкенә генә, матур гына яңа туган бозауны, яңа гына йөри башлаган кечкенә көчекләрне һәм мәче балаларын, яңа гына йомыркадан чыккан каз бәбкәләрен бик яратсам да, моңа кадәр сарык бәтиен күргәнем юкка күрә, күңелемдә аларга каршы артык мәхәббәт тапмый идем. Шулай да, сабактан кайткач, бу яңа кунакларны төшеп карамый чыдап булмады. Аларның түбән өйдә икәнлекләре миңа инде мәгълүм иде.

Төштем, ни күзем белән күрим, бу бәтиләр шулкадәр матурлар, шулкадәр матурлар икән!.. Мин инде тел белән генә сөйләп бетерә алмыйм. Арадан берсе бигрәк тә матур, бигрәк тә күңелле иде. Кап-кара бөдрә йонлы, бик юаш куркак күзле, кечкентәй аякларының очлары гына ак бу бәтигә мин күрү белән гашыйк булдым. Минем аны тотып сөясем, иркәлисем килә башлады. Ләкин ул миннән ятсына, кача; әле анасы аяк астына барып керә, әле, шат сикеренә-сикеренә, сәке астына барып керә иде. Шактый мәшәкатьләрдән соң мин аны әләктердем дә алдыма алып сөя, йоннарын сыпыра, күзләрен,

борыннарын карый башладым. Ул, әүвәл бераз тыпырчынып һәм бик күп һәмзәле[1] итеп:

— Бә-ә-ә-ә...— дип кычкырып, миннән тагы качарга тырышып караса да, булдыра алмагач, үзенең кечкентәй генә йомшак борыны белән минем кулымны иснәнеп тынычланды, сөйдерә, сыйпана башлады. Мин аңар төрле матур сүзләр әйттем:

— Җаным, карачым, акыллым, ак тәпием, матурым...

Менә шушы көннән алып, бу бәрән белән минем арада бик зур дуслык башланды.

Бер-ике көннән соң инде аны анам миңа багышлады. Мин шул матур карачның хуҗасы булып киттем. Кем белә, бәлки, минем егерме яшьлек агам, кырык биш яшьлек атам, хәтта анам үзе дә бу бәтигә — бу кадәр матур бәтигә — хуҗа булырга бик теләгәннәрдер. Ләкин ничек булса булды инде...

Бик күп уйлаган, бик озак баш катырганнан соң, бу яңа дустыма мин «Хөсәен» дип исем куштым. Безнең мәктәптәге бик юаш кына, кара гына бер малай, минем дустым Хөсәен исемле иде.

Көннәр үткән саен, «Хөсәен» үсә бара, мин һәр көнне, икеөч мәртәбә аның янына төшеп, аның белән уйнап менә торган идем. Ул көннән-көн матурлана, шаянлана, җитезләнә, акрынлык белән генә булса да, миңа ияләнә бара иде. Көннәрдән бер көнне мин аны, үзебез тора торган өйгә алып менеп, үз бүлмәмә керттем. Бүлмә аңа бик ошады: ул, әллә нинди кыяфәтләргә кереп, әле алга таба, әле янга таба, әле әйләнеп-әйләнеп сикеренергә һәм ара-тирә үзенең иң сөя торган тавышы белән «Бә-ә-әәәә!»не кычкырынырга тотынды. «Хөсәен»емнең бу шаянлыгы минем дә бик хушыма китте. Шуңа күрә мин, кунак итү теләге белән, аңар бер стакан шикәрле су тәкъдим иттем. Ул, җүләр, өстенә сикергәч, стаканның ава икәнен бер дә уйламыйча гына тыпырчынып, стакан өстенә атылды да бөтен идәнне, бөтен паласны шикәрле суга манчылдырды. Минем бу эшкә бераз кәефем китсә дә, аның үзенә белдермәскә уйладым.

Матур хайванның андый гына гаепләре кичерелә инде.

«Хөсәен» үзе дә эшенә үкенде булса кирәк, тәгәрәп ята торган стаканга бераз карап торды да, башын селкеп, юаш кына тавыш белән: «Бә-ә-әәәә!» — дип куйды.

---

[1] Һәмзәле — мәгънәле.

Бу вакыйгадан соң инде мин аны икенче мәртәбә үзебез тора торган өйгә алып кермәдем. Аналар кайсы вакытта бик гаҗәп булалар бит алар: әллә нинди күңелле, әллә нинди рәхәт булырлык нәрсәләрне санга тыкмыйлар. Мин әнигә «Хөсәен»не өйгә алып менгәч, бик күңелле, бик рәхәт булачагын бик күп төрле дәлилләр белән исбат итеп карадым, ләкин ул һаман үз сүзендә калды.

«Хөсәен», тагы да үсә төшеп, ана сөтеннән аерылгач, мин аны һәр көнне үз кулымнан ашата торган булдым. Ул да шуңар каршы һәрбер очрашканда минем белән күрешми узмый һәм минем һәрбер чакыруыма килми калмый торган булды.

Җәй көннәрендә ул көтүдән кайткач, мин аны чакыра:

— «Хөсәен», кил монда! — дип кычкыра торган идем дә, ул, йөгереп, минем янга килә һәм: «Бә-ә-әәәә!» — дип сәлам бирә дә кулымны үбә иде. Мин аны сөям, иркәли, сыпыргалый, төрле матур сүзләр белән мактый идем.

Шулай итеп, кыш җитте. «Хөсәен» үсеп сарык булды.

Менә бервакыт Корбан гаете җитте. Мин гаеткә барырга чыккач, «Хөсәен», шатланып, йөгереп, миңа каршы килде, кулны иснәде, сыйпанды һәм капка төбенә кадәр озата барды.

Без гаеттән чыккач, йортта корбан чалырга хәзерләнә башладылар: безнең корбан өчен алган ике сарыгыбыз бар иде. Мин өйдә, бәйрәмгә тегелгән яңа киемнәрне киеп, үз-үземне көзгеләрдән карап, купшыланып йөргән вакытта, берзаман «Хөсәен»нең әллә нинди кызганыч тавыш белән кычкырганлыгы ишетелде. Минем йөрәгем жу итеп китте. Күңелемә: «Әллә «Хөсәен»не дә суймакчы булалармы?» дигән уй килеп төште. «Хөсәен»нең тавышы тагы ишетелде. Бу юлы инде әүвәлгедән дә кызганычрак, әүвәлгедән дә җан көйдергечрәк булып ишетелә иде. Мин, үз-үземне белешмичә, корбан чалына торган җиргә атылдым. Мин ялгышмаган икәнмен: минем «Хөсәен»емне яткырганнар да аякларын бәйләп маташалар. Мин, ачы тавыш белән:

— «Хөсәен»! — дип кычкырып җибәрдем дә елый башладым.

«Хөсәен», мескен, минем тавышка яткырылган урыныннан тормакчы булып тыпырчынды, булдыра алмагач, елаган, ыңгырашкан сымак итеп, һәм моңлы, һәм ачы, һәм җан көйдергеч тавыш белән кычкырып, миңа җавап бирде. Бичаракай, яшьле күзләрен соң дәрәҗәдә куркындырып, ярдәм

көткән төсле итеп моңландырып, миңа карады да тагы кычкырды. Хәзер инде аның тавышында зарлану, каргау, кансыз суючыларга ләгънәт уку ишетелә иде. Минем җаным башыма чәчрәде. Йөрәгем ялкынланып сызланды, елавым инде акыруга әйләнде. Мин суючының өстенә атылмакчы булдым. Ләкин җибәрмәделәр. Тоткан кешеләрнең кулларыннан ычкынырга маташсам да булдыра алмадым...

Ике минуттан соң инде минем «Хөсәен»ем дөньяда юк, бары аның әле суынып бетмәгән тәне генә җир өстендә аунап ята иде. Ике-өч сәгать моннан әүвәл ул мине мәхәббәт белән каршылаган, капка төбенә кадәр озата барган, ике генә минут моннан алда кычкыра алган, мине танып, җавап бирә алган, яшьле, моңлы күзе белән миннән ярдәм сорый белгән бичара «Хөсәен» хәзер инде бу эшләрнең берсен дә эшли алмый торган җансыз тән булып калган иде.

Хәзер инде эш үткән, елап бер файда да итеп булмый икәнен белсәм дә, мин тиз генә туктала алмадым. Атам, мине юатыр өчен:

— Юләр, шулкадәр ираулап еларга ярыймыни... Бабаң өчен корбан итеп чалдык бит без аны; менә бабаң Кыямәт көнендә, аңар атланып, Сират күпереннән үтәр,— диеп караса да юата алмады.

Мин аңар:

— «Хөсәен» бабайны түгел, мине дә күтәрә алмыйдыр иде,— дип кенә җавап бирдем.

Мин, өйгә кергәч тә, бик озак еладым. Агам миңа:

— Юләр, «Хөсәен»ең корбанга чалынганга сиңа куанырга кирәк әле. Корбанга чалынган хайваннар — иң бәхетле хайваннар алар,— дип караган иде дә, мин аңар:

— Әйе, менә үзеңне корбанга чалып карасыннар иде әле. Бер дә мин бәхетле булдым, корбанга чалындым, дип тора алмас идең,— дип кенә җавап бирдем.

Бу вакыйгадан соң миңа бәйрәмнең бер кызыгы да булмады. Мин озак вакытлар «Хөсәен»не оныта алмадым. Аның суелыр алдыннан кычкырган кызганыч тавышы минем колакларымны озак вакыт яңгыратып тордылар. Аның моңлы һәм яшьле күзләре белән карашы минем күз алдыма килеп йөдәттеләр...

1913 ел

Бирем

Хикәягә анализ ясагыз.

Марсель Галиев

Балачак эсирлегендә

Каешланып, ялтырап яткан авыл юлы, көтүче чыбыркысы шикелле бормаланып, тау астына төшеп югала. Шаулы, болгавыр шәһәрдән кайтып төшүгә, тирә-як тыныч табигате белән тәбәнәгәеп, саңгырауланып кала сыман. Офыклар нинди иркен. Дөньяда әйтерсең лә син һәм табигать кенә. Үзем дә сизмәстән йөгерә башлыйм. Тизрәк авылны күрәсе, өйгә кайтып керәсе килә. Зиратка җитәрәк адымнарны акрынайта төшәм. Ничәмә-ничә тапкыр шушы зират яныннан үткән саен, сәер тойгылар биләп ала. Гел шулай. Койма аша каберләрне күзәтеп барам. Шулчак, якында гына, зәңгәр рәшәткә артында, җирдән калыккандай кемдер пәйда була. Сискәнеп куям. Кояштан уңа төшкән, үлән төсендәге күлмәк кигән әби белән күзгә-күз карашып торабыз. Ул мине төсмерләми дә бугай. Ә мин аны танып та алдым.

— Нихәл, Миңлеҗамал әби!

(Мин элек аңа «апа» дип эндәшә идем...)

Миңлеҗамал әби, уң кулын каш өстенә куеп, бермәл текәлеп торды да миңа таба килә башлады. Йөзендә сәерсену катыш кызыксыну билгесе.

— Әллә танымыйсыңмы, Миңлеҗамал әби?!

Ул җанланып китте. Тавышымда балачактан ук сакланып килгән ниндидер төсмер гүя аның хәтерен уятып җибәрде.

— Бәй, Илшат түгелме соң? — дип, әби койма буена ук килде. Койма аша җиңел генә сикереп кердем дә Миңлеҗамал әбинең кабырчык шикелле кытыршы кулларын учыма алдым.

— Яшәреп буламы, әби?!

— Кая инде ул, бер артка китә башлагач... Сөбханалла, бөтенләй ирләр кыяфәте кергән үзеңә.

Миңлеҗамал әбинең тавышы калтырап куйды. Аның күзләрендә мин мәңге эремәс боз булып тирәнгә киткән сагыш күрдем. «Минем улым да синең кебек булыр иде бит» дигән сүзләр әбинең күзләренә тирән әрнү белән язылган иде.

— Менә улымның каберен чистартыйм дип килгән идем. Чәчкәләрне үлән басып киткән гел.

Мин кабернең салкынча рәшәткәсенә тотынган килеш озак басып тордым. Миңлеҗамал әби, тирәмдә сөйләнә-сөйләнә, нидер эшли...

Еллар үткәч, шушы рәшәткә белән уратып алынган кайгы инде күңелемдә суына төшкән. Ләкин ул кайгы, туган якка кайтып балачак эзләренә басу белән, кара канатын җәеп, шатлыгыңны, ваемсыз хисләреңне күләгәли. Миңлеҗамал әби белән очрашкач, үзеңдә сәер бер уңайсызлану сизәсең. Без аның бердәнбер сөекле улын, дустыбызны, рәшәткә эчендә калдырдык та үзебез еракларга китеп таралыштык. Кайгыдан сыгылган ана улының үткәне белән яшәп калды, һәм без аратирә авылга кайтып төшкәч, Миңлеҗамал әбинең җөйләнгән ярасы кабат ачылып киткәндер, мөгаен.

...Мансур... Ул бар иде бит, кайчандыр исән иде. Уйныйкөлә иде. Әгәр ул көнне булмады дип исәпләсәң... нинди ваемсызлык... мәгънәсез очраклылык аркасында... Безнең очырткыч талга килеп эләкте. Биектә, нәзек ботакта җилфердәп торган очырткычка карап бермәл чарасыз калдык. Нишләргә? Очырткычны алмасак, бу инде ярты юлда туктап калу, башка малайлар каршында җиңелү булыр иде. Әнә алар инде безнең арттан җитеп тә киләләр.

Мансур җәһәт кенә ботинкаларын салып ташлады. Ниятен сизеп, мин аны туктатырга ашыктым.

— Менмә, барыбер ала алмыйсың!

— Минме? — Ул миңа мыскыллы караш ташлады да, мәче кебек, ботактан ботакка үрмәләп менеп китте. Мин аны тыеп кала алмадым.

Мансур тал ботагыннан түп өстенә егылып төшмәгән булса... Ул бит авыртуын да сиздермәде. Кичкә кадәр уенны ташлап китмәде. Ә без, ваемсыз малайлар, башта куркып өнсез калсак та, Мансурның берни булмагандай тотышын күргәч, көлешә-көлешә, беребездән-беребез арттыра-арттыра, аның ничек егылып төшүен, ни рәвешле тәгәрәп китүен тасвирлый башладык. Шулай ду килеп шаярышкан вакытта кемдер аның бил тирәсенә ялгыш кына кагылып китте. Мансурның йөзе агарып, тартышып куйды, әмма ул берни дә сиздермәде.

Үзсүзле, үҗәт[1] иде шул. Кызып-кызып бәхәсләшә, һәр бәхәстә өстен чыга белә иде. Аның тәвәккәллегенә бездә соклану уята, хәтта юаш, нәзберек кенә малайлар да аңа охшарга тырыша иделәр.

---

[1] Үҗәт — үзенчә, үз дигәненчә эшләргә омтылучан кеше.

Миңлеҗамал әби инемә кагылды:

— Син Мансурдан бер яшькә кече идеңме әле?

— Әйе, әби.

— Сиңа егерме ике яшь инде, алайса. Кичә генә булган кебек, баксаң, унөч ел үтеп тә киткән... Балаң берәү генә булса, шул инде ул: әҗәл дигәне сагалап кына тора.

— Теге вакытта без утырткан сәрви куагы корыдымыни, Миңлеҗамал әби?

Әби күзенә төшкән парчалы яулыгын артка табарак шудырып куйды.

— Агач кирәкми, улым. Йоклаган чакта юрганын гел ачып ташлый торган иде балакай. Төненә ничә торып япканмындыр, барыбер ача да ташлый. Әллә инде шуңа күрә кабере өстенә агач утыртасым килми.

Тирә-ягымда урман кебек куе аксыргаклы, түмгәкле үзән җәелеп ята. Без анда сугышлы уйный торган идек.

Үзәнлек түрендә — Мөкәтә тавы. Анда менеп без ярыша-ярыша очырткычлар очыра идек. Кемнеке биегрәк оча? Кемнең очырткычы матуррак? Китә бәхәс. Үпкәләшү. Көнләшү. Мансур каяндыр сызымнар тапкан иде. «Иң биек оча торганы, иң зурысы безнеке булачак!» — дигән иде ул.

Мансурны район хастаханәсенә салдылар. Минем иң беренче уем шул булды: без бит ул әйткән очырткычны ясарга өлгерә алмый калдык. Аксыргаклыкта сугыш уены да тукталды. Мансурның өлгерлеге, кайнарлыгы җитмәүдән уенның кызыгы югалды.

Ә беркөнне әни эшеннән иртәрәк кайтты да:

— Мансурны күрәсең киләме? Җыен әйдә, районга барабыз,— диде. Әнинең тавышында мин шомлы бер мәгънә сиздем. Ләкин төпченеп сораштырырга кыймадым.

Хастаханәгә җитәрәк, әни:

— Бүген Мансурга операция ясаячаклар,— диде.

Ак җәймә астында яткан Мансур безгә күтәрелеп карамады. Йөзенә әллә нинди сары төс өртелгән иде аның. Эч турысы кабарып тора, мендәр куйган шикелле. «Эчке әгъзаларына кан сауган, үлекләгән, каян беләсең бит аны, хастаханәгә бер атна үткәч кенә илткәннәр»,— диде әни соңыннан. Карават башында Миңлеҗамал апа утыра, күзләре кызарган, йөзендә арыганлык галәмәте. Миңлеҗамал апа белән әни читкәрәк китеп пышылдап кына нидер сөйләштеләр. Аерым сүзләрен генә ишетеп калдым. «Төннәрен саташа... танымый».

Бераздан Миңлеҗамал апа мине караватка якынрак китерде дә, Мансурның җәймәсен ача төшеп, сак кына дәште:

— Улым, иптәшең килгән әнә, таныйсыңмы?

Мансур, хәлсез карашын миңа төбәп:

— Илшат,— диде. Тавышы гыжылдап, бик авырлык белән генә чыкты. Мин шунда гына дустымның хәле никадәр җитди икәненә төшендем.

— Хәлең ничек?..

Мансурның күзләре калтырап куйды, күлгә таш төшкән кебек. Тышта гөжелдәп кисәк кенә яңгыр ява башлады. Эре-эре тамчылар тәрәзә пыяласын уеп-уеп төшә иде сыман.

— Очырткычны үзең генә яса инде...

Миңлеҗамал апа: «И бала...» — дип, урыныннан торды да, битен яулык белән каплап, тәрәзә янына китте. Минем күз яшьләре тирәннән күтәрелә башлады. Ләкин мин тәҗрибәсез малай күңеле белән сиздем: күз яшен күрсәтмәскә кирәк.

— Икегез ясарсыз, улым. Менә тиздән терелеп чыгарсың да,— диде әни. Аның җылы итеп әйткән сүзләре күңелне үстереп куйды.

Китәр алдыннан мин дустымны юатырдай иң кадерле сүзләрне әзерләдем. Әмма кырыйда өлкәннәрнең торуы әллә ничек шунда тартындыра иде. Җитмәсә, әни дә:

— Китәбез бит, улым. Тизрәк терелеп чык, диген Мансурга,— дип әйтеп җибәрмәсенме. Әнигә чиксез үпкәләп, мин һаман тын гына тора бирдем. Без бит Мансур белән икәүдән-икәү генә калырга тиеш идек бу минутта.

Мансурны күмгән көнне болынга чыктым да ауный-ауный еладым. Әгәр теге чакта Мансурны тал башына менүдән тыеп калсам, бу фаҗига булмый калыр иде бит. Мин гаепле, мин! Ул фаҗига булмый каласы иде бит...

Еллар аша барын искә төшерәм дә шул адымны ясый алмавыма тагын бер үкенеп куям...

— Син хәтерлисең микән,— дип, Миңлеҗамал әби җиңемә кагылып алды,— Мансурга кесәле, падтәжкәле зәңгәр чалбар тегеп биргән идем. И шуңа куанулары, олылар кебек башын кыңгыр салып капкадан чыгып китүләре... һаман да күз алдымда. Бердәнбер бала булгач, энәдән-җептән генә киендереп йөртә идем бит мин аны,— дип, Миңлеҗамал әби кызарган күзләрен яулык почмагы белән каплады.— Шул көнне кайтып керде дә: «Илшат шундый кызыкты чалбарга, ди. Су коенганда киеп тә карады, ди. Әни, теген бир әле Илшатка да

шундыйны»,— ди. Вакытым булмагандыр инде, көне-төне кыр эшендә бит. Тегә алмадым сиңа. Яңадан сорамады, балакай, күреп торам бит, гел иске чалбарын киеп чыга урамга. Синнән кыенсынгандыр инде...

Мансурның кесәле, подтяжкалы ул чалбары минем хәзер дә күз алдымда тора. Кесәле чалбар — малайчакның төшләренә кергән хыялы бит ул. Кая куярга белмәгән, артык булып тоелган кулның оясы, тукталыр урыны иде кесә.

Әйе, хәтерлим мин ике кесәле зәңгәр чалбарны. Тик Мансурның әнисенә әйткән теләген белмәгән идем. Ул елларда яңа кием белән мактану, өстен булырга тырышу — хәзерге малайларга хас гадәтләр — юк иде шул әле, бары тик уенда ярышу, беренче калырга тырышу тойгысы гына бар иде.

— Җәй җитсә, күлмәк-ыштаннарын сандыктан алам да юып элэм. Бауда кердәр чайкалганда капка келәсен шалтыратып, Мансур улым үзе кайтып керер сыман,— дип, Миңлеҗамал әби бөрешеп үләнгә утырды. Мин сумкамнан тартмалы конфет алып, аның алдына куйдым. Әнигә дип алган яулыкны да чыгарып әбинең иңенә яптым. «Мин бит әле әнинең исән улы, аңа икенчене алырмын. Минем вакытым бар. Мансурның гына менә...»

Зәңгәр җирлегенә чәчәкләр сибелгән яулыкның шәүләсе төштеме, Миңлеҗамал әбинең йөзенә нур кунды, күзеннән яшь тәгәрәп төште.

— Улым...— дип, ул минем беләк мускулларыма кагылып алды.— Минем дә улым шулай булыр иде бит... Озак яшә, балакай.

Үземнең дә күңелем тулган иде, йомшап китмәс өчен, тизрәк әби белән саубуллашырга ашыктым.

Үзәнгә җитүгә, аксыргаклар арасыннан шаулашып малайлар төркеме чыкты. Кулларында — агач мылтыклар. Колак төбемдә Мансурның усал тавышы яңгырагандай булды:

— Кулларыңны күтәр, син әсир ителдең!

Минем уйчан-җитди карашымнан ятсынышмы, малайлар, өркетелгән күгәрченнәр кебек, як-якка сибелделәр дә аксыргаклар арасында юк булдылар. Мин алар артыннан кызыгып карап калдым. Алда Мөкәтә тавы күренде. Тау турында, без Мансур белән ясарга хыялланып йөргән очырткыч шикелле, нәни генә ак болыт туктап калган. Кемдер җебеннән тартыр да, ул тагын кузгалып китәр, зәңгәр киңлектә талпынып йөзәр кебек...

Биремнәр

1. Хикәянең сюжетын кыскартып сөйләгез.
2. Хикәядә өч персонаж катнаша. Аларның берсе — әби. Әбинең төп сыйфатын бергәләп табыйк.
3. Илшатның холкы турында сөйләгез.

Хикәядә әбинең бер генә сыйфаты бирелгән — ул үкенечле үлем белән үлгән улын сагынып яши. Күп еллар үтсә дә, аның хәсрәте аз гына да кимемәгән... Миңлеҗамал әби улы Мансур турында сөйли, ләкин чынлыкта үзенең бетмәс-төкәнмәс хәсрәте белән уртаклаша. Улы турында күбрәк сөйләгән саен, хәсрәтен яңарта. Улының юрган ябынырга яратмавы ана өчен үткән заман вакыйгасы гына түгел. Ул кабердәге улын гел исән итеп күз алдына китерә. Зәңгәр чалбар вакыйгасы да үткән замандагы үкенеч кенә түгел. Ул аны һаман юып киптерергә элә.

Ә хикәя авторы әбинең хәсрәтендә аналарның улларына булган әйтеп бетермәслек зур мәхәббәтен күрә.

Иҗади эш

«Илшатның холкы» дигән темага инша языгыз.

План

1. Кереш:
   а) әсәрнең авторы турында белешмә;
   ә) хикәянең исеме һәм Илшат холкы.
2. Төп өлеш:
   а) Илшат кичерешләренең сәбәпләре;
   ә) Илшатның холкы.
3. Йомгак:
   а) Илшат холкына мин нинди бәя бирәм;
   ә) хикәягә минем бәя.

Образ дип башка мәгънә алган әйберләргә (предметларга) яки күренешләргә әйтәләр. Мәсәлән, хикәядәге **очкыч** һәм **ак болыт** — образлар. Чөнки икесе дә, башка эчтәлек алып, өзелгән хыялны сурәтләп киләләр. Әсәрдә катнашучы персонажларга да образлар, диләр. Образ булсын өчен, персонаж автор тарафыннан укучы күз алдына китерерлек дәрәҗәдә сурәтләнергә тиеш. Сыйфатлары (йөзе, кыяфәте, киеме, холкы һ. б.) күбрәк ачылган саен, шундый кешенең яшәвенә чын-чынлап ышанасың.

Мирсәй Әмир

Мөстәкыйм карт йокысы

Мөстәкыйм картны күптән исәптән чыккан кешегә санайлар иде инде. Дөрес, яшь ягыннан тугызынчы унны куса да, болай күрер күзгә таза иде әле үзе. Вакыты белән зур-зур, авыр-авыр эшләрне җиңел-җиңел генә эшләп ташлый ала һәм ашау ягына килгәндә дә сынатмый торган иде. Тик бер генә нәрсә аяктан ега иде аны: йокысын җиңә алмый иде карт.

Гаҗәп бер йокы булып чыкты ул Мөстәкыйм карт йокысы. Нинди генә вакытта, нинди генә хәлдә йокламый иде ул?! Тәмле генә итеп сөйләшеп утырганда дисеңме, ләззәтле генә итеп чәй эчеп утырганда дисеңме — әллә каян таяныр әйберен таба, әллә каян сөялер урын туры килә — эри дә китә.

Өй эчендәгеләр аның бу гадәтенә ияләшеп беткәннәр иде инде. Бервакытны ул тавык суйган чагында йоклап көлкегә калды. Ә тавык суярга туры килә иде аңа. «Кулы тәмле» дип, күрше-күләң дә тавыкны аңардан суйдыра иде. Шулай беркөнне шактый ерак күршеләреннән исәпләнгән Хөбби карчык кысыр тавыгын күтәреп килде.

— Тиз генә суеп бирче шушыны, Мөстәкыйм абзый,—диде карчык,— күкәй салмый башлады, рәхмәт төшкере.

— Хәзер эшен бетереп алып керәм мин аның,— диде Мөстәкыйм карт, бер кулына тавыкны, икенче кулына чалгы пәкесен алып, лапас астына кереп китте.

Хөбби карчык, Мөстәкыйм картның үзе белән бергә картайган Мәрзия карчык белән сөйләшеп, өйдә калды. Мәрзия карчык самовар да куймакчы иде дә, Хөбби карчык чын күңеленнән каршы төште:

— Кирәкмәс, күрше, эшем ашыгыч, зинһар, мәшәкатьләнмә, бик тиз кайтып җитәм, дип кенә чыгып киттем,—диде. Ләкин бик тиз генә кайтып китә алмады ул. Ике карчык байтак сөйләштеләр. Мөстәкыйм карт һаман тавыкның эшен бетереп алып керми иде. Хөбби карчык сабырсызлана башлады:

— Ай Алла, нишләп болай озаклады соң бу Мөстәкыйм абзый, рәхмәт төшкере?— дип, берничә тапкыр кабатлап алды. Картының гадәтен белгән Мәрзия карчык, борчылып, кулын селкеп:

— Йоклап китте микәнни, Ходаем,— диде,— чыгып карыйксана үзен.

Мәрзия карчыкның сизенүе дөрес булып чыкты: Мөстәкыйм карт, тавыкның канатларын артка каерып, җиргә баскан, томшыгын кысып тоткан килеш, башын тез өстенә салган да йокыга киткән иде. Икенче бервакытны ул, тәһарәт алып утырган чагында, бер аягын юган, икенче аягын юмаган хәлдә, болдыр баскычына утырган килеш, башын тез өстенә салган да йокыга киткән иде.

Мәрзия карчыкның мондый хәлләргә бер дә исе китми, вакытлы-вакытсыз, урынлы-урынсыз йоклаган өчен, картын шелтәләп торуны да кирәк тапмый иде.

Шулай итеп, Мөстәкыйм картны колхоз өчен күптән исәптән чыккан кешегә саныйлар иде инде. Карт үзе дә, бу хәл белән килешкән булып, зур эшләргә тыгылмый, тик үз йорты тирәсендә, үз җае белән генә кыштырдап йөри бирә иде.

Тыныч илебезгә Гитлер Германиясе юлбасарларча һөҗүм башлап бөтен халык Ватан сугышына күтәрелгәч, ир уртасы кешеләр фронтка китеп, колхоздагы барлык эш хатын-кызлар һәм картлар белән үсмерләр кулына калгач, Мөстәкыйм карт үзенең исәптән чыккан кеше булып яшәвенә риза булып кала алмады.

— Ике улымны да фронтка озаттым,— диде ул, колхоз идарәсенә килеп,— алар өчен бередә кем дә булса эшләргә тиеш бит,— диде.— Мин үзем, болай карт булсам да, йокламаган чагымда бер дә яшьләрдән ким түгел. Кулымнан килгән хәтле булыр, кушыгыз мине берәр эшкә,— диде.

Аны хуплап каршы алдылар. Карт өченче бригадага беркетелде.

Өченче бригаданың башлыгы Фәгыйлә исемле, бик характерлы яшь кенә хатын иде. «Ирләребез кайтканчы шушы бригаданы аяктан екмый алып бара алсам, бу каһәр суккан Гитлер дөмегеп, сугыш беткән көнгә, сөреләсе җирләр сөрелгән, чәчeләсе җирләр чәчелгән, чабыласы җирләр чабылган, урыласы җирләр урылган хәлдә ирләребез кулына тапшыра алсам, башкасы кирәкми»,— ди иде ул һәм, берәүләрне тиргәп, берәүләрне юмалап эшкә куша-куша, хуҗалыкны артка калдырмыйча бара иде. Әмма ярсу йөрәкле хатын иде инде. Юмалау килешә торганрак кешеләрне юмалый башласа, тәмам эретә — балавыз итә иде Фәгыйлә. Ә инде яхшылап әйткәнне колакка алмый торганрак кешеләргә кадалса, чыдап кына тор: утка басканнан ким сикертми иде ул андыйларны. Нәтиҗәдә бары да тыңлыйлар иде үзен. Кемнәрне уңай якка

сыпырып, кемнең чәчен кирегә ышкырга кирәклекне белә иде шул.

Әмма Мөстәкыйм бабайның көен таба алмыйча аптырап бетте Фәгыйлә. Мөстәкыйм карт бригадага бик күп файда китерде.

Ләкин әлеге дә баягы йокысын ташлап бетерә алмады ул. Эш өсләрендә вакытлы-вакытсыз, урынлы-урынсыз йоклап китеп, Фәгыйләнең ачуын китереп бетерде. Ләкин Фәгыйлә, бердән, аның олы кеше булуын, икенчедән, кулыннан килгән кадәр намус белән эшләргә тырышуын, бригаданы валюк баулары, тырма, сәнәк кебек нәрсәләргә бервакытта да мохтаҗ итмәвен искә алып, аңа каты бәрелмәскә тырышып килде. Берничә тапкыр теле кычытып-кычытып куйса да түзгән иде. Тик кызу печән өстендә килеп чыккан бер күңелсезлек Фәгыйләнең сабырын җуйды.

Өченче бригада хатыннары искиткеч бер дәрт белән ярышып, икенче бригададан уздырырга тырышып печән чапкан вакытта, Мөстәкыйм карт аларга ярдәмгә бирелгән иде. Чабучылар ял иткән чакларда, аларның чалгыларын чүки иде ул. Ул чүкеп биргән чалгылар Гали пәкесе кебек булалар иде инде булуын. Ә менә бервакытны, печән чабу өчен, заказ ясатып алынган кебек матур көннәрнең берендә, картыбыз чалгы чүкегән чагында кырын ятып йоклап киткән бит. Чалгылар чүкелеп беткәнче генә черем итеп алырга дип ятып торган хатыннар да уянмаганнар. Җәйнең иң озын көннәрендә бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләп йөргән кешеләр ни эшләсеннәр? Рәтләп йокы эләгәмени аларга бу көннәрдә! Печән өсте бит. Гади печән өсте генә дә түгел, сугыш вакыты печән өсте!.. Йоклаганнар да йоклаганнар болар. Алтыннан кадерле вакыт та әрәм үткән, чалгылар да чүкелмәгән. Шуның аркасында ул көнне икенче бригада чабучылары өченче бригадага караганда норманы бик күп арттырып үтәгәннәр.

Фәгыйлә бу хәлгә болай гына түзеп кала алмады, Мөстәкыйм картны кәнсәләргә — рәис янына чакыртты бу. Кич булып, көн караңгыга авышып барган вакыт иде. Үзе өстәл артыннан рәис белән янәшә урын алып, Мөстәкыйм картны каршысына утыртты да тотынды пешерергә, тотынды пешерергә, чыдап кына тор.

— Болай ук гамьсез булырсың дип уйламаган идем мин сине, Мөстәкыйм бабай! — дип башлап җибәрде ул сүзен.— Карт кеше дип, тырышып йөри дип, моңарчы дәшми килдем.

Кәнүшни түбәсен япканда, салам алып торган чагында йоклавына да сүз әйтмәдем. Тары чәчкән вакытта тагын...

Шулай тезеп китеп, Фәгыйлә аның кайчан, кайда йоклаганнарын санарга тотынды. Мөстәкыйм карт каршы сүз әйтмичә, «ие, ие, кызым, булды бугай шул, картлык, күрәсең инде» дип, һәр гаебен өстенә алып утыра иде. Фәгыйлә аның болай бөтенесен дәреслап утыруын да ошатмады.

— Сугыш вакыты икәнен аңларга теләмисең син. Аңларга теләсәң, бер йокыңа гына баш була алыр идең. Шушындый кызу көндә, шушындый җаваплы эшне тоткарлауга барып җиту уен эшмени ул! Ә?!

Бу сүзләр кәгазьгә язылгач бик каты яңгырамасалар да, Фәгыйлә авызыннан әйтелгән вакытта алар бик каты, бәгырьләргә үтәрлек ачык булып чыктылар. Мөстәкыйм карт инде бөтенләй эндәшми башлады. Ул эндәшмәгән саен, Фәгыйлә тавышын күтәрә бара иде. Карт аның саен дәшмәгәч, бригадир рәискә борылып сөйли башлады:

— Менә күр инде, Сабир абзый, нишлим мин бу карт белән? Сүз дә бирми бит, ичмасам.

Ул, кинәт Мөстәкыйм картка борылып, тагын да катырак тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Адәм рәтле эшләргә телисеңме, Мөстәкыйм бабай, юкмы? Йә, әйт!

Мөстәкыйм карт җавап бирмәде.

Бригадир тагын нәрсәдер әйтеп кычкырмакчы иде дә, нидер исенә төшкән кебек, кинәт тынып калды. Өстәл артыннан чыгып, аның каршысына ук килеп басты һәм әкрен генә картның йөзенә иелде...

1943 ел

Биремнәр

1. Мөстәкыйм бабай холкы турында сөйләгез.
2. Мирсәй Әмир — оста хикәяче. Хикәясен ул ничек тәмамларга мөмкин?
3. Хикәя тәмамланмаган, язып бетерегез.

Роза Хафизова

Сөенечле хәбәр

Атна буе инде буран котыра. Ишегаллары, урам як коймалары тау-тау булып өелгән көрт астында калды. Буран исә һаман котырына, ак ялын уйнаклатып тәрәз пыялаларына

сарыла, моржага кереп кемнедер тирги, үзе белән алышырга тышка чакыра.

Безнең өйдә җылы, рәхәт. Мич кашагасына[1] утырткан сукыр лампадан бүлмәгә сүрән генә яктылык сибелә. Әби, чуар яулыгын артка чөеп бәйләгән килеш, мич буендагы утыргычка кабасын көйләп, йон эрли. Аның орчыгы, буран белән узышып бөтерелгәндәй, зыр-зыр әйләнә. Аш урынын җыеп алгач, кайнар су белән сап-сары итеп юган өстәл артында без, дүрт бала, рәттән тезелеп утырып, дәрес карыйбыз. Мин тырыша-тырмаша мәсьәлә чишәм. «Бер шәһәрдән икенче шәһәргә кара-каршы ике поезд чыккан...»

— Апай, дим, апай, әтәч ясап бир әле!

Кечкенә сеңлем Фәһимә өстәлнең каршы башыннан миңа кәгазь кисәге суза. Ул әле укымаса да, безнең янга утырып, «дәрес» караган булып кыйлана. Аның гозерен үтәмичә ярамый. Әби әйтә: «Ул ятим үсә, ата-ана назын күрми, кыерсытмагыз аны»,— ди. Дөрес тә шул инде, әтиебез икенче ел сугышта, әниебезне узган ел урман кисәргә киткән җирендә агач басты.

Сеңлемә әтәч сурәте ясарга керештем. Кечкенәләргә шул гына кирәк тә, өчесе өч яктан иңемә сарылдылар. Юкса инде энеләрем алай бик кечкенә дә түгел: Фатих өченчедә, Зарифы беренчедә укыйлар. Рәсем ясарга дигәндә, өчесе дә бердәй мавыгалар.

Сукыр лампа мелт-мелт итә. Бу аның керосиным бетә, эшлисе эшләрегезне эшләп калыгыз дип кисәтүе. Минем әле мәсьәлә чишелмәгән.

Шулчак шыгырдап капка ачылды. Ишегалдында Рекс өреп җибәрде. Без тын калдык. Мондый буранлы салкын төндә кем йөрер икән? Әллә соң әтидән хат-хәбәр китерделәрме?

Әби, орчыгын бер читкә куеп, ишек ачарга чыкты. Ишектә башта калын олтанлы киез итекләр, сары тун чабуы, аннары аларның иясе — аргы очның Хәсәнә апа күренде. Аңа ияреп убырылып салкын керде. Хәсәнә апа башына саргылт шәл бөркәнгән, билен шәл өстеннән юан бау белән буып куйган. Килеп керде дә безгә карап ишек катында туктап калды.

Төнге кунак мондый салкын буранда тикмәгә генә йөрмәс. Без Хәсәнә апага сагаеп карап каттык. Ул башта шәлен

---

[1] Кашага — мич авызы өстендәге киштә сыман чыгынты яки уенты; кучкар.

чишеп артка чөйде, аннары туның ычкындырып җибәрде һәм мич буеннан әби әтәргән урындыкка килеп утырды.

— Әтиегез янынннан кеше кайткан, балалар. Керәшен авылыннан Микулай. Ул сезнең әтиегезне күрдем дип әйтеп әйтә, ди. Дон елгасын бергә кичкәннәр. Әтиегезнең бармаклары шешкән булган...

Хәсәнә апа сөйли дә сөйли. Без, аның сүзен бүлдермәс өчен, тын алырга да куркып утырабыз. Минем баштан ялтырап йөгерек уй узды. «Бармаклары шешкәч, мылтык тота алмый ич ул, бәлки әле, өйгә дә кайтарырлар».

Шулчак Фәһимә, өтәләнә-кабалана, урындыктан төште дә кунакка килеп сарылды.

— Безнең әти кайтам дигәнме? Шикәр алып кайтамы?

— Кайтыр, балам, әтиегез кайтыр,— дип, Фәһимәнең башыннан сыйпады Хәсәнә апа.

Әбием, мичкә аркасы белән сөялгән килеш, озак кына эндәшмичә торды, аннары офтанып:

— Әниләре исән булса, Микулай янына барып, үзе сорашып кайтыр иде дә бит,— дип әйтеп куйды.

— Әби, Фатих белән икәү барып кайтыйк. Берсекөнгә ял көне ич,— дип кабаланып әйттем...

Әби икеләнеп калды, озак кына сүзсез торды, ахырда җибәрергә риза булды.

* * *

...Әби безне авылны чыкканчы озата барды. Ул таягына таянып әкрен генә атлый. Фатих белән безнең йөрәк түзми, тизрәк чабып китәсе, урманга җитәсе килә. Әлеге керәшен авылы шул урман артында ич. Анда барып җитсәк, Микулай дәдәйне табабыз да табабыз инде.

Уф, җилкапкага җиттек. Әби, таягына таянып баскан килеш, дога кылды да:

— Йә балалар, Аллага тапшырдык, исән-сау йөреп кайтыгыз,— дип, басу капкасы төбендә басып калды.

Фатих белән җитәкләшеп алга йөгердек. Аякларыбызда җылы оекбашлар белән өр-яңа чабаталар. Әби ул чабаталарны урта урамның Шәйхулла бабайдан үрдереп алдырган иде. Олтанлы булса да киез итекләребез дә бар барын. Тик әби әйтә, озын юлга чабата җиңел була, ди. Дөрес әйтә, аяклар үзләреннән-үзләре атлыйлар.

Әнә якында гына урман караеп күренә. Урман артыннан иренеп кенә кояш күтәрелеп килә. Тирә-юньдә ник бер җан иясе булсын. Тып-тын, ап-ак кар дәрьясы...

Атлый торгач, урманга да җиттек. Монда тыныч. Биек-биек агачлар кар бүрекләр киеп йокымсырап утыралар...

Бик ашыксак та, керәшен авылына төш җитәрәк кенә килеп кердек.

Бу авылның да, безнеке кебек, кар астыннан морҗалары гына калкып утыра икән. Урамына килеп кергәч, беравык кая барырга, Микулай дәдәйнең йортын кемнән сорарга белмичә аптырап тордык. Урамда бер җан иясе юк. Хәтта эт өргәне дә ишетелми иде. Әллә авыллары белән йокыдан ук уянмаганнар инде.

Ихатасыз-капкасыз бер йорт янында озак кына басып тордык.

Күрше йорттан көянтә-чиләк күтәргән бер апа килеп чыкты. Аның янына барырга да, бармаска да белмичә икеләнеп тик торабыз. Ул арада әлеге апа үзе безгә таба атлады.

— Чит авыллар димме?

— Ие, без Микулай дәдәйне эзләп килгән идек.

— Кайсы Микулай ул, бездә икәү бит алар?

— Әле генә сугыштан кайтканы.— Апаның ягымлы йөзенә карап, мин тиз-тиз сөйләргә керештем.— Ул безнең әти белән бергә сугышкан. Әби авылыннан без, Мирсәгыйть балалары.

Апа көянтә-чиләген кар өстенә куйды.

— Гәргәри Микулае кирәк икән сезгә. Узган атнада гына кайткан ие шул ул, бер кулын өздереп... Әйдәгез, күрсәтәм өйләрен,— диде...

— Ник әниегез килмәде соң?

— Әниебезне узган ел җирләдек, урман кисكәндә, агач басты. Әбиебез карт, ерак юлга чыга алмый.

Апа адымын әкренәйтте, безгә текәп карап куйды. Бер сүз дә әйтмәде. Урам буйлап шактый баргач, шундый ук ихатасыз бер йортның ишеген какты.

— Микулай, Анка, менә сезгә кунаклар алып килдем.

Безгә ияреп өйгә бер кочак салкын керде һәм, кәрә-керәшкә ак пар мендәренә әйләнеп, бүлмәгә таралды. Шул ак томан эченнән йөзеп чыккандай, каршыбызда ябык бер апа күренде:

— Әйдүк, түрдән узыгыз. Мәтрүнә, бу кунакларны кемнәр дип белик соң? — диде.

— Күрше авыллар. Микулайдан әтиләре турында сорашырга килгәннәр, әтиләре Мирсәгыйть атлы икән.

Хуҗа хатын никтер тынычсызлангандай булды һәм, такта белән бүлгән түр якка карап:

— Микулай, синең янга килгәннәр, Мирсәгыйть балалары,— дип эндәште.

Бүлмәдән буш җиңен бил каешына кыстырган аксыл чырайлы, озын буйлы кеше чыкты.

— Карыйк, карыйк, нинди кунаклар килгән икән безгә,— дип сөйләнде ул.

Тавышы бик ягымлы икән. Хәер, безнең әти яныннан кайткан ла ул! Мин аны-моны абайлаганчы, Фатих атылып барып, аның аягыннан кочаклады. Әйтерсең лә үз әтиебезне күргән. Мин, уңайсызланып, Фатихның җилкәсеннән тарттым.

— Безнең әти түгел ич ул!

Фатих аңа ябышкан да тынган.

Микулай дәдәй аның бүреген салдырып мич башына куйды.

— Әйдә, әйдә, егет, түрдән уз. Әтиең бик сагынып сөйли иде синең турыда. Менә нинди дәү булгансың икән!

Хуҗалар безне, чишендереп, түр якка алып чыктылар. Мин Микулай дәдәйгә алдан ук әзерләп куйган җөмләмне әйттем:

— Микулай дәдәй, сугышта безнең әтине күргәнсең икән, шуны белешергә дип килгән идек.

Микулай дәдәй бераз уйланып торды.

— Күрдем, балалар, соңгы сугышка әтиегез белән бергә кердек. Мин менә кулны өздереп кайттым. Ә әтиегез...—Агай никтер тотлыгып калды, исән кулы белән муенын сыпырып алды.— Әтиегез сезгә сәлам әйтте, сәлам генә түгел, менә бумажнигын да биреп җибәрде әле,— диде.

Бу сөенечле хәбәр безне әллә нишләтте. Соң инде дүртенче ай әтиебезнең бер хәбәре юк иде ич! Болай яныннан кеше кайткач, исән дә исән инде ул.

— Яле, карчык, әтиләренең бумажнигын тапшырыйк балаларына. Үзем барырга җыена идем сезгә. Менә чынлап торып аякка басарлык хәлем генә юк. Әниегезнең вафат булуын да ишеттек. Ничегрәк көн итәсез соң?

Әнине телгә алуы ярамадымы, Микулай дәдәйнең әти кебек иркәләп сөйләшүеме, үзем дә белмим, мин үксеп елап

җибәрдем. Еламаска телим — булмый, күземнән чишмә булып яшь ага. Фатих исә Микулай дәдәй каршына баскан да аның түшендәге медальләрне барлый.

— Елама, балам, тынычлан,— дип, башымнан сыйпады хуҗа апа...

Әтинең безгә җибәргән әйберләре бер бумажник кына түгел икән, бәләкәй бер төенчек. Мин, күз яшьләремне сөртеп, төенчекне кулга алдым. Аны иплэп кенә чишеп җибәрдем. Әтинең безгә бик таныш, таушалып беткән бумажнигы, өч медале килеп чыкты...

Мин әтинең бумажнигын ачтым. Аның эченнән өч сум акча, сугышка хәтле безнең белән төшкән фоторәсеме һәм без язган берничә хат килеп чыкты.

— Ә боларны ник җибәрде? — дип, тагын аптырап сорадым.— Бумажниксыз нишли инде ул үзе?

— Һи, кызым, сугышта бумажник ник кирәк ул? — диде Микулай дәдәй, үзе хатыны белән ялт кына күзгә-күз карашып алды.

— Анысы да бар инде,— дип килештем мин.

Тик никтер йөрәгем кысып куйды. Тик торганда әти бу әйберләрне җибәрмәс иде. Микулай дәдәйнең күзләре дә безгә туры карамый, нидер яшерә кебек иде. Әллә соң?..

Мин, бармакларым белән чытырдатып тотып, әтинең бумажнигын күкрәгемә кыстым. Өзгәләнеп, тагын сорадым:

— Әтием, чынлап та, исәнме?

— Әйттем ич инде! — диде Микулай дәдәй, үзе өзелгән кулбашын исән кулы белән сыйпап куйды, йөзен җыерды, ярасы сызлый башлады, ахры.

— Рәхмәт инде, Микулай дәдәй,— дидем мин, урынымнан торып,— без кузгалыйк инде. Яктыда урман аша чыгып калырга кирәк безгә.

Микулай дәдәй безне урманны чыкканчы озатып куйды. Фатих аның исән кулына асылынган да туктаусыз сөйләнә:

— Микулай дәдәй, әти кайткач, без аның белән үрдәк атарга барабыз әле. Бах...бах...бах... берьюлы өч чүрәкәйне әти чөеп кенә төшерә.

— Барасыз, барасыз,— диде Микулай дәдәй, аның сүзен җөпләп.

Минем күңелемне ниндидер шик кимерә. Микулай дәдәйнең яшерен серен белергә теләгәндәй, аның йөзенә текәлеп карыйм. Бер дә болай шикләнерлек урын юк кебек. Йөзе

тыныч. Әтинең исән икәнен бик ышанырлык итеп әйтте бит. Тик әти нигә бумажнигын безгә җибәрде икән?

— Микулай дәдәй, әти кайткач, син безгә килерсеңме?

— Киләм, килмимме соң! Әтиегез белән бик дуслар идек, гел бергә булдык. Бер-береңнең гаиләсе турында кайгыртырга, дигән сүзебез дә бар.

Урман авызында баскан килеш Микулай дәдәй безнең арттан озак карап калды. Без энем белән ялтырап яткан чана юлы буйлап авылга таба йөгердек. Әтинең исән хәбәрен тизрәк әбигә җиткерәсе килә иде.

Әби безне капка төбенә чыгып каршылады. Өйгә кергәнне дә көтмичә, Фатих кесәсеннән әтинең медальләрен чыгарды.

— Менә, әби, әтинең медальләре. Әллә ничә немецны берьюлы бәреп салган ул. Шуның өчен биргәннәр. Аннары бумажнигын да җибәргән әле, өч сум акчасы да бар.

Фатихның сүзләрен ишеткәч, әбием хәлсезләнеп болдыр баганасына сөялде.

Без атылып өйгә кердек. Мин, әбидән бигрәк үз-үземне ышандырырга теләп:

— Әби, әти исән. Микулай дәдәйне озатып калган,— дидем.

— Микулай дәдәгез үзе безгә килермен димәдеме соң?

— Килә, менә җәй генә җитсен, әти кайткач та килә,— дип такылдады энем.

Әби яулык читләре белән күзләрен сөртте. Аннары мич буена утырып озаклап дога кылды. Әтинең бумажнигын, медальләрен кулына алып озак кына карап торды.

— Җыеп куйыйк боларны, оланнар, әтиегез төсе, югалмасыннар... Үскәч, бер алып карарсыз,— диде һәм, бумажник белән медальләрне барын бергә төенләп, сандык төбенә яшерде.

Әтинең үлеме турындагы кара мөһерле кәгазьнең дә инде өч айдан бирле шул сандык төбендә ятуын без, балалар, белми идек әле.

1982 ел

Иҗади эш

Хикәягә анализ ясыйк. Балалар һәм өлкәннәр турында дип, ике өлешкә бүлик. Эчтәлекне табу өчен, өлешләрне берәм-берәм өйрәник. Беренче өлешнең эчтәлеген кыскартып болай язар идек:

Хикәянең бер өлеше балалар хисе турында. Балалар әтиләренең фронттан кайтуын түземсезлек белән көтәләр.

Әтиегез исән, тиздән кайтыр, дип ышандыргач сөенәләр. Дөрес, балаларның өлкәнрәге олылар сүзенә бигүк ышанып бетми. Ләкин әтисен күрү өмете шулкадәр көчле булу сәбәпле, ул яман уен тизрәк онытырга тырыша.

Бу өлештә шактый үзенчәлекле хисләр каршылыгы белән очрашабыз. Без, укучылар, балаларның алдануларын күреп торабыз. Аларның сөенечләре, өметләре юкка булуы өчен борчылабыз. Безнең борчылу хисебез балалар шатлыгы белән каршылыкка килде. Без көндәлек әсәр вакыйгасын дәвам итәбез: хакыйкатьне белгәч, әнисез дә, әтисез дә калган дүрт бала хәсрәтен күз алдына китереп, аларның язмышы өчен хәсрәтләнәбез.

Биремнәр

1. Икенче өлеш эчтәлеге өлкәннәр хисе турында, дидек. Микулай көнелендәге хисләр каршылыгын аңлатып языгыз.
2. Әбинең хисләре турында сөйләгез.

Йомгак ясыйк

1. Хикәя жанры белән таныштык. Укыган хикәяләрнең һәркайсында төп герой холкына аеруча игътибар ителүен күрдек. Димәк, хикәя язсак, иң элек холкы үзенчәлекле герой образын эзләп табарга кирәк икән.

2. Хикәяләрнең күбесендә төп геройның кичерешләре үзенә бер вакыйгага булуын белдек.

3. Тагын бер мөһим үзенчәлек — холык күп очракта хисләрнең сәбәбе ул. Шәфкатьле кеше елаган баланы кызгана. Усал кешенең елау тавышына ачуы килергә мөмкин. Әнә шулай тормыштагы бер үк вакыйга төрле холыклы кешеләрдә төрле хис тудыра. Хикәя авторлары шуңа күрә хис белән холыкны сәбәп-нәтиҗә итеп ялгыйлар.

4. Хикәя сюжеты башлам, төенләнү, киеренкелекнең иң югары ноктасы һәм чишелеш кисәкләренә бүленә.

Ләбибә Ихсанова

Безнең ишегалдында

Күбәү без ишегалдында. Малайлар да, кызлар да бар. Башлыгыбыз — Мәхмүт. Буе безнең хәтле генә булса да, барыбыздан да көчлерәк ул. Алтынчы сыйныфта укый. Ә безнең кайсыбыз бишенчедә, кайсыбыз дүртенчедә генә әле.

Ял көне булдымы, иртәдән кичкә кадәр ишегалдында без. Кар атышып, әүмәкләшеп уйный-уйный кып бабай төсле ап-ак булып бетәбез. Әниләр ачуланалар. «Кеше төсле уйный да белмисез бит»,— диләр. Кеше төсле уйнау ничек буладыр ул?

Беркөнне капка төбенә чыгып бастык та кая барырга белми аптырап тик торабыз.

— Әйдәгез, малайлар, каток ясыйк. Рәхәтләнеп шуарбыз, ичмасам,— дип куйды Мәхмүт.

Шундый инде ул. Беребез дә уйлап таба алмаган эшләрне оештыра да йөри. Әле ярый Мәхмүт бар. Юкка гына башлыгыбыз итмәдек шул без аны.

Йөгереп барып көрәкләр, себеркеләр алып килдек. Чиләк тотып кызлар чыкты. Барыбыз да җыелгач, катокның урыны турында тарткалаша башладык. Утын сарайлары артында бик иркен бер буш урын бар иде. Без, малайлар, катокны шунда ясыйк, дибез. Ә кызлар безгә каршы киләләр:

— Ул бик читтә. Анда күрше йортның малайлары да килеп интектерер. Безнең ишегалды катогы булмый инде ул,— диләр.

— Килсеннәр. Шуарга күңеллерәк булыр. Аңар карап, катокның бозы кителеп төшмәс бит,— дип, без каршы киләбез.

Мәхмүт кенә озак бәхәсләшергә ирек бирмәде, барыбыздан да катырак кычкырган Таһирның башына сугып туктатты да:

— Сарайлар артын билдән кар күмгән. Иң элек бульдозер белән чистартып чыгарга кирәк. Йә, кайсыгызның бульдозеры бар, алып килегез,— ди бу.

Каян килсен ди безгә бульдозер. Без артык бәхәсләшеп тормадык. Ишегалды уртасының карын көрәргә, себерергә тотындык! Караңгы төшеп, ишегалдында электр утлары кабынганда, зур гына мәйданчык тап-такыр иде инде. Су сибә башладык. Кызлар чиләк белән ташып торалар, без сибәбез, мәйданчык боз белән каплана бара.

Иртән торып чыкканда, боз өсте шыкырдап каткан иде инде. Без бер-ике тапкыр гына шуып үттек тә мәктәпкә йөгердек.

Тик кайтуыбызга катокның бозын чабып, ишегалды уртасына өеп куйганнар иде инде. Кайсының эше булыр бу, дип уйлыйбыз. Кем дип әйтергә дә белмибез.

— Кем булсын инде,— диде Мәхмүт,— Шәйхулла бабай эше генә бу. Ишегалдын ул чистартамы, ул! Әйдәгез, үзен дә кызык итик. Моннан соң безнең эшкә тыгылып йөрмәс.

Шәйхулла бабайның өен бикләп киткән вакытын чамалап торырга да ишегендәге йозакның эченә кар тутырып, су сибеп катырырга кирәк.

Тагын бәхәс китте.

— Карт кешене ничек кызганмыйсыз? — диләр кызлар. Ә безнең җавап әзер:

— Үзе безне кызганмаган бит әле. Әйдә, өенә керә алмый азаплансын бераз.

— Әшәкеләр сез, хулиганнар,— диләр кызлар,— без сезнең белән уйнамыйбыз.

Алар шулай дип китеп бардылар. Миңа бик читен булды. Эчемнән генә кызларны яклап торган идем. Шулай да аларга ияреп булмый бит. Соңыннан малайлар, үртәп, күзеңне дә ачырмаслар...

Дәрес әзерләп утыра идем, әни кайтып керде:

— Кеше башына бәла ясап йөрисез шунда,— дип, күру белән мине ачулана башлады ул.— Кем аяк астына боз катыра, ди. Әнә Шәйхулла бабай таеп егылган. Кулын каймыктырган. Җитмәсә, больницадан кайтуына, йозагын бозып куйганнар. Кайчаннан бирле өенә керә алмый тора, бичара. Анысы да сез юньсезләр эшедер әле!

Әллә нишләп киттем. Чәч төпләрем тирләп чыкты. Сикереп тордым да, тунымны эләктереп, ишегалдына йөгердем.

Мин килеп җиткәндә, Гасыйм абый, балта белән сугып, йозакны ваткан, бәйләгән кулын муенына аскан Шәйхулла бабайны җитәкләп өенә кертеп маташа иде. Баскыч төбендә торган кызлар мине күреп алдылар да менә тиргиләр, менә тиргиләр, ник чыкканыма үкенә башладым.

Ул арада Гасыйм абый да килеп чыкты. Миңа карады да:

— Менә бит ул нинди эшләр! — дип куйды. Әйтерсең мин генә гаепле...

— Йә, нишлибез, егетләр? — диде Гасыйм абый, чабып өелгән боз өстенә таба күрсәтеп.— Кичә мин чабып ташладым аны. Бик аяк астына ясагансыз...

Бирем

Хикәяне кем ничек тәмамлый ала, шулай тәмамлагыз.

ЛИРИК ШИГЫРЬЛӘР

Лирик шигырьләрнең эчтәлеге хис булуын беләбез. Шатлык, ямансулау, көнләшү, ярату, үкенү, ачу килү һ. б. Хикәяләрдә, повесть, роман, пьесаларда кеше төрле яктан сурәтләнә. Ә лирик шигырь кешенең бер генә ягын — кичерешләрен сурәтләү белән чикләнә.

Лирик шигырьләрдәге үз хис-кичерешләре турында сөйләүче төп кешегә **лирик герой** диләр.

Лирик шигырьләрнең эче тулы кабатлау: строфа саен рифма, ритм, басым һ. б. Алар билгеле бер тәртипкә буйсынып урнашканнар. Строфалар үзләре дә бер-берсенә күп яклары белән охшыйлар. Аларның күбесендә дүрт юл. Күбесендә рифмалар юл аша урнашалар, беренче һәм өченче, икенче һәм дүртенче юллардагы иҗек саннары кабатлана.

Лирик шигырь үзенчәлеген белү бу жанр эченә кергән әсәрләргә анализ ясауны күпкә җиңеләйтә. Чөнки уртак сыйфатлары булган әсәрләргә анализ бертөрле ясала.

Габдулла Тукай

Милли моңнар

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир[1] безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

---

[1] Тәкъдир — язмыш.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Таплап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, Әллүки!»

Биремнәр

1. Шигырьнең эчтәлеген сөйләп аңлатыгыз.
2. Баштагы ике һәм соңгы строфаларны ятлагыз.

Хәсән Туфан

Кояшта тудың микән

Кояшта тудың микән,
Йолдызда тордың микән?
Өйгә ай кердеме дисәм,—
Ул синең нурың икән!

Кигәннәрең ал икән,
Гөләп белән пар икән;
«Ай ни, ул ни!» — диләр иде,—
Халык сүзе хак икән!

Керфекләрең кагасың,
Моңсу гына багасың;
Ай кояштан нурлар ала,
Ә син кайдан аласың?

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

Хәсән Туфан

Давыл

Кем дә инде миңа, Бишбалтага,
Килмәс инде дигән шикелле,
Ялгыз булып утыра идем шунда,
Ялгыз калып,
Бикләп ишекне.

Ачмасаң да керәм! дигән сыман,
Ишек шакый тагын кайсы чорт?!
Һәм ун баллы давыл кебек булып
Килеп керде
Тиңсез якын дус.

Керен шулай
Минем тын бүлмәгә,
Давыл килеп кергән шикелле,
Үзе белән гүя Сыркыдының
Усаклары шавын китерде.

Күтәренке шундый
Безнең күңел,
Шундый тирән безнең куаныч:
Бер-беребезне гүя өч көн түгел,
Ә утыз ел күрми торганбыз!

Сөйләшүләр безнең, киңәшүләр
Шундый матур гөрләп куйгалый:
Утыра монда өстәл тирәсендә
Ике Хәсән, гүя дүрт Һади...

Беребезнең сүзе бетәр-бетмәс
Икенчебез баса,
Сүз башлап,
Гөрләп тора бүлмә, әйтерсең лә
Тугыз Туфан анда, ун Такташ!

Киңәште ул,
Көлде-шаярды ул,
Мишәрчәләп хәтта җырлады...
Һәм туздырып китте
Өстәлдәге барлык китапларны,
Йөрәктәге барлык уйларны.

«Давылларда туып, канатланган
Бунтарь йөрәк туеп тынлыктан»,
Яңгыр китерә торган давыл сыман,
Дулый шулай язар алдыннан.

Азмы тапкыр шулай килеп чыгып
Һәм таратып сагыш-кайгымны,
Мәңгелеккә, ахры, йөрәгемдә
Урманнары шавын Сыркыдының,
Усаклары шавын калдырды...

* * *

Син йөргән юлларга быел да
Май ае чәчәкләр китерде:
Сине бит кайтыр дип уйлый ул,
Миңа да —
Кайтырсың шикелле.

Көз киткән тургайлар кайттылар,
Чәчәкләр терелде, ә син — юк.
Моңая таң саен сандугач:
Ул сине юксына минем күк...

* * *

Мин генәме, Һади, сагынам сине,
Мин генәме шулай юксынам,
Юк,
Һәрбер чәчәк миңа:
«Тап син аны,
Сәлам тапшыр миннән!» — ди сыман.

Үпкәлисе килә сиңа бераз,
Сагындырган өчен ул кадәр...
Тик бер генә, тик бер генә көнгә
Кайтсаң иде терелеп син әгәр...

Күрер идең:
Корычланып, кырысланып беттем,—
Еллар мине шулай иттеләр.
Чәчләргә чал кертеп уза торган
Читен хәлләр баштан үттеләр.

Теләсәм дә елап булмаганда,
Җан таштан да катыланганда,
Күзләрдә яшь түгел, ә яшәүгә
Соңгы сәлам нуры янганда,
Кулымда мин синең кулны тойдым...

Беренче кат көрәшү минутында,
Сиздек микән үзебез, юк микән,
Кулларны без
Мәңге аерылмаска,
Ташламаска биргәнбез икән...

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

Габдулла Тукай

Пар ат

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.

Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.

Берзаман ачсам күзем, бертөрле яп-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә бер тапкыр күрәм.

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.

Хуш, гомер иткән шәһәр! инде еракта калдыгыз;
Аһ! таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.

Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;
Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

Әллә нәрсәм юк кеби; бер нәрсә юк, бер нәрсә ким;
Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.

Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?
Бикмөхәммәт, Биктимер — берсен дә белмим, әллә кем!

Сездән айрылып, туганнар! — җайсыз, уңайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш, айсыз тору.

Шундый уйлар берлә таштай катты китте башларым;
Чишмә төсле, ихтыярсыз акты китте яшьләрем.

Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан!»

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан[1], монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

1907 ел

Татар халкының бөек шагыйре ятимлектә үсә. Бала чагын чит-ят гаиләләрдә яшәп үткәрә. Аны асрамага әле бер гаилә, әле икенчесе ала. Нәни Габдулла авылдан авылга күчеп йөри торгач, аны ерак туганнары эзләп табалар һәм Уральск шәһәренә алып китәләр. Монда да булачак шагыйрь озак яши алмый. Ул эшләгән газета-журнал редакцияләре ябылалар, һәм Габдулла Тукай эшсез кала. Шагыйрь бер ят җирдән икенчесенә — Казанга китәргә мәҗбүр була.

Яшь егетне Казанда ничек каршы алырлар? Анда да туганнар да, торыр урын да юк бит!

Шагыйрь борчулы уйларын, өметләрен «Пар ат» әсәрендә сөйли.

Биремнәр һәм сорау

Шигырьдә лирик каһарманның рухи халәте өч төрле. Башта аны канәгатьлек, тынычлану хисе биләп ала. Бу халәтнең сәбәпләре берничә: ниһаять, мәшәкатьләр бетеп юлга чыгу. Атларның шәп кенә баруы. Күңелгә ятышлы таныш якларның табигать матурлыгы.

[1] Гыйрфан — аң-белем, мәдәният.

1. Лирик герой хисенең ничек үзгәрүен аңлатыгыз.
2. Шигырьдә хис дәрәҗәсе сурәтләнгән урыннарны бергә җыегыз.
3. Лирик геройның үзен үзе юаткан урыннарын табыгыз.
4. Шагыйрь Казанга шомланып, ләкин зур өметләр белән килә. Шул өмет белән бәйләп, әсәрнең исеменә бәя бирегез. Ни өчен Габдулла Тукай шигырь исемен «Пар ат» дип куйган?

ДРАМАЛАР

Драма — матур әдәбиятның бер төре. Ул **трагедия, драма, комедия, мелодрама, водевиль, фарс** кебек жанрларга бүленә.

Драма жанры белән танышыйк. **Драма жанрына** сәхнәдә уйнау өчен иҗат ителгән әсәрләр керә. Бу жанрның төп үзенчәлеге икәү:

1. Драмада катнашучы персонаж, лирик герой кебек, үзенең хисен сөйли. Үзенә багышлаган җырын ишеткәч, Хәмдия менә ничек шатлана: үзенә үзе рифмасыз шигырь сөйли диярсең:

Ах, минем үз көем бар. Берәүгә хасланган мәхәббәтемне дә күләгәдә калдырырлык, күңелемне кол иткән көем бар. Исемем халык телләрендә мәңге тирбәлә. Исемем телдән телгә, буыннан буынга күчеп мәңге яшәр. Бәхетле мин, бәхетле! Бәхетле! Бәхетле!

Бакый Хәмдиягә әйтәсе мәхәббәт сүзләрен шулай ук үзенә үзе шигырь сөйләгән кебек сөйли:

Туташ, белмисең көтүче күкрәгендә ниләр барын. Исемеңне телләрендә тибрәтеп төннәр буе тилмереп йөргән бәхетсез — мин ул. Гыйшкың белән янып, мәхәббәт җырлары тезгән гашыйк — мин ул. Бәхетсез гыйшык белән корбан булырга яратылган бәндә — мин ул... Мин сине сөям. Бөтен тиңсезлекләремне белә торып сөям. Кил, Хәмдиям, вәгъдәләреңне көтүчелегем каршында каушатма!

Шуның белән бергә драма әсәрләрендә, чәчмә әсәрләрдәге кебек, үзенчәлекле холкы булган герой һәм сюжет бар.

2. Драма жанрына кергән әсәрләр кискен конфликтка корылалар.

Драмадагы конфликтлар

Драма әсәрләренең үзегендә конфликт ята. Конфликт дип персонажларның үзара көрәшенә әйтәләр. Бусы — **тышкы конфликт.**

Кеше, нинди дә булса хисен, теләген басу өчен яки начар гадәтеннән бизү өчен, үз-үзе белән дә көрәшергә мөмкин. Авыр кичерешләр тудыручы шундый көрәшкә **эчке конфликт** диләр.

Драма әсәрләрендә, лирик шигырьләрдәге кебек, эчке каршылык (конфликт) һәм, повестьлардагы кебек, тышкы конфликт күрәбез.

Әсәрдәге геройларның максатына ирешү юлында конфликт туа. Ул юлда каршы торучы, комачаулаучы кешеләр дә, табигать киртәләре дә, кануннар да, кагыйдәләр дә, кабул ителгән гадәтләр дә булырга мөмкин. Конфликт шулар белән көрәштән гыйбарәт.

Конфликт безгә таныш ак белән кара янәшәлеге кебек каршылык бәйләнеше түгел. Ул фәкать көрәш кенә була ала.

Димәк, драма жанрына кергән әсәрләрне, икеләнмичә, конфликтка катнашкан каршы якларга бүлә алабыз.

Иң күренекле драма әсәрләренең берсе белән танышыйк. Аның авторы — Мирхәйдәр Фәйзи.

ДРАМАНЫҢ АВТОРЫ ТУРЫНДА

Мирхәйдәр Фәйзи (1891—1928) — ишле гаиләнең унберенче баласы. Авылда туып үскәнгә, табигатькә, авыл кешеләренә балачактан ук гашыйк әдип. Хисләре күңеленә генә сыймагач, көндәлек дәфтәрләренә дә күчкән. Мирхәйдәр Фәйзи барлыгы җитмешкә якын көндәлек дәфтәре язып калдырган. Дәфтәрләрен ул, әлбәттә, үзе өчен язган. Яза-яза үзе белән үзе бәхәсләшкән, гаделсезлектән дә үзенә үзе зарланган, күзенә чалынган матурлыклар турында да үзенә үзе сөйләп сокланган. Көндәлек дәфтәрләренең берсендә болай яза:

«Кич ай яктысында, тирәнең серлегенә, күк йөзенең яменә хәйран булып озак йөрим. Авыл тынгач, ай яктысында озак уйлар, тойгылар дөньясына батып, тәннәр буе утырам... Әй Ходаем, мине ... җир яменнән аерма».

Мирхәйдәр Фәйзигә табиблар авылда яшәргә киңәш итәләр. Авылда ул халык иҗатын өйрәнә. Әйтем-мәкальләр, әкиятләр җыя. Җыйган җырларының берише «Халык җырлары» исемле китап булып дөнья күрә.

Драматургны күп эшләргә мәҗбүр иткән ихтыяр көче, табигатькә, кешеләргә мәхәббәте пьесаларындагы персонажларына да күчкән. Ул иҗат иткән персонажлар — үзе кебек

ярата белә торган, нечкә күңелле, мөстәкыйль фикерләүче матур холыклы шәхесләр.

Мәдрәсәнең беренче сыйныфында ук көндәлегенә: «...шагыйрь булу, артист булу, музыкант булу кебек уйлар белән җенләнәм»,— дип яза. Һәм шәкерт чагыннан башлап шул максатына ирешү өчен бөтен көчен куя. Авыру сәбәпле мәдрәсәне тәмамлый алмаса да, үз заманының белемле зыялыларына әйләнә. Өендә авыл китапханәсе булырлык китап туплый. Үзлегеннән белемен күтәрә. Төрки, рус, фарсы телләрен дә үзлегеннән өйрәнә. Ундүрт яшендә «Татар туе» исемле беренче пьесасын яза. «Галиябану», «Ак калфак» кебек татар халкының аеруча яратып укый һәм сәхнәгә куя торган пьесаларын иҗат иткәнче, газета-журналларда мәкаләләр бастырып, шигырьләр язып сәнгатьчә фикерләргә өйрәнә.

«Ак калфак» пьесасы белән танышкач, «Кеше Бакый яраткан дәрәҗәдә яратмый, Хәмдия кебек минут эчендә мәхәббәтен берәүдән икенче берәүгә күчерә алмый» диярсез. Ләкин әдип мәхәббәт хисен тасвирлаганда үзе теләгән дәрәҗәдә арттыра һәм әкиятләрдәге кебек, адәм ышанмаслык дөньялар, персонажлар уйлап чыгара ала. Хәмдия хисен минут эчендә үзгәртү дә аның өчен тормыш дөреслегеннән китү түгел. Тормыш дөреслегенә әдипләр үзләре уйлап чыгарган вакыйгалары һәм персонажлары белән дә ирешә алалар.

Тормышны хыял кушып тасвирлау алымына **романтизм методы** диләр.

Мирхәйдәр Фәйзи

Ак калфак

(Драма өч пәрдәдә)

Вакыйгаларда катнашучылар:

Сәлим — мирза, 60 яшьтә.
Җиһан — аның бикәсе, 60 яшьтә.
Хәмдия — аларның кызы, 19 яшьтә.
Шаһтимер — икенче бер мирза баласы, 22 яшьтә.
Бакый — Сәлим мирзаның көтүчесе, 24 яшьтә.
Рушан — 20 яшьтә. } Хәмдиянең хезмәтчеләре.
Гафия — 18 яшьтә. }
Гөләндәм. Кунак кызлар вә башкалар.
Хөсәй — бер карт, 60 яшьтә.
Гали — кечкенә хезмәтче, 13 яшьтә.

Вакыйга 1860 елларда, Сәлим мирзаның имениесендә бара.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Челтерәп агып яткан кечкенә елга. Елга буйлап зирек агачлары тезелгән.
Арырак куй-сарык көтүе утлап йөри. Су читендәге бер зур гына таш өстенә көтүче Бакый утырган. Матур яшь егет.

БЕРЕНЧЕ ҺӘМ ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШЛӘР

Бакый *(таягының башын пәке белән юна-юна җырлый).*

Хөсәй керә. Сакалы агарган, аркасы чыккан, йончыган бер карт. Чабаталы; чикмәнен юкә белән буган, татар бүреге кигән. Бакый җырлаганда кереп, беткәнче таягына таянып, тыңлап тора.

Хөсәй. Безнең балаларыбызның моңы каршында таулар, ташлар тетрәп тора.

Бакый. Мин моңлы түгел, бабай. Көтүчелектә рәхәтләнеп йөрим. Мин иркле сахра баласы. *(Көтүгә таба тавыш биреп чыбыркы шартлата.)*

Хөсәй. Синең туганнарың боярга ялчылык итә. Аларның аһ-зарлары белән күкләр тетри. Менә бу *(сакалын күрсәтеп)* ак сакаллы алтмыш яшәр бабаларыңның җилкәсендә Сәлим мирзаларның таягы уйнап торганда, син ничек моңланмыйсың? *(Җилкәсен тартып.)* Уф, сыкрый. *(Җиргә утыра.)* Менә әле синең Сәлим мирзаңның таягын җилкәмә йөкләп кайтып барам. *(Елый.)*

Бакый. Кыйнадымы?

Хөсәй. Минем кулдан елаудан башкасы килми. Сез яшьләр дә гомерегезне безнең кебек, боярлар кулында таланып, кыйналып уздырып җибәрерсезме?

Бакый *(аның янына утыра).* Синең сүзләрең йөрәгемә ут салды. Сәлим мирзадан синең ачуыңны алырга вакыт көтәрмен. Бабай?.. Мирзаның кешесе булыр, ат менгән берәү йөри. Юлың уң булсын, карт!

Хөсәй *(тиз торып).* Хуш! Акыллы, батыр бала бул! *(Ашыгып китә башлый.)*

Бакый. Теләгең кабул булсын! *(Чыбыркысын шартлатып.)* Һәйт! Һәйт!.. *(Сызгыра, куйларга таба китә.)*

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шаhтимер керә. Ул кызыл итекләр, кондыз бүрек кигән, билендә көмеш кәмәр[1], кулында кашлар белән бизәлгән көмеш саплы камчы. Җырлап килә.

Шаhтимер *(каранып)*. Сәлим мирзаның көтүчесе... Егет!

Бакый *(керәп, коллык итә)*. Хуш килдең, мирза!

Шаhтимер. Егет, син Сәлим мирзаның көтүчесеме?

Бакый. Хезмәткәрең әмереңә әзер.

Шаhтимер. Әмер түгел. Егет, бер үтенечемне үтәп, минем дустым бул!..

Бакый. Гаеп итмә, мирза, бер көтүче асыл сөяк бер мирза баласының дусты була алырмы? Хезмәтең булса турыдан-туры боер.

Шаhтимер *(аңа дикъкать белән карый)*. Син көтүче?.. Син Сәлим мирзаның көтүчесеме? Яшерми әйт, егет, син бары көтүче генәме? Яки шул киемнәр астына яшеренгән бер аксөякме?

Бакый. Ник?

Шаhтимер. Синдә бер нур балкый. Сүзләрең очкын кебек. Син — бер асыл зат!

Бакый *(шулай ук нык рәвештә)*. Түгел! Йомышыңны әйт тә, мирза, мине бушат. Мине әнә утлап йөргән дусларым көтә.

Шаhтимер *(җай гына)*. Ярың көтәме? Сөйгәнең белән кавышырга ашыгасыңмы? Җиләк җыю сылтавы белән килгән мирза кызы Хәмдия белән кавышуыңа комачаулыйммы?

Бакый. Мирза кызларын сөю түгел, баскан эзләрен дә күргәнем юк. Каушама, мирза, назлы ярың булган Хәмдияңне сөюдә мин көндәш түгелмен.

Шаhтимер *(кинәт актырып)*. Син беләсеңмени?

Бакый. Ул синең йөзләреңә язылган. Ул синең бер көтүчедән көнләшүеңнән билгеле. Әйт, егет, син минем илче булуымны телисеңме?

Шаhтимер *(тынычлап)*. Серләремнең тугры уртагы бул! Миңа бер хезмәт итеп, җаның теләгән нәрсәне сора. Хәмдия туташ монда бит?

Бакый. Алар җиләккә килгән.

---

[1] Кәмәр — билбау.

Шаһтимер. Кыйммәтле бүләкләр бәрабәренә туташка миннән хат илт.

Бакый. Мирза, син Сәлим мирзаның чиксез явызлыгын беләсеңме? Читкә китеп бер куйдан гына аерылсам да, ул аны каным белән түләтәчәк.

Шаһтимер. Куйларыңны мин багам. Бир чыбыркыңны! Туташның каһәреннән куркып, каршында сүз ачарга батырчылык итә алмаган гашыйк өчен җәбраил[1] бул! Йөрәгемнең сәламнәрен ирештереп, куенымдагы алтын сәгатемне ал. Хәмдия миңа яр булса, иярләгән акбүз юргам[2] — синеке!

Бакый. Син Шаһтимерме?.. Сине яхшы күңелле кеше дип ишеткән идем. Ярый! Мин синең хезмәтеңне өстемә йөкләдем. Мирза кызы моңарчы йөзенә карарга да хурланган көтүчесеннән бәхетенең ачкычын тапсын. Мә сиңа чыбыркы! Мин килгәнче куйлар — сиңа әманәт. Бер сүзем бар: алтын сәгатьнең чылбыры мирза кызы тирәсендә йөргән ярлы кызының муенын матурламасмыни?

Шаһтимер *(йөзеген салып бирә).* Бир аңа йөзекне. Менә хат, менә сәгать.

Бакый. Теләктә бул! *(Китә.)*

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шаһтимер *(чыбыркысын җилкәсенә салып, ташка утыра).* Йөрәгенең тавышын ишеттерергә әмәл тапмаган моңлы егет бер көтүче алдында баш иде. Аның кушуына кол булып, җилкәсенә чыбыркы элеп, куйлар көтә. *(Читкә карап.)* Түчә!.. *(Торып көтүгә таба йөгерә.)* Түчә! Тву-у!.. Маһ-маһ-маһ... Дөгә, дөгә, дөгәшкә!..

Бакый кайта.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Шаһтимер.

Шаһтимер *(йөгереп керә).* Көтүче, җәбраил, изге хәбәрләр белән!

Бакый. Хәзер туташ кызларыннан берсе алтын йөзек эзе белән монда килә. Син аны күрмәскә тиеш.

Шаһтимер. Кызның колакларына, түшләренә миннән алтын бизәкләр вәгъдә ит! *(Чыгып китә.)*

---

[1] Җәбраил — илче.

[2] Юрга — юргалап чаба торган ат.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Гафия керә. Зур калфак кигән яшь кыз.
Бакый.

Бакый *(сәгать белән атка карап).* Бер кыз өчен алтыннарыннан, юргаларыннан ваз кичеп саташып йөри. Ә мин шушы киң сараемны нинди кызлар белән дә алыштыра алмыйм.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Гафия.

Гафия *(ашыгып килә).* Матур егет! Көткәнең бер үбеш булса, аны ал да күземне чагылдырган йөзегеңне бир!

Бакый. Алтын йөзек бик кечкенә хезмәт белән синең кулыңа күчә. Менә бу хатны мирза кызына тапшырсаң, йөзек синеке.

Гафия *(гаҗәпләнеп карый).* Мирза кызына хат? Көтүчедән мирза кызына? *(Йөзенә карап тора.)* Гаҗәп түгел. Тик мин көнләшәм, аны ертып ташлыйм.

Бакый. Юк, бу — бер мирза баласының хаты. Син һәм мин — алтын балдак белән алтын сәгатькә сатылган илчеләр.

Гафия *(хаттан элек йөзеккә атыла).* Тапшырам. Ах, матур! Нинди бәхет! Ярый, хатны бир... Хуш, җаный!

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бакый, Гафия.

Гафия. Туташ хәзер бире килә.

Бакый. Үзе килә? Алайса, алтыннар хуҗасының эше гөрли.

Гафия. Киләләр. *(Каршы йөгерә.)*

Хәмдия, Гафия вә башка кызлар керәләр.

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Хәмдия, Гафия, кызлар.

Хәмдиянең аягында чуар читек. Өстендә укалы асыл күлмәк, хәтфә камзуллар. Башында ефәк белән чигелгән ак калфак, аның очына ука чук таккан, койрыгы җилкәсенә кадәр салынып тора. Калфак өстеннән ялтыравыклы ефәк шәл ябынган. Аларны күрү белән, Бакый чәчәкләрне Хәмдиянең алдына ташлый.

Хәмдия. Фәкыйрь көтүченең матур кыланышлары өчен Хәмдиянең рәхмәтләре бар.

Бакый *(башын иеп тора).* Ярлыларны куандыра белгән туташны хөрмәт итәм.

Хәмдия. Матур сүзләр. Яшь күңелләрнең сәламен ташу өчен, лаек бер илче... Ал, илче, бу хатны! Ал да яшь мирзага илтеп, ахак[1] кашлы көмеш иярен сора.

Бакый, моңарчы иеп торган башын күтәреп, хатны алганда беленерлек үзгәреш ясый. Хат кулыннан төшә.

Хәмдия. Хәерле фал булсын! Хат синең кулыңнан кача.

Бакый *(җирдән хатны ала).* Хат качмый, хат эчендәге сүзләрдән куркып, котүченең кулы кача. Гафу ит!

Хәмдия. Кайгырма, егет, син аңа көткән җавабын илтәсең. *(Бакый сугылган төсле була.)* Әйт син аңа, мәхәббәт каһарманы булса, телләреннән тамдырган гөлләрен күңел чишмәсе белән сугарып бирсен!

Бакый *(карап кала).* Аh!

Бакый катып тора. Хәмдия китә.

УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый.

Бакый *(баскан урынында сүзсез тора. Күзен Хәмдияләр юлына теки. Бераздан башын иеп, ташка утыра. Үзен белешмәгән хәлдә кулындагы хатны ерткалый. Соңыннан сизеп сикереп тора).* Ерттыммы?.. *(Карап тора да кинәт кәгазь кисәкләрен суга бәрә. Алтын сәгатьне алып ташка утыра. Чылбырыннан тотып суга тыгып уйната башлый.)*

Шаһтимер керә.

УНӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Шаһтимер.

Шаһтимер *(атылып килә).* Илче! Туташны алдыңа кадәр китерә алган бәхетле илче!

Бакый, аның тавышын ишетү белән, сәгатьне судан ала; урыныннан кузгалмый, эндәшми.

Хәбәрең изге булса, ал минем акбүз юргамны!

Бакый *(күтәрелеп карамый гына сәгатьне аңа суза).* Мә!

---

[1] Ахак — кыйммәтле таш.

Шаһтимер *(чигенә)*. Ул минем мәхәббәтемне кабул итмәде. *(Бакыйга карый.)* Ул көтүче киеменә төренгән үз ярына килгән... Ул Шаһтимер гашыйкның күңелен кыруны шул йөргән куйларның аягын кырудан да җиңел санады. *(Җирдән таш ала.)* Сөенегез, Хәмдия өчен аһ иткән егетләр! Хәмдия сездән алда торган Шаһтимерне таптап үтте. *(Ташны көтүгә таба селти. Куйларның тупырдап кузгалганы, бәэлдәгәне ишетелә.)* Ләкин Хәмдия исеме Шаһтимер йөрәгендә мәңге иркәләнеп тирбәлер! *(Куйларга карап.)* Гафу ит мине, гөнаһсыз хайван! *(Чыга.)*

УНДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый.

Бакый *(тора, бер Шаһтимергә таба, бер көтүгә карый. Бераздан кулындагы сәгатьне ташка бәрә)*. Гафу ит мине, Шаһтимер!

Пәрдә төшә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәлим мирзаның бай җиһазлар белән җыелган кунак бүлмәсе. Өстәлдә дә шәмдәлле шәмнәр бар. Идәндә хәтфә паласлар. Бер як стенага мылтык, кылыч кебек кораллар куелган. Сәхнә буш. Тыштан калын тавыш белән кычкырынган тавышлар ишетелә. Күп тормый Рушан керә.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рушан.

Тавыш. А, лав, гөр, ян, у, вах, тан... (Сүз *аңлашылмый, ерактан килә.)*

Рушан *(тәрәзәдән карый)*. Ходай күрсәтмәсен, юлбарыс рәвешенә кергән. Җимерә, кыра, вата. Кара инде, ул камытларның, дугаларның ни гаебе бар? Атып-атып бәрә... Ай, каравылчыны әләктереп алды... Алла сакласын, бер сарыкның аягы сынган өчен дөнья куптара. Мескен көтүчене кайткач ни көтә инде? Болай булса безгә дә өлеш тияр. Ычкынып китте инде, берничә көнсез тагы ипкә килмәс...

Хәмдия керә. Шәлсез, ак калфагы белән генә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рушан, Хәмдия.

Хәмдия. Атакай Тимри картны кыйнаган.

Рушан. Әйдә, туташ, су буена китик; ул бик ярсыган.

Хәмдия. Ул рәхәтләнеп котырсын дип китимме? Ходаем, нинди кыйланыш бу! Бичара көтүчене үтерә бит.

Тавыш. Лав, лав, лав, лав... *(Әллә нәрсәләр дөберди.)*

Хәмдия. Көтүчене үтерер бу. Качырыйк аны, Рушан, качырыйк. Качып китсен ул.

Рушан. Аннан үзеңә кыен булыр, туташ.

Хәмдия. Булса булыр. Мин аны айыйм. Минем аны кыйнатасым килми. Рушан, йөгер! Юлына каршы чык!..

Рушан. Кереп килә.

Хәмдия. Чыгыгыз! *(Тиз чыгалар.)*

Тавыш *(бакыра)*. Китер аны монда! Китерегез монда...

Каршыдан бүртенгән, йодрыкларын төйгән хәлдә лап-лоп басып, Сәлим мирза керә. Ян ишектән Җиһан каршы килә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Җиһан.

Җиһан. Юньсез нәрсә; керүенә алты ай булмаган, бер куйның аягын сугып сындырып та өлгерде.

Сәлим *(йодрыгы белән өстәлгә суга)*. У-у-у-у!

Җиһан. Ни кыйланасың, әйберләрне төшерәсең бит...

Сәлим. Син дә миңа каршы киләсеңме? *(Көзге алдында торган чәчәкле вазаны алып идәнгә бәрә.)*

Җиһан *(омтылып кала)*. Кытай савытымны...

Сәлим. Кытай савытымнымы? Менә, менә, менә! *(Аягы белән таптый.)*

Җиһан *(ачуланып)*. Башка нәрсәләргә кагыла күрмә. Барысы да җандай кадерле нәрсәләр. *(Үзе пыяла шкаф белән Сәлим арасына керә.)*

Сәлим. Кадерлеме? *(Җиһанны этеп җибәреп йодрыгы белән пыялага суга, пыяла чалтырап коела.)*

Сәлим *(урындыкны атып бәрә)*. Мә!

Җиһан *(барып)*. Атакайлары, кара әле, бер генә сүз сорыйм. *(Кулына ябыша.)* Гыйлаҗи беркөн сәнәк сабын сындырган бит. Бүген шуны сылтау белән...

Сәлим *(Җиһанның кулын кагып җибәрә)*. Кыйнадым инде.

Җиһан. Исмәгыйльне?

Сәлим. Кыйнадым. *(Утыра.)*

Җиһан. Тимри картны?

Сәлим. Кыйнадым.

Җиһан. Хәсән каравылчы да бар...

Сәлим. Кыйнадым.

Җиһан. Бик яхшы иткәнсең. Хисамга да кирәк иде.

Сәлим. Кыйнадым.

Җиһан. Бик яхшы булган, һаман туры килеп тормый. Урыны чыкканда өйрәтеп калырга кирәк... Фәтхетдине калгандыр әле?

Сәлим. Кыйнадым.

Җиһан. Галине?

Сәлим *(тора, сузып).* Юк...

Җиһан. Нәрсәләргә кагыла күрмә берүк... йә...

Сәлим *(өстәлне этеп җибәрә).* Кагылам! Мә!.. Мә!.. Мә!..

Җиһан. Бәр, бәр! Илаһи, барын да бәр! Менә боларын да бәр! Боларын да бәр!

Сәлим. Бәрмим! *(Утыра.)*

Җиһан. Бәрмәсәң бик яхшы...

Сәлим. Бәрәм. *(Нәрсәләрне ыргыта башлый.)* Мә!.. Мә!..

Җиһан *(ишеккә барып кычкыра).* Гали! Гали!.. Йөзе карасы, юри качып йөри. Усаллыгыннан качып йөри... Гали! Гали!..

Кечкенә малай Гали бик куркынып кына керә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Җиһан, Гали.

Җиһан. Кайда йөрисең, азгын малай? Сезнең аркагызда нәрсәләрем харап булып бетте. *(Кулыннан сөйрәп, Сәлимгә илтә.)* Менә бер явызы. Кичә су керткәндә сөртенеп бер чиләкне яньчә язды.

Сәлим. Бас шунда. Кузгаласы булма! *(Каршыда бастырып куеп чикәли башлый. Бала елый. Акырып.)* Елама! Тавышыңны тансык дип беләсеңме?!

Йөгереп Бакый керә. Ян ишектән Хәмдиянең башы күренә.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Җиһан, Гали, Бакый, Хәмдия.

Хәмдия *(ишектән башын тыгып Бакыйга кул селти).* Кермә!

Бакый *(Хәмдиягә карап аптырабрак кала да, ул югалу белән, алга атлый).* Минем өчен гөнаһсыз баланы кыйнама, мирза! *(Галине Сәлимнең кулыннан гайрәт белән тартып ала; үзе Сәлимнең алдына баса. Гали йөгереп чыга.)*

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Бакый.

Сәлим. Син сындырдыңмы куемның аягын?

Бакый. Мин сындырмасам да, сынуына сәбәп булдым. Шунлыктан...

Сәлим. Син сындырдыңмы куемның аягын?

Бакый. Мин сындырдым.

Сәлим *(җиңен сызганып).* Сәлим мирзаның каһәреннән курыкмый әйтәсеңме аны? Син кем, потомственный почетный дворянин Сәлим мирза алдында сөйләшергә батырчылык итүче?

Бакый. Мин — көтүче.

Сәлим. Сәлим мирза алдында моңарчы бер көтүче дә авыз ача алганы юк. Гафу үтен, әдәпсез! Гафу үтенсәң — кыйналасың гына; гафу үтенмәсәң — үтерәм!

Бакый. Аяк-кулым бәйләнеп алынмаган булса, сиңа да Бакый каршында тетрәп торыр көннәр килер иде.

Сәлим *(сикереп тора).* Үтерәм!.. Син миңа нинди акыллар өйрәтәсең?! *(Урындыкны күтәреп сукканда гына кинәт, ишек ачылып, Хәмдия кереп арага баса.)*

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Бакый, Хәмдия.

Хәмдия *(урындыкка ябышып).* Атакай!

Сәлим *(чигенеп).* Кит!

Хәмдия. Сук миңа!

Сәлим *(чигенә).* Ә-ә?

Хәмдия. Аның өчен миңа сук!

Сәлим *(аптырап карап тора).* Хәмдия! *(Урындык кулыннан төшә.)* Йөземне каралттың, кыз. *(Диванга ава, бакыра, кычкыра.)* Күземнән югал, эт баласы!

Бакый Хәмдиянең ишарәсе белән чыга. Каршы ишектән Шаһтимер килеп керә.

УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Хәмдия, Шаһтимер.

Шаһтимер. Данлы кыз шундый хөрмәтсезлекләр күрәме? *(Сәлимгә.)* Чигел! Ата тарафыннан куылган кызның аяк астында туфрак булырга хәзер йөрәкләр барын онытма!

Сәлим. Көтүче түгелме?

Хәмдия. Хәмдиянең илнең нәфис егетләрен бер көтүче белән алмаштырырлык тиле түгел.

Сәлим *(йөзе яктыра).* Шаһтимер беләнме әллә?

Хәмдия. Хәмдиянең ак егетләр эчендә иң асылы булган бер яры бар инде. Каршында ул торганда, бүтәннәр күләгәдә.

Шаһтимер *(яктырып китә).* Каршында торганда?

Хәмдия. Каршында тора.

Сәлим. Шулаймы? *(Икесенә дә карый.)* Эһем, эһем... *(Йөреп китә. Йөзендә җиңү галәмәтләре.)*

Хәмдия. Ул Хәмдиясенең йөрәгенә ия булды. Тик яры көткән серле бүләкне бирә алганга кадәр якын килә алмас. Бәйгене бүтәннәрдән алдырса, Хәмдиясенә үпкәләмәс. Егет булса, нинди бүләк икәнен йөрәге белән сизсен; йөрәге аша үткәреп бирсен! *(Ян ишеккә китә.)*

Шаһтимер. Серне чишеп, сөеклесенең теләген тутыру юлында ул корбан булсын! *(Каршы ишеккә китә. Икесе бер вакытта чыгалар.)*

Җиһан керә.

УНДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Җиһан.

Сәлим. Син кайда булдың?

Җиһан. Кайда булыйм, давылда кыйралган нәрсәләрне барладым. Ике тавыкның аягы сынган, өч чеби үлгән, ике казның канаты каерылган, тәрәзәләр ватылган, чиләкләр яньчелгән, утыннар җимерелгән, сулар түгелгән, арбалар ауган, кисмәкләр тәгәрәгән...

Сәлим. Давыл көчле булган икән.

Җиһан. Инде давыл басылган шикелле.

Сәлим *(өстәлгә суга).* Тукта!.. Бар, көтүчене монда чакырт!

Җиһан. Әле давыл басылмаган, күрәсең. *(Китә.)*

Бакый керә.

УНАЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Бакый.

Бакый *(каушамый килә)*. Мин килдем.

Сәлим. Бакый!.. Куемның аягын син сындырдыңмы?

Бакый. Мин сындырдым.

Сәлим *(акча алып бирә)*. Мә! *(Кычкыра.)* Ал! Гафу ит мине! Бар, кит.

Бакый. Киттем. *(Чыга башлый.)*

Сәлим *(кычкыра)*. Бакый!

Бакый *(борыла)*. Килдем.

Сәлим. Ялгыш әйттем: сине гафу итәм, сине гафу итәм. Бар, кит!

Бакый *(читкә)*. Син җәһәннәмгә кит! *(Акчаны мирзаның аяк очына бәрә.)*

Сәлим *(сизми кала)*. Перес! *(Аягын тибә. Бакый китә. Кычкыра.)* Анакайлары!

Җиһан керә.

УНҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җиһан. Хәерлегә булсын, ничек тавышсыз үтте.

Сәлим. Анакайлары, кил якын! *(Үзе тора.)* Хантимер мирза баласы Шаһтимерне беләсеңме?

Җиһан. Атасының нәселен чертергә туган, дидер идең үзең. Кем икәне билгеле инде, мирза балалары төсле.

Сәлим *(урындыкны атып бәрә)*. Мә! Каршы сөйләмә миңа!

Җиһан. Ни эшләп каршы сөйлим, син яратмаган кешене яманлыйм бит.

Сәлим. Шаһтимер ничек?

Җиһан *(ни дияргә белми тора)*. Син әйткәнчә.

Сәлим. Ничек?

Җиһан. Үзе утырган ботакка балта чабучы юләр, дисең бит үзең.

Сәлим *(өстәлне аудара)*. Мә!

Пәрдә төшә.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәлим мирза өенең пыяла ишекле балконы чыккан матур бакча. Бай җиһаз, гөлләр; кошлар тавышы. Кич, ай яктысы, Хәмдия бер креслога утырган. Калфактан. Аягында яшел башмак. Тирәсендә Рушан, Гафия, Гөләндәм вә башкалар белән «йөзек салыш» уйныйлар. Гөләндәм, йөзекне куш учына куеп, башкаларның кулына салып йөри.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәмдия, Рушан, Гафия, Гөләндәм, кызлар.

Гөләндәм *(һәммә кызларга йөреп бетеп)*. Йөзек кемдә, йөгереп чык!

Гафия. Бер җырламый чыкмыймын.

Гөләндәм. Җырлап чык, туташны зурлап чык.

Гафия. Нинди көйне телисең, туташ?

Хәмдия. Ах, Тәфтиләүләр, Ашказарлар, Мәдинәкәйләр кебек минем дә үз көем булса!.. Менә шул көйгә җырла, дияр идем мин. Ах, минем үз көем булса!

Рушан. Ил егетләрен җил күтәрсен! Тирәгә дан булган мирза кызларына бер күңел бүләге дә бирә алмыйлар.

Гөләндәм. Туташлары теләгән бүләкне бирә алмаган егетләрнең йөрәген таракан ашасын. *(Көләләр.)* Егетләрнең берсе үз атыңа көй чыгарып җырласа, аны ни белән куандырыр идең?

Хәмдия. Ул минем киявем булыр иде.

Рушан. Ах, ул егетнең бәхетен көнлим!

Гөләндәм. Кызганыч егетләр, бәхетләренә нинди юл белән җитәргә икәнен белмиләр.

Хәмдия. Ах, никадәр телим үз атыма бер көй булуын. Үземә билгеләнгән көй белән исемемне халык телләрендә тибрәттерә алса, ул егет минем гомерлек юлдашым булыр. Буз юргасын юргалатып килсен дә теләсә дөньяның читенә китсен. Шул бүләге өчен барысына да риза. Ай, мин уйга чумып уенны бүлдем. Җырла, Гафиякәй. Теләгән көеңә, теләгән җырыңны җырла.

Гафия җырлый.

Хәмдия. Рәхмәт, дуслар, рәхмәт! Дусларым, уен бетсен! Таң да якындыр инде. Барыгыз, ятыгыз. Рушан, син минем белән кал. Мин, таң җиле белән сөелеп, тын гына былбыл моңнарын тыңлап утырырга телим.

Кызлар. Фәрештә юлдашың булсын! *(Китәләр.)*

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәмдия, Рушан.

Рушан. Туташ, син Хантимер мирзаның улы Шаһтимерне сөясең бит?

Хәмдия. Сөям мин аны, Рушан. Ләкин иң көчле теләгем булган исемемә аталган көй юлында мәхәббәтем корбан булсын!

Рушан. Бу куркыныч, туташ.

Хәмдия. Кайгырма, Рушан, Шаһтимер йөрәгеннән башка бер йөрәк тә бу бүләкне бирә алмас.

Рушан. Бу теләгеңне ул белсә ярый.

Хәмдия. Көтүче апа биргән хатымда мин аны ачык әйттем. Миңа бирәчәк бүләгең үземә аталган бер көй, дидем. Өченче көн сөйләшкән чакта да шуны аңлаттым. Ул вәгъдә бирде. Теләгеңне тутыру юлында корбан булыйм, диде.

Сандугач сайрый.

Чү!.. *(Тын калалар. Хәмдия торып йөреп килә.)* Рушан, минем йөрәгемдә ниндидер бер уңайсызлык бар. Йөрәгемдә бер авырту сизәм.

Сандугач сайрый.

Хәмдия *(кинәт)*. Чү!..

Рушан *(туктый)*. Нәрсә бар?

Хәмдия. Мин хыялланам, ахры. Бу дәрт мине саташтыра. Хәмдия дип читтә берәү җырлаган кебек булып китте.

Тынып торалар. Еректан сызылып кына җырлаган тавыш килә. Җыры аңлашылмый.

Ах, хыял түгел. Әллә бәхет кошым сайрыймы, Ходаем?..

Тыңлап торалар. Төнге тын һаваны ярып тибрәнеп кенә килгән саф тавыш һаман якынлый; җыр аңлашыла башлый.

Хәмдиянең ак калфагы...

Хәмдия. Ах! *(Урыныннан тора.)*

Яңа каралган чагы;
Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы...

Хәмдия. Бәхетем!.. Рушан, ишетәсеңме? Мин саташмыйммы?

Рушан. Туташ, сөйгәнең синең өчен җырлый, сөен!

Җыр дәвам итә; Хәмдия әсәрләнеп тыңлый.

Агыйдел алкын, суы салкын,
Барма якын, дулкын какмасын.
Хәмдиянең ак калфагы
Яңа каралган чагы;
Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы.
Бер битең айдай, берсе кояш,
Яман күздән Аллам сакласын!
Хәмдиянең ак калфагы
Яңа каралган чагы;
Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы.

Хәмдия. Үз көем! Хәмдия көе! Минем исемемә көй чыгарган рәхмәтле бәндә кем бу? Рушан, кем бу?

Рушан. Егетләрнең солтаны, кызлар күңеленең иркәсе, Хәмдиянең яры — Шаһтимер.

Хәмдия. Ах!.. Ах!.. *(Рушан килеп тота.)* Сәлам һәм мәхәббәт сиңа, нечкә уйлы ил баласы! Ал, гашыйк бәндә, минем саф күңелемне!.. Ник тынды? Ник минем күңелемне җилкетеп кенә югалды? Рушан, әйдә шунда таба. Әйдә шунда! Табыйк аны! Юатыйк шул гашыйкны...

Җыр.

Тәрәзәләрдән, ай, караган,
Түшләренә мәрҗән кадаган.
Хәмдиянең ак калфагы
Яңа каралган чагы;
Хәмдиягә сүз кушмагыз,
Зиһене таралган чагы.

Яр гынай булып яралмаган,
Җаннар көйдерер өчен яралган.
Хәмдиянең ак калфагы
Яңа каралган чагы;
Хәмдиягә үпкәләмим,
Зиһене таралган чагы.

Хәмдия. Рушан, нинди матур көй! Нинди зур бәхет! Әйдә, ул якын бугай.

Рушан. Шаһтимер булмаса?

Хәмдия. Чынлап та, ул Шаһтимер булмаса?.. Шаһтимерем, син бит бу? Син бит?..

Рушан *(кузгалырга кыймый)*. Туташ, Бакыйны җибәрик. Бакый менә монда рәшәткә янындагы сәкедә генә йоклый бит. Шуны гына уятып җибәрик.*(Читкә карап.)* Әллә кем бар! Мирзадыр, хур булдык. Кем йөри анда?

Тавыш. Мин.

Рушан. Бакый бит... Бакый, синме?

Тавыш. Мин.

Хәмдия. Чакыр!

Рушан. Бире кил! *(Хәмдиягә.)* Безнең тавышны ишетеп торгандыр инде.

Бакый керә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәмдия, Бакый, Рушан.

Хәмдия. Бакый, егет бул, миңа тагы бер хезмәт ит.

Бакый. Баш өсте, туташ.

Хәмдия. Арырак, су буенда кемдер берәү җырлый. Мин шул кешенең кем икәнен белергә телим, син шуны белеп килә алырсың бит?

Бакый. Килермен... Гафу үтенәм, туташ, сине азрак алдадым. Мин ул җырны ишетеп уяндым да җырлаучының янына бардым.

Хәмдия *(ашкына)*. Алайса, син аны беләсең?

Бакый. Мин аның сәламен ирештерергә илче ителдем... Мин сиңа килдем, туташ.

Хәмдия *(сабырсызланып)*. Алайса, ул Шаһтимер?

Бакый. Аның сүзләрен ирештергәндә, син ялгыз булырга тиешле.

Хәмдия. Рушан, кер!

Рушан. Баш өсте. *(Китә.)*

ДҮРТЕНЧЕ—ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШЛӘР

Хәмдия, Бакый.

Хәмдия. Шартың үтәлде. Берсен дә калдырмый сөйлә. Аны күрдеңме? Шаһтимер түгелме әллә? Әллә башка берәүме?

Бакый. Менә ул. *(Каршына тезләнә.)* Менә ул синең колың!

Хәмдия *(аптырап калып).* Юләр малай... Ни эшлисең син?..

Бакый. Сөям! Туташ, кызган мине! Моңлы баланың дәртенә дәва бул!

Хәмдия *(бераз аңлашмый торып).* Бакый!.. Җитәр! Ничек син болай тәрбиясезләнәсең? Тилердеңме әллә?

Бакый. Сөям, туташ! Өч көн эчендә күкрәгемә төен булып өлгергән серләремне бүген ишет. Алмаз кашлы алтын йөзегеңә түгел, үзеңә гашыйк булган колың яңа гына биргән вәгъдәңнең йолдыз булып ялтыравын көтә.

Хәмдия *(буылып).* Әдәпсез! Югал моннан! Син шундый хыянәткә керештеңме? Минем көй чыгаручыга биргән вәгъдәмне үз файдаңа бормакчы буласыңмы? Беләсеңме, мин ни эшләтермен моның өчен... Тор! Көтүче башың белән шундый нәфис көйләр тудыра алуыңа ышанырлар дип уйладыңмы? Күземә күренмә, кит!

Бакый. Мин көтүче генә түгел, сукачы да... Яшерен янып, көл булырга уйладым; вәгъдәңә таянып, серемне ачтым. Саф мәхәббәтемне хыянәт исеме белән пычратма, туташ!

Хәмдия. Кирәкми, кирәкми, сөйләнмә! Мин бу хурлыкка түзә алмыйм. Түзә алмыйм... Ах, югал, югал!

Бакый *(каршына бара).* Мәрхәмәт!

Хәмдия. Төрмә сиңа, зиндан!

Бакый *(тора).* Вәгъдәң буенча бүләгең шулмы? Вәгъдәләреңнән өметләнеп серен ачкан баланың алдануы шушымы?

Хәмдия. Ялган! Ялган!

Бакый. Ышан! *(Тезләнә, җырлый башлый.)*

Шылтыраплай аккан елгаларда...
Кулъяулыкларымны юдым мин.
Хәмдиянең...

Хәмдия. Ул!

Бакый. Ак калфагы
Яңа каралган чагы...
Хәмдиягә үпкәләмим,
Зиһене таралган чагы.

Хәмдия. Ах, хур булдым. Кирәкми! Кирәкми!..

Бакый. Сөйсәң дә, иркәм, сөймәсәң дә...
Синең өчен генә әй тудым мин.

Хәмдия. Бакый, тукта! Хур итмә!.. Бакый, хур итмә! Түзә алмыйм...

Бакый. Хәмдиянең ак калфагы...
Төшеп тора күзенә...

Хәмдия. Беттем!

Бакый. Көтүченең мәхәббәтен...
Хурлык саный үзенә.

Хәмдия. Ах! *(Җиргә егыла.)*

Бакый *(тора. Аның янына акрын бара; тезләнеп)*. Туташ!.. Хәмдиям!.. Үлдеңме, җаным! Көтүче мәхәббәтенең хурлыгын йөкли алмый үлдеңме, Хәмдиям?.. *(Карый.)* Хуш, йөрәгемне ялкыннарга чорнаган бәхетсез яр! Мәңгегә хуш! Минем өчен син барыбер юк идең. Тере көе юк булганчы үлеп юк бул. *(Маңгаен үбә, башын җирдән күтәреп кочагына ала. Кулын күтәреп, йортларга карап.)* Безнең кавышуыбызга киртә булган бу тормышка мин тагы да көчлерәк дошман хәзер. Мин шул ояны туздыручы каһарман булып юаныч табармын. Мин күз яшенә манчылган бу йортларны җимерермен. Хәмдиям, хуш, җаным! Мин хәзердән изге юлга керәм. *(Йөзенә карап җырлый.)*

Шаһтимер килеп керә.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Хәмдия, Шаһтимер.

Шаһтимер *(шашынып керә)*. Каян килә бу тавыш? Кем җырлый?.. *(Хәмдияне кочаклап җырлап утырган Бакыйны күреп тилерә.)* А-а-аһ!.. Алар бергә!..

Бакый җырның азагын әйткәндә генә, Шаһтимер, хәнҗәрен чыгарып, Бакыйга чәнчә. Бакый Хәмдияне кочкан көе авып төшә. Шаһтимер куркып чигенә, аңга килә. Бакыйның үлгәнен белеп шаша. Чигенә-чигенә барып сәхнәдән чыга.

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бакый, Хәмдия.

Хәмдия *(берәр минуттан хәрәкәткә килә. Күзен ача, айнып күтәрелә. Үзен Бакыйның кочагында күреп аптырый)*. Бакый!.. Ах, мәлгунь!.. Җибәр! *(Кочагыннан ычкынып күтәрелә. Бакый хәрәкәтсез җиргә төшә.)* Бакый, син ни эшләдең? Бакый!.. Бакый!.. Ярабби, ни булган аңа? *(Иелеп.)* Йа Алла,

үлгәнме әллә? *(Карый. Кычкыра.)* Үлгән! *(Ачы кычкырып өстенә ташлана.)* Бакый!.. *(Кочаклап елый башлый.)*

Рушан йөгереп чыга.

УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бакый, Хәмдия, Рушан.

Рушан. Туташ!.. Ай, ни булды?

Хәмдия *(елый).* Бакый, Бакый! Уян, җаным, уян!..

Хәмдия. Җаным бул, Бакый, уян, уян! Мин синеке! Уян, ал хакыңны!.. *(Кычкырып.)* Ул үлде. Үлде. Мине калдырып үлде. Җаным, ал мине дә яныңа! Ал, иркәм, Хәмдияңне.

Рушан. Ни эшлисең, туташ? Акылдан язасыңмы әллә?

Хәмдия *(кычкыра).* Син минеке, син минеке! Мин риза, Бакый! *(Елый. Сикереп тора. Юләрләнгән кебек кычкырып.)* Хәмдиянең ак калфагы, җаным, ямьле йөзеңә пәрдә булсын! *(Калфагын алып, Бакыйның йөзенә каплый.)* Ярың Хәмдиянең күңеле кабереңә белән янәшә торсын! *(Югары карап.)* Кошлар, фәрештәләр, шаһит булыгыз. Хәмдия кәтүче гыйшкыгын кабул итә. *(Елап Бакыйга ташлана.)*

Рушан. Туташ!.. Харап булдык, ни эшли бу? Үләме? *(Кычкырып өйгә таба йөгерә.)* Килегез, килегез, туташ үлә, туташ харап була!.. *(Әчкә керә.)*

Шунда ук Сәлим, Җиһан, Гафиләр чыгалар. Соңыннан берәм-берәм башкалар да җыела.

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Хәмдия, Рушан, Сәлим, Җиһан, Гафия, башкалар. Килүчеләрдә каушау, аптырау. Күргән уңае куркалар.

Сәлим. Бу ни эш, кызыкай? Бусы тагы нинди мәсхәрәлек? Кәтүче бу. Минем кызыммы аның гәүдәсе янында? Күземә шулай күренәме әллә?

Җиһан. Бу нинди хурлык? Тор, балакай!

Хәмдия. Ул үлде!

Сәлим. Үлсә, кәтүче бетмәс. Ул түгел, куйның аягы да сынды бит әле... Тор!

Хәмдия *(кычкыра).* Бакый минеке! *(Битен ачып күрсәтә.)* Әнә аның йөзендәге серле нурны мин хәзер ачык күрәм...

Сэлим. Сиңа бер генә сүз — тор! *(Кулына ябыша.)*

Хәмдия *(кулын бәреп җибәрә).* Тотынма миңа! Унҗиде буыннан килгән ак кулың белән кара көтүче ярының кулын тотма. Син мирза булсаң, мин инде мирза кызы түгел.

Сәлим *(Хәмдияне Бакый өстеннән йолкып ала).* Синме атаңа каршы кул күтәргән бала? *(Ике кулы белән башын кыса, бөтенләй шашына.)* Билемне сындырды. Дөньямны екты. Ах, ах, ах... Китегез, китегез, кырам барысын да! *(Юл өстендә торган Рушанны сугып очыра. Башкалар кача.)* Җимерәм дөньясын! *(Өйгә таба китә.)* Ах, ух, бетәм... Ут төртәм!.. *(Бәреп-җимереп өйгә керә. Һаман тавышлый, кырып-ватып йөргәне ишетелә.)*

Җиһан *(бер Сәлимгә йөгерә, бер Хәмдиягә килә).* Атакайлары!.. Хәмдия!.. Аһ, ни эшлисез?.. Атакайлары!.. Кызым, кызым!.. Аһ, аһ!.. *(Һуштан язып, егыла. Кызлар аның янына йөгерәләр.)*

УНИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлимнән башкалар.

Хәмдия *(Бакый белән хыялланып сөйләшә).* Тукта, чыбыркың кайда соң синең? Куйның аягын сындыручыны куып җибәр тизрәк! Хәзер, хәзер китерәм чыбыркыңны. Хәзер китерәм, җаным. Аз гына көт... Кара, чәчләрең нигә бөдрәләнгән синең? Бөдрә гөлләр кебек булган. Мин бу бөдрә чәчләреңне көмеш бизәкле ак тарагым белән тарармын да ефәкләр куеп матурлармын.

Кызлар Җиһанны күтәреп алып китәләр.

Җаным, мин сине бик сөям бит. Без гел, гел бергә бит? *(Җырлый.)*

Алмагачларның алмасын
Ала алмассың, бәгърем, үрелмә;
Хәмдиянең ак калфагы
Чигелмәгән үрнәккә;
Хәмдиянең моңлы көе
Калсын илгә гыйбрәткә!

Шаһтимер керә.

УНӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бакый, Хәмдия, Шаһтимер, соңрак кызлар.

Шаһтимер *(баягы формада килеп керә. Хәмдиягә барып).* Аны мин үтердем.

Хәмдия *(сикереп тора).* Син?

Шаһтимер. Мин чәнечтем.

Хәмдия *(килеп йөзенә төкерә).* Тфү! *(Елап Бакыйның өстенә ташлана.)*

Пәрдә төшә.

1922 ел

Биремнәр һәм сорау

1. Башта тышкы конфликтны табыйк. Моның өчен драмадагы төп геройларны ачыклагыз. Әсәрдәге тышкы конфликт, гадәттә, алар арасында була.
2. Тышкы конфликтның сәбәбен әйтегез.
3. Әсәрдәге эчке конфликтны табыгыз. Эчке конфликт Хәмдиядәме, Бакыйдамы?

ПОВЕСТЬЛАР

Повесть әдәбиятның чәчмә әсәрләр төренә керә. Күләме ягыннан хикәядән зур, романнан кечкенә.

Повесть жанрына хикәя сыйфатларының барысы да хас. Хикәядән ул сюжет эчендәге вакыйгаларның һәм персонажларының күплеге белән генә аерыла. Гадәттә, анда ике сюжет сызыгы була. Повестьларның тагын бер үзенчәлеге шунда: анда автор шактый актив катнаша.

Искә төшерик:

Бер-берсе белән әледән-әле кисешүче ике яки өч сюжет агышын **сюжет сызыклары** диләр.

ПОВЕСТЬНЫҢ АВТОРЫ ТУРЫНДА

Мирсәй Әмирнең йөзенә карап: бу кеше балачакта ук ятим калып, бик интегеп үскән димәссең. Аның йөзендә һәрвакыт шәфкатьлелек, сабырлык нуры балкыды. Елмаеп торучы күзләре аның һәрвакыт кемгә дә булса ярдәм итәргә әзер торуы турында сөйлиләр иде. Мирсәй Әмир матбугатта

басылып чыккан һәр әсәр белән танышып барды. Берәр әсәр ошаса, үзенең сөенечен ничек кенә булса да авторына җиткерергә тырышты. Ничәмә-ничә яшь автор хөрмәтле аксакалның җылы сүзен ишетеп рухланды, язучы булып китте.

Мирсәй Әмир туган авылы Җиргән турында күп язды. Башкортстандагы бу кечкенә авылның табигате һәм кешеләре әдипнең күп санлы әсәрләре эченә керделәр. Әдип хәтта «Агыйдел» повестенда да үз авылының табигатен һәм кешеләрен искиткеч матур итеп тасвирлый. Ләкин шул гүзәллек эчендә үзенең булуын сиздереп тә куймый. Әдип әсәрләрендә үз хисләре, уйлары турында язды, әмма «үземнеке» дип әйтмәде. Ә менә сез аның «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре», «Балыкчы ялганнары», «Безнең авыл кешесе» повестьларын, «Миңлекамал», «Тормыш җыры», «Җыр дәвам итә» исемле драмаларын, «Саф күңел» исемле романын укып карагыз. Аларның эчтәлегендә авторның чиксез шәфкатьлелеге, тыйнаклыгы, зирәк акылы һәм җылы юморы ятканлыгын күрерсез.

Әдип 1907 елда туып, 1980 елда дөнья куйды. Шул гомере эчендә ул әллә ничә газета-журнал редакцияләрендә эшләде. Татарстан Язучылары берлегенең рәисе итеп сайланды. Югары Совет депутаты иде. Әмма нинди генә эштә булмасын, нинди генә дәрәҗәле урын биләмәсен, барыбер ачык йөзле, шәфкатьле, тыйнак, һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торучы гап-гади Мирсәй Әмир булып калды.

Мирсәй Әмир

Агыйдел

I

Иртәнге кояшның йомшак нурларына иркәләнеп, көлеп уяндым, һичкем кыңгырау шалтыратмады, өстемә ябынган чикмәнемне һичкем килеп тартмады, фәкать куксел урман белән капланган кәчле таулар артыннан көлеп күтәрелгән иртәнге кояш нурларының йомшак кына итеп битемнән сыйпавы җитте — уяндым.

Шундый бәхетле, шатлыклы, җиңел уяну иде бу!

Без йоклаган арба төбендәге кичә генә чабып кайтарылган печән исе дә мине исертә. Шул исле чәчәкләр арасына кысылган әрем исе дә кыйммәтле хушбуйлар исеннән тәмлерәк

булып тоела. Хәтта читән буйларына сырышып үскән алабуталар да, кычытканнар да Шишкин пейзажларыннан матуррак булып күренәләр.

«Әйе, дөнья матур, чиксез матур!..» Шулай дип, үзалдыма үзем кычкырып җибәрә яздым. Күңелле минутны якын иптәшем белән уртаклашасым килде. Ә иптәшем уянмаган әле.

Аның өстендә дә, минеке кебек үк, җиңсез челтәр күлмәк, арзанлы материядән тегелгән кара чалбар. Таза мускуллы ялангач беләкләре ике якка ташланган, тыгыз күкрәк итләре белән нығытылган авыр гәүдәсе чи печәнгә чумган. Куе яшел печән белән кушылып киткән кара бөдрәләре астыннан күренгән ап-ак киң маңгае аны әкиятләрдә сөйләнә торган гүзәлләргә охшата. Тигез булып сызылган коңгырт-кара кашлар, көлеп чыккан кояш нурлары кебек, түбәнгә таба атылган озын керфекләр аны тагын да матуррак итеп күрсәтәләр. Чынлап та, аның йөзендә ниндидер нур балкый кебек иде ул минутта. Мин, аның матурлыгына, җанлылыгына, ягымлылыгына сокланып, шактый вакыт сүзсез генә карап тордым. Мин аны яратам. Техникумда укый башлаганыма менә быел — 1927 елның көзендә — ике ел тула. Шул ике ел эчендә без, аның белән икебез, бер кеше төсле яшәдек. Безне ялгыз очрату кыен булгандыр. Шуңа күрә дә җәйге ял чорында өч ай буенча аерылышып тору беребезнең дә башына сыя алмады. Бергәләшеп Агыйдел буена — минем туган авылыма кайттык.

Сабырлыгым җитмәде, шундый күңелле, матур минутларда аның йоклап ятуын әрәм санадым да уяттым:

— Гаяз!.. Гаяз!..

Аның күзләре ачылды. Әйтерсең лә ул кара күзләр юри генә йомылып торганнар: шундый мәшәкатьсез, шундый чиста булып ачылдылар алар, минем өчен, чыннан да, икенче кояш чыккан кебек булды.

— Нигә бик иртә? Барасы җир юк бит,— диде ул.

— Бар, Гаяз, барасы җир бар. Әйдә, мин сине хәзер Агыйдел буена алып барам, су коенырга.

Ул кинәт машина тизлеге белән сикереп торды.

— Әйдә, киттек.

Сирәк-сирәк кенә утырган салам түбәле өйләрне үтеп, Агыйделгә алып төшә торган кечкенә тыкрыкка борылуга, миңа бала чагымнан ук таныш булган Тешсез Ибрай очрады. Ул тыкрыкны аның исеме белән атап, Тешсез Ибрай тыкрыгы

дип йөртәләр. Чөнки аның өе нәкъ чатта утыра. Ишегалдына ялганып, артка таба киткән яшелчә бакчасы да шул ук тыкрык буйлап сузыла. Ул һаман да шул ук бакчасында, түтәлләр арасында казына иде. Читән аша исәнләштем:

— Ибрай абзый, исәнме?

Ул кинәт гәүдәсен турайтты, балчыкка буялган кулларын киндер алъяпкычына сөртә-сөртә, безнең янга ашыга башлады.

— Синме бу, Ильяс, танырлык та түгел бит егет, ә?

Иптәшем белән дә таныштырдым. Гаязның шәһәр егете — завод егете икәнен белгәч, Ибрай тагын да шатлана төште:

— Ә, рабочий егетме,— диде ул,— бик күп сүзләр сөйлисем, бик күп сораулар бирәсем бар әле минем сезгә...

— Сөйләшербез, сөйләшербез,— диде Гаяз, гадәттәгечә тыныч та, ягымлы да, җитди дә булып ишетелде аның җавабы. Агыйделгә төштек.

II

Агыйдел!

Рәсемдәге төсле матур, әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы елга ул Агыйдел... Җырларда аны, күбесенчә, яшь гомергә охшаталар. Чынлап та, бик урынлы охшату. Кыска гына ара эчендә дә чиксез күп борылышлар ясый, агымын әледән-әле үзгәртеп тора: бер карыйсың — яшәү көче белән ярсыган яшь йөрәкне хәтерләтә, ташып барган көчен кая куярга белми аптыраган егетләр шикелле, ташларны актарып, уң яклап күтәрелгән текә тауларның каты ярларын кисеп, баштүбән ага. Ул арада булмый, ай яктысына чыгып утырган яшь кызлар төсле, уйга батып китә; ике як ярларында үскән куаклардан асылып төшкән күләгә эчендә бөтенләй агуын онытып тора. Хәтта чит-читләрендә төнбоеклар үсүгә дә каршы килми. Аның мондый урыннарын үрдәк-каз кебек кошлар бик яраталар, ләкин тормышлары өчен куркыныч барлыгын белмиләр алар: күл кебек тыныч, төнбоеклы суга булган мәхәббәтләренә каршы килә алмыйча йөзеп китәләр дә чоңгылда яткан усал җәен авызына барып кергәннәрен дә сизми калалар... Ә Агыйдел аларны күрмәмешкә салыша, бөтенләй дөньясын оныткан төсле тынып, тик тора... Күп тә үтми, тагын бик кирәкле эшен исенә төшергән кеше сыман, яңа тауларга таба борылып ашыга башлый.

Ташларга бәрелүдән туган кечкенә-кечкенә дулкыннар күп булып җыелышалар да, кызык күрергә ашыккан төркемдәй, берсен берсе төртешә-төртешә, узара ярләшә-ярләшә алга йөгерәләр. Шулай бер котырып, бер басылып ага ул. Барган юлында очраган кечкенә-кечкенә елгаларны үзенә ияртеп, зурая бара, зурайган саен «акылга утыра». Шулар белән бергә Кама, Идел кебек абзыйларына кушылып, Каспий диңгезенә чыга — киң тормыш эченә керә.

Без төшкән тәңгәлдә[1] Агыйдел каты акмый: өзлексез акрын гына күчеп торган киң, шома көмешкә охшый аның ул җире. Аргы як ярында үскән бөдрә таллардан асылган күләгәләр аның иртәнге серен тагын да арттыралар. Тугайлыкны каплаган куе яшеллек эчендә санап бетергесез төрдәге кошлар бергә кушылып сайрыйлар. Тойгылар үткенләшә, күңел үзеннән-үзе романтикага бирелә. Җитди әйберләр турында уйлыйсы да, сөйлисе дә килми. Уйныйсы, шаярасы, җырлыйсы, сөясе, сөеләсе килә, кәефнең әйбәт булуы белән масаясы килә, җырлап җибәргәнеңне сизми дә каласың.

Без дә Гаяз белән, сүз берләшкән кебек, бер үк җырны беравыздан сузып җибәрдек:

Ямьле Агыйдел буйлары...
Бетерәдер хәсрәтле уйларны...

Агыйдел өстенең пыяла тигезлеге челпәрәмә килде. Аргы як ярдагы бөдрә талларга карап, колач сала башладык. Мәшәкатьсез генә йөзә-йөзә, икенче як ярга шактый якынлашкан идек инде. Гаяз кинәт кенә талларга күмелгән ярга таба йөзе белән әйләнде.

— Тукта! — дип пышылдады ул миңа.— Кара, кем бу? Нинди сын бу?

Каршыбызда, акыл ирешә алмаслык сер булып, бер кыз басып тора иде. Матурлык, чиксез матурлык...

Бөтен җире тигез килгән алсу-көрән тәнле бу кызның, үз тәне төсле үк материядән тегелгән су киемнәреннән генә булуына карамастан, безгә шулкадәр якын җирдә, шулкадәр тирән тынычлык белән басып тора алуын күреп каушап калдык.

Кем ул? Башкортстанның шактый караңгы почмакларыннан исәпләнгән тәңгәлендә шундый матурлыкка ия булырлык серле кыз кем ул?

---

[1] Тәңгәлдә — урында.

Бу сорауларга җавап таба алмау тәэсирендә нишләргә белмичә байтак азапланган булыр идек, Гаяздагы кыюлык ярдәмгә килде. Ул кыю, батыр тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Бәхетле иртәгез белән тәбрик итәбез!

— Рәхмәт.

Тал арасына сибелгән сандугачлар музыкасын күмеп, шыңгырдап чыккан көмеш тавыш белән әйтелгән бу җавап безгә шулкадәр якын, шулкадәр ягымлы булып ишетелде, моңа кадәр татып каралмаган яңа, рәхәт тойгы бөтен тәнебезне чолгады.

Кыз беребезгә дә аерым караш бирмәде, җитез хәрәкәтләр белән куе таллар арасына кереп югалды.

Икебез дә, телсез калып, кызның яңадан күренүен көттек. Кыз яңадан күренмәде. Кире кайткан вакытта инде без килгәндәге төсле шаян түгел идек.

— Очратырбыз әле без аны, Гаяз, ә?

— Бәлки...

III

Тешсез Ибрай тыкрыгын борылып, безнең урамга керүгә, чалма-чапан кигән, кечкенә буйлы, ап-ак кәҗә сакаллы бер карт очрады. Мин белгәннән бирле аны Таквә Сәхәү дип йөртәләр.

Сәхәү карт яшь чагында бик тәүфыйксыз кеше булган, имеш. Кәлимулла исемле зур маллы картның төпчек улы булганга күрә, иркә үскән. Егет булып җиткәч, атасының акчасын урлап качып, еллар буенча югалып йөргән. Атасын җәберләп кенә калмаган, яман кешеләргә катнашып, тирә-яктагы бик күпләргә зыян китергән, ди. Атасы дөнья куюга, ике агасын куып чыгарган да төп йортта калган. Мал табу өчен нинди юл уңай килсә, шуннан барырга тайчынмаган. Үзе дә эшләгән, хатыны да эшләгән, тирә-яктагы ярлы-ябагай да аңа хезмәт иткәннәр. Таквә Сәхәү белән исәнләшәсем килде:

— Исәнме, Сәхәү бабай? — дип кычкырдым. Таквә Сәхәү каргана башлады:

— Тәһарәтемне сындырта яздылар, җәһәннәм кисәүләре, тфү!..

IV

Йокыдан торуыбызга ук барлык тойгыларыбызны тоткын иткән Агыйдел буеның матур табигате безгә тагын да тулырак булып күренә иде. Шундый тойгылар кочагында без үзебезне бер бу авылга гына кунакка кайткан итеп түгел, бәлки бөтендөнья йөзенә мәңгегә кунак булып килгән бәхетле кешеләр итеп сизә идек. Тик акыл белән бер тиенлек алышбиреше булмаган ул тойгыларыбызның гомере кыска булды. Табигатьнең чиксез матурлыгына күмелеп утырган тыныч авылның тынычсыз яклары, күңелсез яклары безгә күренергә ашыктылар.

Кич белән, абзыйлар-жиңгиләр утаудан кайтып, умач ашагач, капка төбенә чыгып утырган идек. Безнең янга башлап Тешсез Ибрай килде.

— Җә, ниләр күрдегез, кунаклар? Яшел Елга тамагы үткәч, җәелеп яткан чирәм бар, анда булдыгызмы? Матурлык әнә шунда...

Матур дип күрсәтергә теләгән җирнең, күп еллар буена тик ятканлыктан, төрле чүп үләннәре басып киткән ямьсез җир икәнлеге миңа электән үк мәгълүм иде.

— Юкны сөйлисең лә син Ибрай абзый,— дидем мин,— тапкансың матур җир.

Сүзгә яңа бер кеше катнашты:

— Байыйсы килә Ибрай абзагызның, байыйсы килә...

Өч-дүрт каеш йөгәнне бергә бәйләп аркасына аскан килеш ялкау гына атлап кайтып килүче бер яшь егет әйтте бу сүзне. Өстенә кигән киндер күлмәгенә, мәңге чишелмәстәй итеп киенгән чабаталарына һәм чит-читләре чачакланып беткән киез эшләпәсенә караганда, аның аркасына күтәргән каеш йөгәннәр бәйләме үзенеке түгел икәнлеге сизелерлек иде. Мин аның Күчәрбай исемле башкорт егете икәнен әүвәлдән үк бик яхшы белә идем.

Ибрай аны да җавапсыз калдырмады:

— Әйе шул, Күчәрбай энем,— диде,— байыйсы килә. Ә менә синең, күрәм, байыйсың килми. Таквә Сәхәүне баетып ятасың. Аның хикмәте,— энекәйләрем, шундый яхшы җирнең әрәм ятуында. Сөрәсе иде шул җирне дә, яшелчә утыртып җибәрәсе иде...

— Ул җирне күтәрү өчен, дүрт ат җигәргә кирәк,— диде берәү.

— Дүрт ат пустяк ул, машина кирәк анда; безнең илдә тракторлар бар бит... Берничә хуҗа артель булып берләшер идек тә, менә дигән җирне кисеп алып, бергәләп дөнья итә башласак, ә? — Ибрай тирә-ягына каранып куйды, тирә-як тыныч иде.— Юлын гына белмибез. Баш-күз алганчы хөкүмәт машиналар биреп торса... Кала итәр идек без бу авылны! Нигә? Валлаһи. Китереп ач шунда кәнсир заводы — помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме, үстереп өлгертәбез; китереп ач шушында шикәр заводы, чөгендер белән күмеп ташлыйбыз без аны. Электростанция корып җибәрсәң...

V—VII

Иртәнге чәйне эчкәндә, безгә бер кечкенә кыз бала килде.

— Исәнмесез,— диде ул,— Низамый абзый сезгә менә бу язуны җибәргән иде.

Конверттан кечкенә записка чыкты:

«Ильяс иптәш!

Бүген кич сәгать 8 дә, иптәшегез белән икәүләп, безгә сөйләшеп утырырга килүегезне үтенәм».

— Гаяз,— дидем мин.— Әллә Низамыйларга бармыйбызмы?

— Барыйк без аңа, Ильяс. Үз күзебез белән күрик-белик: нинди кош икән ул сәүдәгәр-комсомолец.

Низамый безне капка төбенә үк чыгып каршы алды. Беренче карауга аның киң, тигез маңгае һәм һәркемнең йөрәгенә керерлек матур итеп елмаюы күзгә ташлана. Күзләренең бик тиз алмашынып торулары Низамый белән озаграк утырдаш булганның соңында гына сизелә башлыйлар.

Низамый безне, зәңгәр йортка ялганып эшләнгән яшел рәшәткәле бакча капкасын ачып, туп-туры агачлар арасына алып керде. Күкрәп утырган күкчәчәк арасындагы кечкенә өстәл тирәсенә утырыштык. Куе шомырт куаклар арасыннан кызлар көлүе ишетелде. Тынгысыз йөрәкләребезгә нәрсәләр алып килер бу билгесез кызлар? Чү!.. Әнә алар.

Низамый безне таныштыра башлады. Иң элек алдан килүче сары чәчле кыз белән таныштырды ул безне:

— Таныш булыгыз, бу безнең комсомол ячейкасы секретаре һәм укытучыбыз Зоя туташ була.

Йөзе матур иде аның.

— Бусы менә минем сеңелкәш — Мәһибикә,— диде Низамый аксыл-зәңгәр кофталы, кара чәчле кызны күрсәтте.

Кызлар белән танышкач, без акрынлап өйгә таба атладык. Ап-ак эскәтер белән капланган зур өстәл тирәсен әйләндергән кара урындыкларга утыруга, Низамый табынның өстен ачып җибәрде. Бизәкле тәлинкәләргә матурлап тезелгән колбаса телемнәре, юка итеп туралган сыр, капкачлары ачылып куелган консерв савытлары арасында утырган кап-кара шешәләрне күрүгә, мин куркып киттем. Комсомолец өендә мондый күренеш булуын берничек тә башыма сыйдыра алмый идем мин. Аптырап, Гаязга карадым. Аның йөзе гадәттәгечә тыныч булса да, бу юлы ул тынычлык миңа тәэсир итә алмады.

Җиңги кеше табынга тәлинкәләр тезгән арада, без, урыннарыбыздан торып, идән буенча йөри башладык. Зоя белән Маһибикә безнең тирәдә уралалар, әйткән бер сүзебездән рәхәтләнеп көләләр иде. Балалыктан аерылып җитмәгән Маһибикәнең нәрсәседер миңа ошый башлады. Ул көлгән саен сөйлисе, аны һаман да көлдерәсе килә. Күзләрем белән йотардай булып, Маһибикәнең тулы кара күзләренә карыйм. Ул, минем карашыма җиңелеп, башын ия дә кызара, серле итеп елмая.

Без яңадан өстәл тирәсенә утырыштык...

VIII

Низамый безне күп озатмады, беренче тыкрыкны узуга ук кире борылды. Икәү генә калгач, байтак вакыт сүзсез бардык. Гаяз, сүз юктан сүз булсын дигән сыман гына итеп, миңа сорау биреп куйды:

— Син соң бернәрсә дә төшенмәдеңмени?

— Төшендем, Гаяз, Низамыйның чын комсомолец булып җитмәгәнлегенә төшендем, Зояның секретарьлыкка ярамаган кыз икәнлегенә төшендем.

— Бик азга төшенгәнсең. Ә мин Низамыйның безнең өчен дошман икәнлегенә дә төшендем. Зояның шул дошман кулында корал икәнлегенә дә төшендем. Маһибикәнең дә шул ук хезмәтне башкаруына төшендем.

Бу минутта авылда әтәч тавышлары басылган иде инде. Безгә шактый якынаеп өлгергән җыр тавышы ишетелде. Без акрын гына атлап килә-килә кайтып җитә язганбыз, Күчәрбайның, җырдан туктап, безгә якынлашканын да сизмәгәнбез икән. Ул якын килде һәм бөтенләй үзенә хас булмаган ачыклык белән сөйли башлады:

— Мин — инәсен югалткан куй бәрәне. Минем әйләнәмдә ерткыч бүреләр улый. Ул бүреләр мине кешегә санамыйлар. Алып китегез мине, дуслар, бу авылдан. Бер-ике ел читтә йөреп кайтаем.

Гаяз, аның янына ук барып, иңбашыннан тотты. Дусларча акрын тавыш белән тынычландыра башлады:

— Күчәрбай туган, мин синең йөрәгеңне аңлыйм. Сине бу авырлыктан коткарырга тырышырбыз. Ә хәзергә бүреләрнең нишләгәнен бик ныклап күзәтеп йөре. Иртәгә күрешербез. Хуш, хәзергә кайтып ят.

Күчәрбай, сүзсез генә баш иеп, Таквә йортына таба юнәлде.

IX—X

Йокыдан уяну чиксез күңелсез булды ул көнне. Әни безне йокыбыз туймас борын уятты. Салкын су белән битләребезне, күкрәкләребезне югач кына бераз адәм рәтенә кергәндәй булдык. Аның өстенә чәй дә эчеп җибәргәч, хәлләр тәмам җайланды. Җәяүләп Базарлы авылына — волкомга[1] чыгып китәрлек батырлык бар иде инде бездә.

Чыгып киттек. Сул ягыбызда Агыйдел. Ул дөньяның матурлыгы, яшәүнең шатлыгы турында өзлексез курай тарта.

Менә уң ягыбызда урман бөтенләй бетте... Сул ягыбызда да таллар бетте. Агыйдел нәрсәгәдер бик ачуланган төсле үкереп ага. Ул бу урында юрамалый бөтен көчен бергә җыярга теләгәндәй тарайган. Тимер аркан төсле ишелеп, тыгыз булып, өзлексез рәвештә тауга һөҗүм итә. Бу һаман шулай. Мин аны сабый чактан бирле беләм. Моңа кадәр дә бик күп заманнар һаман шундый көрәш баргандыр. Тик кем җиңә? — Билгесез. Агыйдел никадәр генә үкереп ташланмасын, барыбер тауны кисеп үтә алмый, башына сугылган төсле кинәт кенә читкә борылып тынычлана. Тау никадәр генә күкрәген киереп масаеп утырмасын, барыбер әкренләп кенә булса да чигенмичә булдыра алмый. Агыйдел аны бик күп кимергән...

— Беләсеңме, Ильяс,— диде Гаяз,— Агыйделнең шулкадәр көч белән үкереп тауга ташлануы мәгънәсез. Ул барыбер бу тауны җиңә алмый. Ә бу таулар — бу ташлар, минемчә, тикшерелеп бетмәгән әле. Алар астында безгә кирәкле

[1] Волком — комсомолның өлкә комитеты.

әйберләр табылмас иде дисеңмени син? Минемчә, менә шул Агыйделгә бу тауны актарып ташларга ярдәм итәсе иде. Электрик көче белән акыл көче генә кирәк монда. Электрик көче аның үзендә бар. Акыл көче үзебездә...

— Ә минемчә, шушылай әйбәт, Гаяз. Уйлап кара син, бу күренешләргә бер генә каравы да никадәр ял бирә. Бу һавада бер генә көн ял итү дә ел әйләнәсенә дәртләнеп яшәрлек энергия бирә... Аннан соң, табигатьтә һәрнәрсә дә урынлы яратылган булырга тиеш.

— Алай, менә ничек уйлыйсың икән, ике ел буенча иптәш булып йөреп, һаман да таныш бетерә алмаганмын икән үзеңне. Болай булса, син комсомолец түгел, Ильяс.

— Юк инде, Гаяз туган, берәү табигатьнең матурлыгыннан ләззәтләнә белә икән, аннан аның комсомоллыгына бернинди дә зарар килми. Минемчә, бездә буржуйныкына караганда да көчлерәк, бозылмаган хисләр булырга тиеш...

Агыйдел сулга борылып китеп бездән шактый ераклашкан иде инде. Авыл тирәсен әйләндергән киң чирәмлектә йөгерешеп уйнап йөргән малайлар күренде.

ВЛКСМның волость комитеты секретаре Рахманов безне шактый эре кыяфәт белән каршы алды. Таныштык.

— Иптәш Рахманов, без авыл ярлыларының теләкләрен алып килдек,— дип башлады Гаяз. Авылыбызга кайтканнан бирле башыбызны ваткан мәсьәләләрне ачып сала барды, мин аның фикерләрен куәтләп бардым.

Нәкъ шул вакытта кемдер, сак кына итеп, ишек какты. Ишек яртылаш ачылды һәм, безнең өчен ниндидер бер онытылган җырны хәтерләткәндәй, көмеш тавыш ишетелде:

— Мөмкинме?

«Әйе, миңа таныш бу, әйе, бу — ул»,— дип кычкырды күңелем. Аның Агыйдел ярына басып тауларга караган чагы күз алдымда шәүләләнеп узды. Нәрсә дип әйтергә, нинди хәрәкәт ясарга белмичә аптыраашта калдым. Гаязның күзләре гадәттәгедән көчлерәк яна башладылар.

— Кыюлыгым өчен гафу итегез,— диде кыз,— минем сездә йомышым бар.

— Яхшы,— диде Рахманов, кызга сөйләп бетерергә дә ирек бирмәде,— хәзергә утырып торыгыз, мин менә бу иптәшләр белән эшемне бетереп җибәрим.

Кыз риза булды. Тәрәзә янындагы артсыз урындыкка барып утырды. Рахманов өзлексез рәвештә үзе сөйли башлады:

— Кайтыгыз да, Низамыйлар белән бергәләп, тыныч кына эшләгез. Аларда стена газетасы чыга алмый, җәй көне спектакльләр куя алмыйлар...

— Болай булса,— диде Гаяз,— Низамый белән генә түгел, безнең юллар сезнең белән дә аерылышыр, ахры...

Гаязның батырлыгы минем күңелемне күтәрде. Аның бу кыю фикерләрен тагын да ныграк ишеттерер өчен, мин дә кушылдым:

— Әйе, һичшиксез, эш шулайга кала.

Моңарчы тыныч кына утырган кыз да безгә катнашырга теләгәнлеген белдерде:

— Мин дә нәкъ шундый мәсьәләләр буенча килгән идем.

— Тукта әле, кем син, нигә килдең син?— диде Рахманов, кызны яңа күргән төсле текәлеп карап.

— Мин,— диде кыз,— Кинҗә авылыныкы. Фамилиям — Иделбаева. Авыл хуҗалыгы техникумында укыйм. Җәйге каникул вакытында авылыма кайттым. Кайтсам: моннан дүрт ел элек тә кулаклар этлек эшләп ята иде, хәзер дә шулай ук...

Рахманов энәгә чәнчелгән төсле сикереп торды.

— Җитәрегез, шайтан алгыры! — дип кычкырып җибәрде ул.— Сез монда эшне бутарга кайткансыз. Сезнең ише сухой интеллигентлардан башка да ерып чыгарбыз. Довольно!

Кычкырыш шактый зурга китмәкче иде, барыбыз өчен дә абзый булган яңа кеше кереп тынычландырды.

— Безнең волком партия секретаре Аязгулов агай,— дип таныштырып куйды Рахманов.

— Безнең бар теләгебез — авылны социалистик юлга бастыру эшендә партиягә ярдәм итү. Шуннан чыгып, менә күргәннәребез турында киңәшергә килдек,— диде Гаяз.

Ярлылар арасында авыл хуҗалыгы артеленә оешып эшләү теләге барлыгы Аязгуловны аерата кызыксындырды.

— Әйбәт ният бу,— диде ул.— Хәтта бик әйбәт ният. Нигә син аларга ачуланасың, Рахманов?

Аның мондый карашы безне бөтенләй канатландырып җибәрде.

XI

Кайткан вакытта без дүртәү булдык. Дүртенче кеше капкара киң битле, елтыр-елтыр карый торган кара күзле унберунике яшьлек башкорт кызы иде. Артыкбикә үзенә иптәш итеп алып килгән булган.

Акрынлап кына авылны чыгуга табан атладык.

Кәефнең яхшылыгына, дәртнең көчлелегенә чыдаша алмыйча, чәчәк арасында куышып, төрле көйләргә җырлашып, кычкырышып килә-килә, без Агыйделгә якынайганбыз. Кинҗә кичүенә килеп җиткәнебезне сизми дә калганбыз.

— Хушыгыз, иптәшләр, мин уңга,— диде Артыкбикә.

Без сискәнеп киттек. Тукта, бу ничек болай тиз үтте әле? Без бит аның белән юньләп сөйләшергә дә өлгермәдек. Аның кем булуы, кайда торуы,ниләр эшләве турында да белмәдек. Без аның белән тагын очрашырбызмы? Ничек?

Гаяз үзен югалтмады. Минем күңелемдә уйланганнарны теле белән әйтте:

— Бигрәк тиз килеп җиткәнбез, минем сездән бер дә аерыласым килми иде әле.

— Тормыш дулкыннары аера шул, нихәл итик,— дип көлде Артыкбикә. Тик ул безнең өметебезне өзмәде, яңадан очрашырга, сөйләшергә вәгъдә бирде. Без үзебезнең авылда концерт оештырырга уйлавыбызны әйтеп, аның да катнашуын үтенгәч, килергә ризалыгын белдереп елмайды.

Алар уңга борылып, Агыйделгә аркылы төшеп киттеләр.

— Мин курка башладым әле, Гаяз. Безгә сугышырга туры килмәсә ярар иде.

— Мин сиңа бирешмәм дип уйлыйм.

Йөзләребезгә аз гына да көлү билгесе чыгармыйча, тирән тынычлык белән шундый сүзләр сөйләшә-сөйләшә җай гына атлаганда, арттан — Кинҗә кичүе ягыннан — йөрәк өзгеч аваз ишетелде:

— Коткарыгыз!

Гаяздан да, миннән дә бер генә аваз сүз дә чыкмады. Борылдык та чаптык.

Каршыбызга Зөлхиҗә килеп чыкты. Аның кара күзләре утланган иде:

— Артыкбикә апай... Артыкбикә апай...

Зөлхиҗә кире борылып чапты.

Иделне чыгуга, читәнле тарантаска җигелгән ак аргамак күзгә ташланды. Тарантастан читтәрәк агачлар селкенгәне сизелде. Куян өстенә атылган эт кыюлыгы белән таллар арасына атылдык.

Соңга калмасак та, шактый ямьсез күренеш өстенә килеп чыктык. Артыкбикә кычкырырга тели, ләкин аның авызын томалаган зур кул аңа ирек бирми. Ул кул — ат зурлыгы

гәүдәгә ия булган ир кулы. Киң симез битле, тап-такыр итеп кырылган башлы бу кеше бер кулы белән Артыкбикәнең авызын каплап, икенче кулы белән кулларын җибәрми тора.

— Җибәр, сволочь! — дип кычкырды Гаяз.

Ләкин симез кеше, бернәрсә дә аңламаган күзләре белән безгә караган килеш, шул хәлендә калды. Ике тапкыр әйткәннең соңында гына селкенмәгәнен күргәч, үз-үземне тыя алмадым, бөтен көчемне аягыма биреп, җинаятьченең уң як кулбашына типтем. Ул шуннан соң гына аягүрә басты. Артыкбикә аның кулыннан ычкыну белән сикереп торды, аерылган изүен ашыга-ашыга ябып, түбән караган килеш, таллар арасына кереп югалды.

— Артыкбикә, ерак китмә,— дип кычкырды Гаяз һәм, тавышына усал кискенлек биреп, җинаятьчегә сорау бирде: — Кем син, эт? Ничек син, шушы кыяфәтең белән, шул чәчәк кебек кызны җәберләргә батырчылык иттең?

Ләкин теге кешенең артык исе китмәде.

— Бәй,— диде ул, кулларын җәеп, йөзенә гаҗәпләнү чырае чыгарды.— Үз бисәм[1] булгас, теләһәм нәмә эштәргә лә курыкмаем мин, мулла никах укыган бисәм булгас... хәләл бисәм...

— Алдама, ерткыч! — дип кычкырдым мин.— Кайдан килеп синең бичәң булсын ул?

Гаяз әкрен-әкрен басып якынлаша башлады:

— Әйдә утыр атыңа, судка алып барам мин сине! Тот, Ильяс, бер кулыннан!

Башкорт бәләкәй балаларны селтәгән җиңеллек белән Гаязны селтәп очырды да аты янына йөгерде. Кадалып аккан Агыйделне минут эчендә кичеп чыгып, Базарлыга таба юыртты.

Артыкбикә янына бардык. Артыкбикә кыска гына карамага йөзе белән капланып елый иде. Гаяз аның тузган чәчләрен сыйпады:

— Иделбаева, елама, борчылма. Син ул кешене беләсеңдер бит?

Артыкбикә йөзен ачмыйча гына җавап бирде:

— Коткаруыгыз өчен рәхмәт, тик, зинһар, хәзергә мине калдырыгыз. Зинһар, китегез, хәзер мин йөземне күтәрә алмыйм, оялам, зинһар китегез.

— Син, алайса, безгә теге кабахәтнең кем икәнлеген генә әйт.

---

[1] Бисәм — хатыным.

— Әлимгул Алтынхуҗин дигән кеше ул, мине аңа кияүгә биргәннәр иде, ләкин мин аның хатыны түгел...

Без аны артык азапламадык. Саубуллашып, үз юлыбызга киттек.

XII—XVI

Рамазан гаете якынлашу уңае белән зур кичә уздырырга хәзерләндек без. Кайтуыбызга артык озак булмаса да, авылга тәмам ияләшеп җиткән идек инде.

Бу вакыт эчендә без ике тапкыр совхозга барып кайтырга да өлгергән идек. Совхозның җитәкчеләре безгә трактор белән җир сөреп бирергә вәгъдә иттеләр.

Беренче көннәрдә безнең өчен искиткеч булып күренгән Агыйдел буйлары, ямьле тугайлыклар — һәммәсе дә табигыйләштеләр. Күптән түгел, авылда комсомол ячейкасының гомуми җыелышы да булып үтте. Яңа секретарь сайланды. Үзлексез стена газетасы чыгарабыз. Крестьяннарның читән буйларында чүбек чәйнәп уздыра торган вакытларына да кысылабыз: ничек итеп күп уңыш алу, ничек итеп яхшы тормышка чыгу турыларында белгәннәребезне сөйлибез. Абзыйлар белән бергәләп кырга да чыгабыз; чалгы тотып, печән чабабыз, сәнәк тотып, кибән куябыз... Шулар нәтиҗәсендә безне бөтен авыл бик тиз белеп алды.

Бүгенге кичәбез шушы бер-ике атна эчендә алып барган эшләребезгә йомгак ясау урынын тота иде. Ул кичәгә без алдан ук хәзерләндек. «Галиябану»га кат-кат репетицияләр ясап, рольләребезне күңелдән белү дәрәҗәсенә килеп җитә яздык. Тик кичә башланыр вакыт җиткәч, эчне пошырган бер генә мәсьәлә булды: ул Артыкбикә мәсьәләсе иде. Ул килергә вәгъдә биргән иде. Артыкбикәнең килмәве шактый тынычсызландырды.

Шашып кул чабулар арасында кичәне ачып җибәрдек. Иң элек рәсми бүлек булырга, рәсми бүлек артыннан «Галиябану» шактый урын алырга, аннан соң концерт бүлеге булып, гает вакытына кадәр сузылырга тиеш иде.

Көчле алкышлар астында Гаяз сәхнәнең сул ягында торган трибуна артына чыгып басты. Гаязның нәрсәләр сөйләячәге миңа билгеле иде инде. Ул сүзләргә карата зал тарафыннан күрсәтелгән көчле игътибар минем йөрәгемне кузгатты. Бөтен тәнемне чолгап алган шатлыклы кан йөрешенә чыдый алмый идем мин. Чиксез бәхетле идем мин...

XVII

Спектакль башланырга биш минут вакыт калганда, көтелмәгән бер бәла килеп чыкты. Безнең янибызга гримланган артистларыбыз җыела башлады. Аларны күрүгә, Гаязның да төп эше исенә төште: ул ашыга-ашыга Хәлил булып киенергә тотынды. Минем яныма Маһибикә килде:

— Ильяс абый, гримым әйбәтме? — дип сорады ул миннән. Карчыклардан бигрәк, бите-башы балчыкка каткан балаларга охшый иде ул.

— Юк, Маһибикә, болай ярамый,— дидем мин,— кил үзем төзәтим.— Ул минем төзәтүемә, битләреннән сыйпавыма иркәләнеп, риза булып торды.

Аны рәтләп бетерергә өлгермәдем, Зоя килеп бүлдерде:

— Ильяс, кара әле, минем гримым ярарлыкмы?

Ул Галиябануны — авыл кызын уйный. Зур ачык якалы кофта кигән. Бөдрәләндереп кабарткан сары чәчләре өстенә кечкенә калфак кадаган булган. Җитмәсә, тездән генә итеп тегелгән зәңгәр юбкасы астыннан тыгыз ефәк оеклар ялтырый. Аягында биек үкчәле туфли.

— Юк, юк, Зоя, хәзер киемнәреңне алыштыр. Сиңа әзерләгән киемнәр бар бит.

Зоя, кирәксез кыланышлар белән боргалана-боргалана:

— Ә миңа шушылай килешә. Алыштырмыйм,— диде.

— Алыштыр!

Ашыга-ашыга, Гаяз килеп җитте.

— Юк, мин шушылай уйныйм.

— Бу нинди капризлану? — диде Гаяз, тавышын күтәреп.— Бүгенгә генә ташлап тор ичмасам шул мещанкалыгыңны!

— Алайса, мещанка булмаган кызларыгызны табыгыз,— диде дә Зоя, борылды да китте.

Гаяз белән күзгә-күз карашып аптыраштa калдык.

— Тукта, Зоя, үзең теләгән киемнәрдән уйнарсың, спектаклебезне генә харап итмә.

Зоя, безгә эндәшмичә, сикереп сәхнәдән төште дә мәктәптән үк чыгып китте.

Залда кул чабулар, аяк дөбердәтүләр көчәйгәннән-көчәя бара иде. Гаяз каты итеп тешен кысты, кашларын җимерде дә, уң кулын каты йодрыклап, һавага кизәнеп куйды:

— Ярый! — диде. Тавышы нык, ышанычлы иде: — «Галиябану»ны калдырабыз, концерт бүлеген башлыйбыз. Бар, син чыгып халыкка аңлат.

Мин пәрдә алдына чыгып басуга, кул чабу, аяк тыпырдату, сызгыру тавышлары басылды. Иң алдагы сафта утырган Низамыйның миңа карап мыскыллы елмаюы мине эсселе-суыклы итеп җибәрде. Минем нәрсә әйтүемне тирән тынычлык белән көтүче халык өстенә карап, «Иптәшләр!» диюемә, урам як ишек ачылып китте. Ят кызлар арасында аерылып Артыкбикә күренде.

Үземне үзем белешмичә, сәхнәдән сикереп төштем дә Артыкбикәгә каршы йөгердем.

— Соңгарак калдык, Ильяс иптәш, ачуланмыйсызмы? — диде Артыкбикә.

— Бик вакытлы, бик вакытлы, әйдәгез,— Артыкбикәне сәхнәгә алып кердем.

Гаяз аны күрү белән сикереп торды. Исәнлек-саулык сорашып тормастан, Артыкбикәнең иңбашларына килеп тотынды:

— Иделбаева, әйтегез: «Галиябану»да уйнаганыгыз бармы сезнең?

Артыкбикә тыныч кына елмаеп куйды:

— Техникумда чакта мин аның героинясы идем.

Үз-үзебезне онытып, икебез берьюлы кочаклап алдык без аны.

— Димәк, безне бу хурлыклы хәлдән котылдырдыгыз?

...Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты. Андый көчле җырны, андый йөрәк җырын гомеремдә беренче тапкыр ишеткәнмендер. Шулкадәр дәртләнеп, шулкадәр бирелеп җырлый иде Артыкбикә, әйтерсең лә ул чын-чынлап Галиябану кичергәннәрне кичерә. Анда гади кешегә аңлашылмый торган ниндидер сер яшерелгәндер сыман тоела...

Бу тиңе булмаган йөрәк көче алдында үзен үзе югалтмаган бер генә кеше күрдем мин — ул Низамый иде. Аның чыгып китүен миннән башка берәү дә күрмәде дә, сизмәде дә. Мин, үземне зур көрәштә җиңеп чыгучы батыр кебек хис итеп, залдан күзләремне алдым.

XVIII

Әйтеп аңлатырга мөмкин булмаган дәрәҗәдә көчле алкышлар, көчле «ура!» тавышлары астында беренче пәрдә төшерелгәч, барыбыз да Артыкбикә янына җыелыштык. Ничек итеп

котларга, нинди сүзләр белән тәбрикләргә белми идек без аны...

Сәхнәгә керә торган ишектән бер башкорт кызы дәште:

— Артыкбикә апай, һине Күсәрбай агаең көтә, сыкмайһыңмы?

Артыкбикәнең йөзендә көчле шатлык уты кабынды:

— Күчәрбай агаем? — дип кычкырып җибәрде.— Бердәнбер абыем ул минем!

— Хәзер алып керәм мин аны,— дидем мин, машина җитезлеге белән залга атылып төштем. Безне Артыкбикә белән Гаяз берьюлы каршы алдылар.

— Күсәрбай агаем, һинме был!— диде Артыкбикә.

Күчәрбай «мин» дияргә өлгермәде, Артыкбикә аның киң күкрәгенә капланды. Абыйсы аны сөеп чәчләреннән, иңбашларыннан сыпыра башлады.

— Артыкбикә иркәм, һин югалмадыңмыни?— диде ул. Аның күзләрендә яшь бөртекләре ялтырадылар.

XX

Гаяз белән минем тарафтан билгеләнгән план буенча, концерт программасын үтәп чыгып, иртәнге чәйне эчкәннән соң, без урманга чыгарга, серле таулар өстенә менәргә тиеш идек. Киттек. Мәһабәт тауның серле түбәсе читтән караганда бик якын сыман тоелса да, аның өстенә менү алай җиңел булмады.

Күчәрбай авылны чыгып, тугайлыкка керү белән ачылып китте. Үзенең туган авылыннан килгән башкорт кызлары белән шаян сүзләр сөйләшә башлады. Билгеле, Гаяз белән мин дә бу күңелле компаниядә суфи булып кына калмадык. Тик безнең күңелләр күбрәк Артыкбикәдә булды. Авылдан чыгып киткәннән бирле бер генә минутка да аңардан аерылмадык. Бөтен кызык сүзләребез аның кәефе өчен генә телебезгә килә, җитез хәрәкәтләребез аның йогынтысы астында гына сокланырлык булып чыга.

Тугай тавы озакка бармады. Уен-көлке, шау-шу белән аның өстенә менеп җитүебезне сизми дә калдык. Дөнья киңәйде. Артта — тугайда утырган авылыбыз кечкенә булып калды. Агыйдел озынайды, борылмалары ешайды. Агыйдел буена утырган авыллар да күбәйделәр.

Урман авызына кергәч, безнең тәннәребез тагын да яңа тойгылар белән чолганды. Берсеннән-берсе уздырышып үскән

имән, юкә, өрәңге, элмә агачларының яңа гына юындырылган яшь гөлләр төсле саф, иркә яфраклары безне салкынча урман һавасы белән коендырдылар.

Кучәрбай, баскан урынында елмаеп бераз торганнан соң:

— Әйдәгез, һаман болай әзер юлдан гына барсак, без гомердә дә тау түбәсенә күтәрелә алмабыз, әйдәгез, үзебез юл салыйк,— диде.

Аның бу сүзләре безгә бик тирән мәгънәле хакыйкать булып ишетелделәр. Чыннан да, без, әле һаман ике тау арасы буйлап салынган тигез, күләгәле юл белән, бернинди авырлык сизмичә, әкрен генә алга бара идек. Билгеле, бу юл әкренләп тауга күтәрелсә, аның без теләгән ноктага алып менү ихтималы юк иде. Андый тауларга менгәндә һәркем үзенә юл сала. Безнең дә шул законга буйсынмый хәлебез булмады.

Куе урман белән капланган тауның текә җиренә юлсыз күтәрелә башлагач кына, без никадәр авыр юлга чыкканыбызны аңладык. Өсте-өстенә авып җирне каплаган коры агачлар безнең аякларыбызны тырныйлар, тупас тау имәннәренең тырпаешып торган шыксыз ботаклары киемнәребездән тотып тарталар — бөтен көчләре белән безне алга җибәрмәскә тырышалар. Монда инде без бер-беребездән шактый аерылдык. Кучәрбай алдан китте. Гаяз, аңа иярә алмаса да аннан калышмаска теләп, барлык көченә ашыга, безнең күздән югалып куйгалый.

Бераз ял иткәннән соң, юлсыз җирләрдән текә тауга күтәрелүебезне дәвам иттерә башлагач, без арыганлыгыбызны тагын да ныграк хис иттек. Алга барудан бөтенләй гайрәтем чикте. Иптәшләргә кычкырдым:

— Шуннан ары бармыйк инде, кайтыр якка таба борылыйк.

— Нигә? — дип аптырады Гаяз.

Башкалар да, шундый ук сорау билгесе чыгарып, миңа карадылар. Мин үземне кинәт ялгыз хис иттем.

— Ярты юлны узгач, кире чигенмиләр, Ильяс,— диде Гаяз. Башка бер сүз дә әйтмичә, алга атлый башлады. Иптәшләр һәммәсе дә аның артыннан ияргәч, мин дә ялгыз торып кала алмадым, алар артыннан кузгалдым. Кучәрбай һаман да әүвәлгечә, куе урманны батырларча ерып, алдан баруын дәвам итә. Гаяз аның артыннан иярә.

Агачлар сирәгәйде. Тагын берничә адым үтүгә, без бөтенләй ялангач түбә өстендә булдык.

— Менеп җиттек,— диде Күчәрбай.

Һәммәбез дә иркен тын алдык. Күкрәкләребезне җиңү шатлыгы дулкынландырды. Тирә-якта без торган түбәдән дә биегрәк түбә күренмәде. Моннан инде дөнья чиксез киң булып күренә.

— Хәзер тилгәннәрнең чираты инде,— диде Гаяз.— Элек син алардан бәбкәләреңне саклаган булсаң, хәзер алар үз бәбкәләрен бездән сакласыннар.

Без, ташлар арасына кереп, биек текә ярның читенә якынлаштык. Бу куркыныч ярның читенә тагын да якынрак барырга йөрәгебез җитмичә тукталдык. Тик Гаяз гына батыррак булып күренергә теләде. Ул, бездән шактый күп аерылып, ярның кырыена ук бара иде. Артыкбикә аның өчен тынычсызлана башлады.

— Гаяз, барма, кайт кире, егылырсың,— ди иде ул.

Гаяз, ярдан аерылып, һавага сузылган кызыл таш өстенә үрмәләде һәм коточкыч бушлык өстенә сузылган кыя өстенә басып сикергәли башлады. Артыкбикәнең чын күңелдән тиргәп-тиргәп кире кайтырга чакыруы аны тагын да тилертә төште. Ул куркынычлы кыяның киртләчләнеп торган кечкенә ботагына таба атлады. Икенче аягын алып куярга өлгермәде, ул баскан кечкенә киртләч ярылып китте дә, Гаязыбыз күз ачып йомган арада, төзсез бушлыкка очып, күздән югалды. Аның артыннан, балалары-ниләре белән тузып, тилгән оясы төшеп китте.

Бөтенебез бердән үзәк өзгеч тавыш чыгарып, кычкырып җибәрдек. Мин, һушсыз булып ава башлаган Артыкбикәне тотып, кочагыма яткырдым.

Нишләдең син, Гаяз? Бервакытта да мондый башсызлыгыңны күргәнем юк иде бит мин синең! Нишләдең, нишләдең?!

XXI

Түбәнгә төшкән вакытта Күчәрбай безне иң кыска юлдан алып төште. Яр астына таба якынлашкан саен, йөрәк урыныннан чыга язып тибә. Гаязның үле гәүдәсе күз алдына килеп, бөтен кан тамырларым чымырдап, туңып китәләр.

Куе әрәмә арасыннан салынган тугай юлының күп бормаларының берсендә, бөтенебезне гаҗәпкә калдырып, каршыбызга теп-тере Гаяз килеп чыкты. Аның киемнәре юеш, куе бөдрә чәчләреннән су бөртекләре тамып-тамып торалар. Ул

кулындагы яңа гына йоны чыгып килә торган кош баласын безгә сузып елмайды:

— Күрәсезме, алдым бит, тилгән баласы бит бу!— диде.

— Гаяз,— дидем мин,— синме бу?

— Нигә әллә танымаслыкмы? — диде Гаяз, елмаеп.— Ялгышлык белән суга төштем шул, корыга төшкән булсам, болай юешләнмәгән булыр идем.

Нишләргә белмичә, шашкан кыяфәттә торган Артыкбикә кинәт «Гаяз!» дип кычкырып җибәрде һәм бөтен көченә ташланып, аны кочаклап алды. Артыкбикә артыннан без дә аны кочагыбызга алып тарткалый башладык.

— Хәтерлисеңме, Гаяз,— дидем мин,— беркөн шушында сөйләшеп утырган идек. Мин синнән: «Нәрсә бирсәләр шушы яр башыннан Агыйдел өстенә сикерергә риза булыр идең?» — дип сорагач, нәрсә дип җавап биргән идең?

Шушы тау чаклы алтын бирүче булса да сикермәс идем, дигән иде ул.

— Ә бүген бер тилгән баласы өчен сикердең,— диде Артыкбикә.

Яр башыннан ычкынып китеп, үзен үзе югалтмыйча, суга аяк белән төшәргә кирәклекне уйлап өлгерә алырлык ихтыярга ия булган характерлы Гаяз өчен тапкыр җавап бирү кыен булмады.

— Юк, мин тилгән баласы өчен сикермәдем һәм тау чаклы алтын бирсәләр дә сикермәгән булыр идем. Минем өчен шушы тау чаклы алтыннан да кадерлерәк күренгән зат өчен сикердем мин,— диде ул серле елмаю белән һәм Артыкбикәгә карап тукталды.

Минем кинәт күңелем әллә нишләп китте. Үземне үзем өзгәләп ташлардай булдым мин шул минутта: их, нигә Гаяз урынына мин егылып төшмәдем соң бу яр башыннан?

XXII—XXVIII

Таквә Сәхәүләр ягыннан безгә карата ачык төстә чыгыш ясаулар күренмәде. Алар без башлаган эшләргә аяк чалуны яшерен төскә күчерделәр. Аларның нинди корал белән эш итүләрен белә алмый идек без. Артельгә оешып эшләргә теләүчеләр исеменнән җир кисеп алырга сорап җибәрелгән гариза җавапсыз ята. Артыкбикәгә һөҗүм иткән өчен безнең тарафтан судка бирелгән Әлимгулның эше дә, Кучәрбайның

Таквә Сәхәүгә биш ел эшләгән өчен хезмәт хакын даулап биргән шикаяте дә һаман нәтиҗәсез буталып йөриләр. Бу эшләрдә шул ук Таквә Сәхәүләрнең, Низамыйларның кулы уйный.

Таквә Сәхәүләр гаиләсендә ниләр бар, ниләр сөйлиләр — аларның бик күбесе Күчәрбайга вакытында мәгълүм була бара иде. Көннәрдән бер көнне ул безгә мондый хәбәр китерде: «Шәфыйк сәүдәдән зур файда итеп кайткан. Иртәгә дусишләрен җыеп, мәҗлес уздыра,— диде ул һәм өстәп куйды: — Андый мәҗлесләрен күргәнем бар. Андый вакытларда алар йөрәкләрендә булган серләрен сөйләшәләр. Тыңлап торсаң, яхшы булыр иде».

— Миңа аларның өйләренә кереп калырга булмыймы? — дип сорады Гаяз.

Күчәрбай уйлап тормыйча ук җавап бирде:

— Батырлыгың җитсә була. Алар көндез кунак өйләренә кереп тә әйләнмиләр.

— Барып чыга бу, мин тәвәккәллим,— дип куйды Гаяз.

Мин аңа каршы төштем:

— Ярый. Барып чыкса, бик әйбәт. Әгәр дә эләксәң, шунда өйләрендә ятканда тотып алсалар?

XXX

Көзге аяз көн. Тонык саф һавада ап-ак пәрәвезләр йөзә. Җәен ямь-яшел булып күпереп утырган урманлы тау сары, кызыл, соры төсләргә кереп алаланган.

Кучерда минем абзый утыра. Түрдә, тарантас читәненә арка терәп, Артыкбикә белән мин. Без шәһәргә — укуыбызны дәвам итәргә китеп барабыз.

Минем йөрәгемдәге басыла башлаган яра бу юлга чыгу белән яңадан кузгалды:

— Ах, Гаяз да булса, нинди күңелле булыр иде,— дип куйдым. Артыкбикә тирән итеп көрсенде:

— Үзенең җиңешләрен үзе күрә алмады, мескен! — диде ул.

Аның күзләрендә күренгән яшь бөртекләре мине дә йомшаттылар.

Бу вакытта инде мин Артыкбикәне Гаяз исән вакыттагы яратуым белән яратмый идем: Гаязны яраткан ярату белән ярата идем мин аны.

Яшел Елга тамагын үтеп, кечкенә тауга күтәрелүгә, безнең каршыбызда кап-кара диңгез төсле җәелеп яткан киң итеп сөрелгән җир ачылды. Күп еллар буенча сөрелмичә, чирәмгә

әйләнеп, Ибрайның күзен кыздырып яткан җир иде ул. Бу җирне үтүгә, сабанчылар күренде. Алар, «Агыйдел» артеле кешеләре, үзләренә бирелеп тә, агач араларында булу сәбәпле, совхоз тракторы сөрми киткән җирләрне туңга сөреп калдырырга чыкканнар иде. Сабанчылар арасыннан кемдер, кулын болгап-болгап, безгә кычкыра башлады.

Безгә кычкыручы кеше Имәли иде:

— Безнең белән күрешмичә дә китеп барасыз, ай-яй,— дип үпкәләде ул.— Ә безнең монда беребездә дә шырпы калмаган.— Ул, төреп колак артына кыстырылган тәмәкесен авызына кабып, минем янга килде.— Кабыз әле, Ильяс.

Без килеп җитүгә, икешәр төрәнле яңа сабаннар берәм-берәм сөрүдән туктадылар, безнең янга җыелдылар. Ибрай озын мыеклы кешеләргә генә хас булган киң елмаюы белән каршыбызга килеп басты:

— Киттегезме инде, балалар?— диде ул. Үзе җавап биргәнебезне дә көтмичә кайгырып куйды: — Яхшылап озатып та булмады бит, китүегез эш вакытына туры килде.

Имәли, авыз тутырып тәмәке төтенен суыргач, көр, иркен тавыш белән:

— Киткән вакытта әйтеп калыйм, алтыннарым, безнең өчен башыгызны кызганмадыгыз, рәхмәт,— диде.

Барысы белән дә саубуллаштык. Хат язышып, хәбәрләшеп торырга сүз бирештек. Кузгалып киткәч, артыбыздан Ибрай йөгереп килде:

— Кая, бер-ике шырпы калдырып китегез инде, утыбыз беткән. Куна ятып эшлибез бит.

Мин аңа шырпы калдырдым.

— Мә, Ибрай абзый, сүндерми саклагыз, ут кирәк булыр.

1935 ел

Әсәргә анализ

Повесть эчендә ике сюжет була, дидек. Димәк, әсәрне сюжет сызыкларына таркатабыз.

> Сюжет бер темага буйсынган берничә вакыйганы үз эченә ала. Икенче бер темага буйсынган вакыйгалар башка сюжет төзиләр. Дөрес, сюжетлар үзара әледән-әле кисешәләр. Ләкин барыбер аларны сюжет сызыклары дип аералар.

Әсәрнең төп геройлары — Ильяс белән Гаяз. Аларның дуслыгы повестьның башыннан алып ахырына кадәр сузыла.

Шуңа күрә бу вакыйгаларны сюжет сызыгы, дибез. Сюжеттагы вакыйгаларның төенләнүен, киеренкеләнүен, киеренкелек тудыра-тудыра иң югары ноктага җиткәч, кинәт чишелүен беләбез. Димәк, ике егет арасындагы дуслык та шундый үзгәрешләр кичерергә тиеш була.

Алар — техникумда укыганда аерылмас дуслар.

Авылга кайткач, Ильяс, үзе дә сизмичә, Гаязның ихтыяр көченә буйсына. Практик эшкә керешү белән, Гаязның күп яктан өстенлеге сизелә башлый. Ул дустыннан зирәгрәк тә, тәвәккәлрәк тә, тынгысызрак та икән. Ильяс Гаязның булдыклылыгы белән горурлана. Аңардан көнләшә. Ләкин бик матур көнләшү белән көнләшә. Хәзер ул бар яктан да Гаязга охшарга тырыша.

Дуслар бер үк кызга — Артыкбикәгә гашыйк булалар. Ильяс көнчелегендә дустына карата каршылыклы хисләр уяна. Әмма дуслык хисе җиңеп чыга. Кызның кемгә күбрәк игътибар итүен күреп, Ильяс мәхәббәт хисен җиңә ала.

Низамыйларга кунакка баргач, Ильяс дустының киңәшенә беренче тапкыр каршы килә. Гаяз аңа ят йортта сер бирмәскә, сыйлардан баш тартырга куша. Ильяс үзенчә эшли һәм көлкегә кала.

Яшьләрнең тау очына менү вакыйгасында дуслык тагын бер сынау үтә. Ильяс белән Артыкбикә биеккә менмәскә киңәш бирсәләр дә, Гаяз үзенекен итә: мактана-мактана тауның иң очына менеп китә һәм егылып төшә. Ильяс дусты холкында моңа кадәр күзенә чалынмаган яман сыйфат күрә.

Ләкин киреләнү берзаман каршылыкка әйләнә. Гаяз, Ильяс сүзен тыңламыйча, дошманнары өенә кереп сәке астына кача. Бу юлы каршылык Гаязның үлеме белән тәмамлана.

Чишелеш вакыйгасында авторның безгә әйтәсе идеясе ята. Гаязны югалткач та, артель оештыру эше дәвам итә. Ләкин хәзер Ильяс Гаяз эшлисе эшләрне дә берүзе башкарырга тиеш була. Ильяс үзе эшли, үзе аптырый. Хәзер ул дусты кебек уйлый һәм аның кебек тәвәккәл, зирәк була ала икән. Димәк, әле тәнкыйтьләп, әле өйрәтеп, әле үрнәк күрсәтеп, Гаяз аны үз югарылыгына үстергән. Гаяз дустын да, үзе кебек, куйган максатка омтылырга һәм җиңеп чыгарга өйрәткән икән. Шәһәр егете Гаяз Ильяс янында табигать матурлыгын күреп сокланырга, кешеләрне яратырга өйрәнә.

Сюжет сызыкларының икесе дә нәкъ менә шул идеяне ачу максатында хезмәт итәләр, чөнки Мирсәй Әмир әсәрендәге

сәясәт идеясен дә гүзәл дуслык идеясенә буйсындыра. Яңа тормышны бары тик Гаяз белән Ильяс кебек риясыз дуслар гына төзи алалар, артельдәге күмәк хезмәткә шундый дуслык кына матур нәтиҗә бирә ала, ди.

Биремнәр

1. Икенче сюжет сызыгындагы вакыйгаларны үзегез табыгыз.

Хикәя белән повестька анализ ясауны төп геройларның холыкларын ачыклаудан башлыйбыз.

Ильяс белән Гаяз холыкларындагы охшаш сыйфатлар: икесе дә бер-берсе өчен утка да, суга да керергә әзерләр. Икесе дә — гаделсезлек дошманнары. Ләкин алар тормыштагы гаделсезлекне гаепләү белән генә канәгатьләнмиләр, аңа каршы көрәшәләр дә. Охшаш сыйфатлар шуның белән бетә.

Ильяс — авылда эшләп үскән егет. Эшендә дә беркадәр салмаклык күренә. Аның караваы ул бер эшкә дә ахырын уйламыйча тотынмый. Ильяс туганнарын ярата, табигать матурлыгына сокланып туя алмый, туган авылына, авыл кешеләренә гашыйк. Аның күңеле бай. Дусты Гаяздан төп аермасы әнә шундый рухи байлыгында. Ә Гаяз — көрәшче. Аның рухи таянычы идея — көрәш идеясе. Шуңа күрә бу тәвәккәл, батыр, тынгысыз егетнең күңеле хискә ярлы.

Гаяз белән Ильяс — капма-каршы холыклы дуслар. Гаяз — шәһәрдә эшче гаиләсендә үскән егет, батыр, тәвәккәл, ләкин дуамал. Бер эшкә керешсә, алдын-артын уйлап тормый — ниятен тормышка ашырырга ашыга.

Автор егетләрнең бу сыйфатларына бәяне Агыйдел сыйфатлары аша бирә.

2. Әсәрнең икенче бүлеген кабат укыгыз. Агыйделнең нинди сыйфатлары Гаяз белән Ильяска бәя бирә?

«Агыйдел» повестенда табигать күренеше

Мирсәй Әмир әсәрендә Агыйдел, таулар, урман, гомумән, авыл күренеше турында күп яза. Шулкадәр күп яза ки, табигать сурәтләнгән урыннарны бергә җыйсак, тулы бер сюжет сызыгы була алыр иде. Шулхәтле тәфсилләп сөйләгән яшәү урыны вакыйгаларның чынлыгына ышандыра. Кешеләрне һәм аларның эш-гамәлләрен ачык итеп күз алдына китерергә ярдәм итә.

Шуның белән бергә, әдип туган як табигатенең гүзәллеген күрсәтүне дә максат итеп куя.

Җир өстендәге матурлыкны бер вакытта да, бер кеше дә күреп тә, тасвирлап та бетерә алмый. Матурлыкның башкалар сизмәгән якларын күрү өчен, күңел күзе кирәк. Әдип табигать матурлыгының без күреп бетермәгән яңа якларын күрә. Аны укучысы күз алдына китерерлек итеп сурәтли. Шуңа күрә әдипнең күңел күзе һәм осталыгы бездә соклану хисе уятырга тиеш. Зирәклек тә, осталык та табигать тудырган матурлык бит.

Табигать матурлыгы һәм матурлык тудырган мәхәббәт хисе турында, гадәттә, шагыйрьләр язалар. «Агыйдел» повестенда Мирсәй Әмир үзен чын шагыйрь итеп таныта.

Ләкин повесть иҗат итүче әдип табигать күренешләренә тагын бер эш йөкли: аларны метафора итә һәм әсәрдәге вакыйгаларга шулар ярдәмендә бәя бирә. Алар ярдәмендә сюжет сызыкларын үзара бәйли һәм үзенең уен, теләген метафоралардан әйттерә.

Үзегезне үзегез сынагыз. (Контроль эш)

1. «Повестьның авторы турында» дигән бүлекне өлешләргә бүлегез, һәр өлешкә исем бирегез.

2. Шундый ук юл белән «Әсәргә анализ» бүлеген дә таркатыгыз.

3. Повестьтагы өч вакыйганы: Агыйделнең, үзенә кушылган елгаларны иyртеп, диңгезгә коюы, яшьләрнең таугa менүләре һәм яшьләрнең артель төзү вакыйгаларын исегезгә төшерегез. Бу вакыйгалар бер-берсе белән бәйләнешкә кереп, берсен-берсе тулыландырып, әсәрнең эчтәлеген ачарга ярдәм итәләр.

Эчтәлек табарга бу өч вакыйганың кайсы ничек ярдәм итә?

Иншa языгыз. Темасы: «Дуслык».

Эпиграф итеп «Агыйдел» повестеннан Гаяз сүзләрен язып куегыз. Менә ул: *Безнең дуслык бер-беребезне үтә күрүебезгә нигезләнгән. Синең йөрәгең минем өчен, минем йөрәгем синең өчен яшерен түгел.*

Һәркемнең якын танышы, иптәше, дусты бар. Димәк, һәркемнең дуслык тәҗрибәсе дә бар дигән сүз. Дуслык турында гомуми сүзләр белән сөйләмәгез, әнә шул дустыгыз турында языгыз. Билгеле, дустыгызга да, үзегезгә дә теләсә нинди күңелегезгә ошаган сыйфатларны өсти аласыз. Исемнәрегезне алыштырып, башка исем дә ала аласыз. Булмаган вакыйга уйлап табарга да мөмкин.

ЯЗУЧЫ ИҖАТЫНА АНАЛИЗ

Моңа кадәр язучыларның аерым әсәрләрен өлешләргә бүлеп өйрәндек.

Әсәрләрне жанрларга җыеп та өйрәндек. Әсәрне тәмамланган, чикләнгән бербөтен күренеш итеп күз алдына китердек. Быел да шул ук эшне башкарачакбыз, ләкин хәзер әсәр үзе башка бер бөтенлекнең өлеше генә булачак. Әсәрдән зуррак бөтенлек — язучы иҗаты. Язучы иҗаты дип язучының барлык әсәрләренә әйтәләр.

Язучы иҗатының үзенчәлеге

Һәр язучының үзе яраткан темасы, теләге, сәнгать алымнары була. Әсәрләрендәге әнә шундый уртак сыйфатларга бу язучының үзенчәлеге диләр.

Безнең максат күренекле әдипләрнең иҗат үзенчәлеген табудан гыйбарәт.

Әдип иҗатының үзенчәлеген табу өчен, әсәрләрендәге уртак сыйфатларны табарга кирәк Ә уртак сыйфатларны табу өчен, әдип әсәрләренә анализ ясау сорала.

Язучы иҗатының үзенчәлеген табу өчен, төрле эчтәлектәге, төрле сәнгать алымнары белән иҗат ителгән әсәрләрнең уртак сыйфатларын табарга тиеш булабыз.

> **Искә төшерик:** фикерләүнең төп алымнары икәү — таркату (анализ) һәм кушу (гомумиләштерү).

Язучы иҗат иткән әсәрләр күп. Аларның барысын да укып чыгу яхшы булыр иде, әлбәттә. Ләкин безнең дәреслек тә, дәресләргә бирелгән сәгатьләр дә күп әсәрләрне сыйдыра алмый. Шуңа күрә язучының берничә әсәрен өйрәнү белән генә чикләнәчәкбез.

Алай да, язучы иҗатының үзенчәлеге әсәрләренең уртак сыйфатларында гына дисәк, ялгыш булыр. Яңалыклар күплеге дә иҗат үзенчәлеге була ала.

Язучы иҗатының үзенчәлеген белми торып, язучының үзен белеп булмый.

«Үзегез турында сөйләгез әле» дигән сорауга язучылар, гадәттә: «Минем тормышым турында беләсегез килсә, әсәрләремне укыгыз, бөтен барлыгым белән мин шунда»,— дип җавап бирәләр. Язучы иҗатының үзенчәлеген өйрәнү — беренче чиратта аның талантын, тормышка карашын, кичерешләрен, холкын белү ул.

Ләкин бериш әсәрдә авторлар үзләре дә персонаж буларак катнашалар һәм үзләренә үзләре бәя бирәләр. Мондый очракта язучының үзенә үзе биргән бәясе иҗатының үзенчәлеген табарга ярдәм итә.

Сибгат Хәким
(1911—1986)

Күренекле татар шагыйре Сибгат Хәким (Сибгат Таҗи улы Хәкимов) 1911 елның 4 декабрендә Татарстан Республикасы Әтнә районы Күлле Киме авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Авыл мәктәбендә җиде ел укыгач, авыл хуҗалыгы белгечләре хәзерли торган техникумда белем ала. Техникумда укыганда шигырьләр яза башлый. Монда игенчелек фәнен яшь агроном Гатуф Яхин укыткан. Үзе шигырьләр язмаса да, Гатуф матур әдәбиятны яраткан. Күп санлы шигырьләрне яттан белгән һәм студентларына артистларча оста итеп сөйли торган булган. Шуңа күрә беренче шигырьләрен Сибгат аңа күрсәткән. Гатуф Яхин кульязмаларын укып чыккан да:

— Син, энекәш, шагыйрь булып тугансың. Агроном синең һөнәрең түгел. Быелдан ук педагогия институтының әдәбият бүлегенә кереп укый башла, чын шагыйрьгә белем дә кирәк,— дип киңәш биргән.

— Укулар башланган бит инде, алмаслар шул,— дигән Сибгат. Гатуф шунда ук декан исеменә үз исеменнән хат язган.

— Деканга туп-туры барып кер дә шушы хатны күрсәт, алырлар,— дигән.

Агроном укытучы деканның танышы булганмы әллә студентының талантлы шагыйрь булачагын дәлилли алганмы,— Сибгать Хәким шул ук елны институтта укый башлый.

Бу вакыйганы миңа Сибгат Хәким үзе сөйләде. Күлле Кимегә, синең әтиең укыткан, мин укыган техникумны күреп

кайтырсың, әтиең йөргән юллардан йөрерсең, ул менгән тауларга менәрсең, әйдә, бергәләп кайтыйк авылга, дип чакырды.

Ул чакта мин «Чаян» журналының редакторы идем. Сибгат Хәкимнең вакыты булмадымы, мин эштән бушамадыммы — әйтә алмыйм. Без Күлле Кимегә бергә бара алмадык. Әтинең якты истәлеген күңел дәфтәрендә саклап йөрткән шагыйрь теләгенең үтәлмәвенә һаман үкенәм.

Халык күңеленә әдип Бөек Ватан сугышына кадәр үк язган «Юксыну» шигыре белән кереп урнаша. Композитор Шакир Мәҗитов шигырьгә көй яза.

Сугыш кырында үзенең ротасы белән дошман атакасына каршы торганда да, ротасының алдына басып атакага күтәрелгәндә дә, әдип әлеге шигырь язмышын белми әле.

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән,—

дип, Сибгат Хәким яшьлек мәхәббәте турында яза. Әмма сугыш елларында ялгыз калган әби-бабайлар, аналар, балалар шигырьгә бөтенләй башка эчтәлек салалар. Елый-елый, фронттагы якын кешеләренең язмышы өчен кайгырулары һәм аларга мәңге тугрылыклы булып калачаклары турында җырлыйлар.

Бу җырны белмәгән, җырламаган кеше булмый. Аны көн дә диярлек радиодан тапшыралар. Концертларга шул җырны тыңлар өчен баралар. Халык аны елый-елый тыңлый, елый-елый җырлый, елый-елый юана.

Сибгат Хәким фронтта чакта да матур-матур шигырьләр язды. Сугыштан ул танылган шагыйрь булып исән-имин әйләнеп кайтты. Тиз арада халыкның иң яраткан шагыйрьләренең берсенә әйләнде. Аның сүзләренә көй язмаган композитор юктыр. Күп җырлары әллә кайчан халык җырлары булып китте. Менә шуңа күрә дә Сибгат Хәким Татарстан Республикасының халык шагыйре (1986) дигән дәрәҗәле исемгә лаек булды.

Бик бәхетле, бик талантлы шагыйрь моңы гына халык күңеленә үз моңы, үз хәтере булып урнаша ала.

Шигырьләрдә тема уртаклыгы

Инша язганда уң як читкә эпиграф — әдип әсәреннән берәр өзек теркәп куярга яратасыз. Эпиграф инша темасын

бик кыска итеп ачып бирергә тиеш. Берничә юл белән бөтен бер теманы ачарлык өзекне ничек табарга соң? Әйтик, сезгә Сибгат Хәким иҗаты турында инша язарга кушылды, ди. Башта, билгеле, әдипнең дәреслектәге әсәрләрен кабат күздән кичерәсез, аннары башка әсәрләрен өйрәнәсез. Әдип иҗаты турында фикер туплагач, эпиграф эзләргә керешәсез. Язучылар әсәрләрендә еш кына үз иҗатларына бәя бирәләр, дидек. Сибгат Хәкимдә дә шундый шигъри юллар юкмы икән? Эзли торгач, шагыйрьнең үз күңелендәге даими хисләре турындагы юлларны эзләп табасыз. Менә алар:

Еш кына мин шулай,
Ташый да дәртләрем,
Актара башлыймын
Күңелем дәфтәрен.
Анда бар уйларым:
Сөюнең сагышы,
Йокысыз походлар,
Илемнең язмышы.
Барсы бер моң булып
Саклана һәрчакта...

«Диңгез күзе» исемле әсәреннән алынган бу өзектә шагыйрь үзен һәрдаим борчып торучы өч сәбәпне әйтә: алар — сөю сагышы, сугыш елларында күргәннәре, илнең иминлеге. Шул өч тема Сибгат Хәким шигырьләрендә дә кабатланырга тиеш, дибез.

Ни өчен шундый нәтиҗә ясыйбыз? Сорауга болай җавап бирик: сөю сагышы да, сугыш еллары да, ил язмышы да — әледән-әле җанланып торган хәтер хисләре. Әлеге өч сәбәп тудырган хисләр Сибгат Хәкимнең лирик шигырьләрендә сурәтләнә. Ә лирик шигырьләр эчтәлегенең хис булуын беләбез. Димәк, әдип шигырьләрендә өч төрле хис кабатланырга тиеш.

Ә хәзер шигырьнең соңгы ике юлына игътибар итик. Сибгат Хәким күңелендә бу өч сәбәп тудырган өч төрле хис бергә кушылып, бер моңга әйләнеп яши икән. Өч сәбәпнең күңелдә бер моң булып яңгыравын гадәти сөйләм дә, фәнни тел дә әйтеп бирә алмый. Без ул моңны шагыйрь әсәрләрен бер-бер артлы укысак кына тоя алабыз. Шуңа күрә шагыйрь сүзләрен әсәрләренә анализ ясап расларга тырышабыз. Расласак, әдип иҗатының төп үзенчәлеген табачакбыз.

Язучы иҗатына бәя бирерлек өзекне **әдип иҗатының фокусы** дип атыйк.

«Фокус» — латин сүзе. Янәшә үтүче нурларның бер ноктага җыелуына **фокус** диләр. Димәк, язучы иҗатының

фокусы да әсәрләрнең уртак сыйфатларын җыеп торучы шигырь яки әсәрдән өзек була.

Язучы иҗатының фокусын тапкач, әсәрләр арасындагы бәйләнешне эзләү һәм нәтиҗәбезне дәлилләү эше җиңеләя төшә, чөнки иҗатының төп сыйфатын автор безгә үзе әйтеп бирде бит.

Шагыйрь үзенең иҗаты турында «Шигырь ничек туа?» дип исемләнгән мәкаләсендә дә язган.

Шигырь ничек туа?

Шигырь ничек туа? Укучылар белән очрашканда мондый сорауны күп ишетәсең. Бу сорауга җавап бирер алдыннан әле син шигырь төзелеше, аның законнары, алымнар һәм, гомумән, осталык белән бәйләнгән бүтән якларыннан бигрәк поэзиянең төп чыганагы — тормыш турында уйлыйсың.

Чыннан да, хәзер син кайсы гына шигыреңне хәтергә төшермә, аларның нигезендә ниндидер берәр тормыш детале, вакыйга ятканын күрәсең. Ул шигырьләргә карап, үзең үткән юлны да хәтта ачык итеп күз алдына китерергә мөмкин. Тормышны үзең аша кичерми торып, бер генә әйбәт шигырь дә тумый, ахрысы.

Мин еш кына 1943 елның июль аен искә алам. Юк, шагыйрь булып түгел (ул чакта шагыйрь булуың синең никтер бөтенләй баштан ук чыккан), ә взвод командиры сыйфатында миңа атаклы Курск дугасында барган сугышларда башыннан ахырына чаклы катнашырга туры килде.

Хәзер менә шактый еллар узганнан соң, артка борылып карыйсың да сине ул вакытта көрәшкә илһамландырган көчнең, ышанычның каян килгәнен яхшырак төшенәсең. Сугышта сине чиксез куандырган нәрсә — ул үзеңне дошманыңнан күп өстен, күп көчле хис итү. Син үз эшеңнең хаклыгы, гуманлы булуы белән аннан буй җитмәс дәрәҗәдә югары торасың. Син мораль яктан өстен. Моңа хәтле кайдадыр тирәндә яшеренеп, тынып яткан ниндидер билгесез хисләр тәмле дә, газиз дә булып әкрен-әкрен куералар, тыгызланалар, күтәреләләр. Бу хисләрнең тамырлары еракта, бик еракта. Аларда артта калган балачак моңсулыгы да, туган ягыңның кечке эңгере дә тирбәлә... Бу, бәлки, илеңнең шушындый авыр көннәр кичергән чакларында гына туа торган кадерле, олы хисләрдер? Белмим. Ләкин мин аларның бөтен

матурлыгын әнә шунда күрдем, аларның башка берни белән дә алыштыргысыз, күңелемә якын икәнлеген беренче тапкыр менә шунда татыдым...

Сугыш та бетте. Ил үзе дә, аның солдатлары да сугышта алган яраларын төзәтергә керештеләр. 1948 елны дәваланырга дип мин дә Кавказга барырга җыендым. Мине яңадан тетрәткән нәрсә шул булды: мин Кавказга Орел — Курск — Белгород — Харьков тимер юлы буйлап, нәкъ үзем сугышып йөргән кырлар аша уздым. Монда миңа күп нәрсә, бик күп нәрсә таныш: үзәннәр дә, ике яклап сузылган ап-ак йортлы авыллар, снарядлар актарган таулар, тау битендә биектә күпне күреп шактый эләккән зур соры чиркәү, тимер юл читләрендәге куаклыклар.

Менә шул хәзер инде бераз серлерәк тә булып күренгән куаклыклар артыннан бергә хезмәт иткән дусларым — солдатларым каршыма килеп чыгар кебек тоелды. Аларның төсләрен, буй-сыннарын, үзләрен тотышларын күз алдыма китердем, аларны сагындым. Бөтен үткәнем кабат терелде. Вагон тәрәзәсеннән кергән таныш җил күңелемнең әллә кайсы төшенә кагылды, күңел тулды, сыкранды, ташыды; карадым, аерыла алмый бөтен нәрсәгә йотылып карадым. Менә кайда минем шул кешеләр турында исән калган иптәшләремә сөйлисем килде, әрнеп-әрнеп язасым килде. Йокы да, тыныч ял да очты. Кавказдан кайтуым белән, мин үземнең туган авылыма киттем һәм шул сугышлар белән бәйләнгән шигырьләремне яздым. Аларның оеткылары минем йөрәккә күптән, 1943 елларда ук салынган, әмма көтмәгәндә, менә хәзер ташып чыгар дип ул чакта кем аны башына китергән?

Шигырьнең шулай көтмәгәндә тууына тормыш үзе генә сәбәпче.

Шигырь синең йөрәгеңә, үзең дә сизмәстән, төрле юллар белән килеп керә. Туган ягыңа кайткач, сине беренче очраткан кеше дә сүзне: «Чыпчык та үз чытырманым ди икән»,— дип башлап китә. Янәсе, кешегә генә түгел, хәтта чыпчыкка да үз оясы якын. Минем туган як — Казан арты. Яшьтән үк монда халык шагыйре Габдулла Тукайның эзләрен күреп, аның «Шүрәле», «Су анасы» әкиятләрен тыңлап үскәнгәме, аерата матур, аерата сихерле.

Төрле чак булгандыр. Шулай да туган ягыма мин авыр сүз әйтеп бервакытта да тел тидермәдем. Минем барлык якты уйларымның җирлеге шунда, язган вакытта әнә шул җирне,

шул туфракны сизеп, тоеп торсаң, нинди рәхәт... Моннан киткәндә сине озатырга килгән олы яшьтәге берәр ил агасының «Күрмәсәм, улым, бәхил бул!» дип эндәшүе дә җанга күпме шигъри моң сала. Бу бит бары туган якта гына әйтелә торган, аерылу белән бәйләнгән кадерле сүзләр, ул сүзләр юлда яңадан үрләр менгәч борылып караган саен тагын-тагын күңелдә кабатлана: «Күрмәсәм, улым, бәхил бул!» Менә яз гына, үзе шигырьгә сорап тора, бу — аның иң кирәкле беренче юлы.

Ләкин шигырь юллары җиңел генә, үзләреннән-үзләре генә тумыйлар. Син теләгән юллар табылганчы, туктаусыз үзеңә эзләнергә, тормышның төрле почмакларына күз салырга кирәк.

Эзләнүләрнең чиге юк. Эзләнүләрдә шагыйрьнең газаплары да, бәхете дә. Эзләнергә тормыш үзе куша. Тормыш гаҗәп киң, катлаулы, тирән. Язучы өчен аның материалы һичкайчан да бетәсе түгел.

Бирем

Шигырь туу өчен, әдип язган кирәкле шартларны санап чыгыгыз.

Көз

Көз. Яфраклар коела урманда.
Нәрсәдер бар бүген, күр анда.

Нинди әмер кинәт кубарга:
Очлы таяк тотып кулларга.

Нишләп йөри икән минерлар —
Вәсиләләр белән Мөнирләр?

Карый алар, карый һәр төпне,
Чистарталар гүя Харьковны.

Эзли-эзли эчкә керәләр,
Бу минерлар нигә көләләр?

Җылы матур булса көн әгәр,
Тәртеп чыга тора гөмбәләр.

Иртәгә дә әле килерләр,
Йөри бирсен мондый минерлар.

1964 ел

Шигырьгә анализ

Шигырьдә автор әйткән өч теманың икесе бар.

Лирик жанр үзенчәлеген искә төшерәбез. Лирик жанрга кергән шигырьләрнең эчтәлеге — хис, ә хис эчтәлеген аның сәбәбеннән белеп була, дип өйрәндек.

Шигырьнең беренче өлешендә лирик герой урманда йөри. Таяклары белән үлән актарып, көлә-көлә, гөмбә эзләүче яшьләргә очрап сискәнеп китә. Кылт итеп сугыш елларындагы минерлар күз алдына килә. Алар да шулай таяклары белән җирне капшап йөриләр иде бит. Хәтердә сугыш еллары вакыйгалары белән бергә алар тудырган хис тә саклана. Алар да күңел түрендә. Шигырьнең беренче өлешен таптык. Аңа «Хәтер» дип исем бирә алабыз.

Икенче өлештә автор яңа гына туган шатлык хисе турында яза. Автор өчен яңа туган шатлык хисенең сәбәбе — тыныч тормыш. Сибгат Хәким, яшьләрнең шат йөзләрен күреп, үзе дә шатлана. Шуңа күрә икенче өлешкә «Шатлык» дип исем бирик.

Ә хәзер беренче өлеш белән икенчесе арасындагы бәйләнешне табыйк. Бәйләнеш вакыйгалар охшашлыгында: шагыйрь гөмбә эзләүче яшьләрне сугыш елларында мина эзләүчеләргә охшата. Бу охшаш вакыйгалар бер үк вакытта ике капма-каршы хис — сагыш һәм шатлык хисләре тууга сәбәп була. Төп бәйләнеш әнә шул каршылыклы хисләрнең кушылуында.

Бирем

Шигырь көз турында түгел. Башка исем уйлап табыгыз.

Давыл чәчәкләре

Печән җиткән, мин болында йөрим,
Тугайларга күңелем табынды.
Озын сары давыл чәчәкләре
Күтәп утыра кебек давылны.

Җир өстеннән күпме давыл узды,
Бөтерелде күпме өермә...
Утыра шомлы давыл чәчәкләре,
Куркам никтер якын килергә...

Кыңгыраулар, сары кыңгыраулар
Сизәрләр дә давыл кубарын,
Хәбәр салып уятырлар төсле
Бу тынгысыз җирнең улларын.

Юк, купмасын иде кабат сугыш...
Кыңгыраулар нигә кагарга!
Халык җыена, ничәнче кат җыена
Чын-чынлап бер яшәп карарга.

1959 ел

Биремнәр

1. Шигырьнең эчтәлеген аңлатыгыз.
2. Шигырьнең «Көз» шигыре белән уртак якларын һәм аермасын әйтегез.

Бу кырлар, бу үзәннәрдә

Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Эзләрем бик иртә салынган.
Кайтам, кайтам туган якларыма,
Талларыма хәтле сагынган.

Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Мәхәббәтем яшьләй кабынган.
Кайтам, кайтам туган якларыма,
Тауларыма хәтле сагынган.

Бу кырлар, бу үзәннәрдән минем
Күңелем, дуслар, һич тә туймаган.
Арыш шаулап серкә очырганда,
Хисләрем дә бергә уйнаган.

Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Үзем генә белгән җырлар бар...
Кайтам, кайтам туган якларыма,
Ашкындырып көткән юллар бар.

1953 ел

Биремнәр һәм сорау

1. Шигырьдә автор ничек катнаша?

2. Беренче строфаны үз сүзләребез белән болай әйтеп була:

«Мин балачактан ук табигатьне бик яраттым. Ялгызым кырлардан, үзәннәрдән әйләнеп кайта идем.

Таныш талларымны шулкадәр сагындым, кайтып күрми түзәр хәлем калмады».

Икенче строфаның эчтәлеген үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз.

Мөстәкыйль эш

Фазыл чишмәсе

Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем;
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.
Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән?
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән...

Кызарып янган шәфәкътән
Күзләрем алалмадым;
Тибрәнде телем, әйтергә
Сүзләрем табалмадым.
Инешкә төшкән сукмакның
Читләре үлән генә;
Вәгъдәм бар сиңа, белмәсен
Тик күрше-күлән генә.

1947 ел

Биремнәр һәм сорау

1. Шигырьнең төзелеше мәхәббәт хисе белән оялу хисе каршылыгыннан гыйбарәт. Бу хисләр ничек каршылыкка керәләр? Аңлатыгыз.
2. Суга дип килгән кызга бәя бирегез.
3. Шигырь эчтәлеген әйтегез.

Йомгак ясыйк

1. Сибгат Хәким шигырьләрендә иң күп кабатланган темалар өчәү: сугыш, ил язмышы һәм мәхәббәт.

2. Темаларның өчесе дә бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора: әдип, сугыш дәһшәтен үз башыннан кичергән кеше буларак, ил иминлеге өчен борчыла. Ә мәхәббәт кешене ил имин булганда гына бәхетле итә ала, ди.

3. Темаларның шул рәвешле бер-берсенә бәйләнеше Сибгат Хәким шигырьләренең эчтәлегенә дә тәэсир итә. Бер моң булып кушылган катлаулы хис шигырьләрне үзара бәйләп, бербөтен иҗат җимешләре итеп җыеп тора.

Әсәрләрендәге шундый уртак сыйфатларга **Сибгат Хәким иҗатының үзенчәлеге** дибез.



Шәехзадә Бабич
(1895 — 1919)

Шәехзадә Бабичка ниндидер бер явыз көпә-көндез, сизмәгәндә һөҗүм итә. Башкорт һәм татар халкының яраткан шагыйре егерме дүрт яшендә һәлак була. Кыска гына гомере эчендә шагыйрь кояшлы тыныч көннәрне күрми дә кала. Рус-япон сугышы үтүгә, 1905 елгы революция, аннан соң реакция еллары дип йөртелгән хокуксызлык, мәсхәрә еллары. Бөтендөнья сугышы; берсе артыннан берсе килгән ике революция, аннан соң гражданнар сугышы... Аның бөтен яшьлеге сугышлар, җимерүләр, бәхәсләр, талашлар эченнән чыга алмый өзелә. Бу сугышлар халыкны тәмам бөлгенлеккә төшерә, халыктан зур корбаннар сорый. Бабичның сизгер йөрәге кешеләр хәсрәтен, мескенлеген, кимсенүен авыр кичерә.

Ниһаять, бу буталчык, тынгысыз вакыйгалардан котылабыз икән дип, ул 1917 елгы революцияне хуплап каршы ала. Октябрь революциясе җиңгәч, аны да алкышлый. Башкортлар арасында милли азатлык яулау өчен көрәш башлангач, анда да катнаша. Ләкин бу сугыш-көрәшләрнең халык бәхетсезлеген арттыра гына баруын күргәч, болай дип яза:

> Яшь сабыйкай, яшь сабый, син үсмә, кал, шул хәлчә кал!
> Үсмә, дөнья бәхтенә кал, саф йөрәк, пакь җанча кал!

Шәехзадә Бабич 1895 елның 2 гыйнварында Башкортстан Республикасының Дүртөйле районы Әсән авылында туа. Аның әтисе Мөхәмммәтзакир шул авылның мулласы була. Авылдашлары аны эшчәнлеге, тугрылыгы һәм гаделлеге өчен яраталар. Ул, башкалар кебек, иген үстерә, мал асрый, шәһәр кешесе кебек, сабын кайната. Белемле кеше була аның әтисе.

Күп итеп китап җыя. Газета-журналлар яздыра. Улын эш һәм китап яратырга өйрәтә. Татар язучыларының иҗаты белән шагыйрь әтисе алып кайткан китаплар аша таныша.

Шәехзадәнең әнисе Бибисаҗидәбану җыр, моң ярата. Бабич хыялга, моңга әнисеннән өйрәнә.

13 яшендә авыл мәдрәсәсендә мөгаллим-хәлфә булып шәкертләргә белем бирерлек укымышлы малай була. 15 яшендә казакъ далаларында шәкертләр укыта. 16 яшендә Уфага кайтып, заманы өчен алдынгы булган «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Мәдрәсәдә танылган татар язучысы Галимҗан Ибраһимов та укыта. Бабичның иҗаты камилләшүенә аның ярдәме зур була.

Монда Шәехзадә үзлегеннән халык иҗатын тырышып өйрәнә. 16 яшендә шигырьләр китабы басылып чыга. 18 яшендә башкорт һәм татар халкының күренекле шагыйре булып танылла.

Шәехзадә Бабич үзенә өй салырга да, гаилә корырга да өлгерә алмый кала. Ләкин берсеннән-берсе күркәмрәк шигырьләр язып калдыра. Күңел дөньясының чиксез моңын, сагышын, мәхәббәтен сыйдырырлык сурәтләр, сүзләр, рифмалар, ритмнар таба.

Ул үзенең иҗаты белән татар, башкорт халкының күңелен баетты, аларның милли горурлыгына әйләнде.

Әсәрләренең уртак эчтәлеген әдип бик матур образ аша гомумиләштереп, «Шатлык җыры» исемле шигырендә менә болай язган:

Чайпалышып, шатлык дулкыннары
Чәп-чеп бәрелә күңлем ярына;
Шул шатлыклар белән каршы торам
Бу дөньяның барлык зарына.

1916 ел

Шагыйрьнең кыска гына шигырен, тормыш авырлыклары һәм күңел тулы шатлык хисе дип, ике өлешкә бүлик. Алар арасындагы бәйләнеш тиз табыла. Ул — каршылык. Шагыйрь авыр тормыштан канәгатьсезлек хисен күңелендәге шатлык хисләре белән җиңәргә тырыша. Күңелендәге шатлык белән хәсрәт көрәше шагыйрьнең даими рухи халәте дип исәпли алабыз. «Шатлык җыры» шигырендә автор үзе шулай дигән.

Лирик шигырьләрдә авторның рухи халәте чагылуын сез инде беләсез. Димәк, шагыйрьнең күпчелек шигырьләрендә

тормыш тудырган авыр хисләр һәм ул хисләрне сүндереп торучы шатлык хисләре арасында булган каршылык табылырга тиеш. Шушы каршылыкны тапсак, Шәехзадә Бабич иҗатының үзенчәлеген тапкан булабыз.

Хәзер шагыйрьнең башка әсәрләре белән танышып, аларның охшаш сыйфатларын эзлик.

Дөньяга

Әй дөнья, шашма,
Юкны алдашма;
Синең хәлеңә
Мин бит бик ашна[1].
Беләм: син ялган,
Белеп алданам!

Үз маягымны
Үземчә кадап,
Үз сабагымны
Үземчә аңлап,
Юллар ясармын,
Шулай яшәрмен!

Күкләр очармын,
Йолдыз үбәрмен!
Диңгез кичәрмен!!
Теләсә нишләрмен!!! —
Мин — ирек ханы,
Ханы-солтаны!

1915 ел

Бирем

«Дөньяга» һәм «Шатлык җыры» шигырьләренең охшашлыгын табу кыен түгел. Охшашлыкны табып исбат итегез.

Бәхетсез мин

Көн саен миндә бәхетсезлек кенә арта бара,
Җайсыз, уңайсыз, кырыйсыз юлына тарта бара.
Мин, шулай уйлана торгач, татлы уйларга күчәм,
Төрле хыялларга батып, гарше әгъләгә[2] очам.

Бирем

1. Бу шигырьдә дә әдип хәсрәтенә каршы шатлыгы белән көрәшүе турында яза. Исбат итегез.

---

[1] Ашна — таныш.
[2] Гарше әгъләгә — биеккә, күккә.

Хәсрәт сагызы

Шат вә шаркылдап көләлмим, көлкене куйган авыз;
Һәр авызда, белсәгез, гамьнән[1] ясалган бер сагыз.

Һәркайчан телдә «Сугыш! Ачлык!» сүзе әйләндисә
Һәм авызыңда сагыз урынында чәйнәлдисә —

Шаккатасың, дәһшәтеннән күз тона һәм сүз бетә,
Күкрәгеңне бер ягын ут, бер ягын тоз әрнетә.

Кышкы юл

Их, рәхәт, шуа чана, юырта ат талгын гына,
Як-ягымда киң ялан йоклап ята тып-тын гына.

Алдымда ак кар җәелгән ялтырап, ап-ак булып,
Энҗе-мәрҗәннәр чәчелгән өстенә вак-вак булып.

Юл читендә кар кисәкләре торалар тезелешеп,
Барсы да иелеп калалар: «Хуш, исән бул!»— диешеп.

Ак кояш нур җепләрен сузган да җиргә нур сибә,
Нурлы җепләрдән агып, моңлы күңелгә җыр килә.

Җырлый башлыйм... Шунда салкын җил исеп, җырны кисә,
Әй усал җил! Кырдагы бар ямьне, бар моңны кисә.

Биремнәр

1. «Кышкы юл» шигырен ятлап килегез.
2. «Хәсрәт сагызы» һәм «Кышкы юл» шигырьләрендә дә тормыш авырлыгына каршы көрәшүче шатлык хисе бар. Шуны исбат итегез.

Мөстәкыйль эш

Язгы җыр

Утырдым мин тауның күкрәгенә;
Җырлар язам, җилкәй, исми тор!
Чишмәкәй! Тын! Әкрен!.. Чү! Шаулама!
Үткән гомерем, искә төшми тор!

Челтерәп аккан чишмә буйларында,
Аһ, мин йөрдем былтыр кем белән?

---

[1] Гамьнән — кайгыдан.

Шул чакларны, чишмә, алып актың...
Калдым сыкрап авыр моң беләнǃ..

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Зинһар димен, җилкәй, исми торǃ
Йомыл, гөлкәй, йомыл бер минутка —
Минем күзләремә төшми торǃ

Аһ, чәчәкләр, былтыр сезне өзеп,
Кемнең күкрәгенә кададым,
Кемгә кадап, кемгә моңлы карап,
Күзләреннән җавап арадым[1]?

Ни диде ул күзләр? Әй чәчәкләр,
Күрдегезме серле күзләрен?
Кем иде ул, тетрәп хозурында,
Ак кулларын сорап тезләндем?..

Җырлар язам тауның күкрәгендә;
Кодрәтле җилǃ Әкрен, исми торǃ
Сандугачкайǃ Назлым, куй, сайрамаǃ
Сайрап, яшь бәгырьне кисми торǃ

Котлы булсын айлы төннәр диеп,
Син бит безне котлап сайрадың;
Син бит шунда, сикереп ботак саен,
Кунар өчен урын сайладың.

Син идең бит аның күкрәк серен,
Сайрап-сайрап, миңа белдергән;
Ул кайнаткан минем күкрәк җырын,
Сайрап-сайрап, айга мендергән...

Тыңлагызчы, кошлар, җырларымны,
Тыңласагыз, сезгә җырлармынǃ
Сез сайрарсыз, соңра мин тыңлармын,
Тыңлап, үксеп-үксеп егълармынǃ..

Бирем

Лирик герой бүгенге чынлык тудырган хәсрәтен хәтерендәге шатлык белән җиңәргә омтыла. Шуны исбат итегез.

[1] Арадым — көттем.

Шәриф Камал

(1884—1942)

Шәриф Камал (Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев) 1884 елның 27 февралендә хәзерге Мордва Республикасы Рузаевка районы Пешлә авылында хәлле генә гаиләдә туган. Әтисе мулла булган. Үз авылындагы мәдрәсәдә укыган. Күрше авылдагы мәдрәсәдә дә дүрт ел буена белем алган. 16 яше тулгач, үз тормышын үзе күрергә дип, авылларыннан чыгып киткән. Булачак язучы, мәдрәсәдә укыганда ук, тимер юл эшендә эшли башлый. Шәлче сәүдәгәрләргә кибетче булып яллана. Алар белән илнең төрле шәһәрләренә, авылларына барып чыга.

Укырга ниятләп, Рига шәһәренә китә. Төркиягә, Мисырга бара. Соңгысында елдан артык укыганнан соң, Россиягә кайтып күмер шахталарында — шахтер, Каспий диңгезендә — балыкчы, Петербургта — укытучы, Оренбургта газета хезмәткәре булып эшли. Туган авылы Пешләгә кайтып дүрт ел балалар укыта.

1910 елда Оренбургка килә. Газета-журнал редакцияләрендә эшләвен дәвам итә. Эштән соң әсәрләр яза.

1925 елда Казанга кайта. Казанда да журналист вазифасын башкара.

Сугышка кадәр әдибебез күп санлы хикәяләр, повестьлар, романнар, драма әсәрләре авторы булып танылa. Татар әдәбиятына керткән зур хезмәте өчен 1940 елда Шәриф Камал Ленин ордены белән бүләкләнә.

Яше өлкән булу сәбәпле, Бөек Ватан сугышы елларында әдип җиңүгә үз өлешен әдәби осталыгы белән генә кертә ала. Ул шулай итә дә. Яза башлаган күләмле әсәрен читкә куеп, сугыш темасына мәкалә артыннан мәкалә яза. Сугыш

елларына багышлаган пьеса да яза башлый. Ләкин тәмамларга өлгерми — 1942 елның декабрь аенда кинәт дөнья куя.

Шәриф Камал җыелышларда сүз алып сөйләргә яратмаган. Күп кеше белән дә аралашмаган. Үзе турында да язарга базмаган. Ләкин язучы холкы турында аны күреп белгән, иҗатын җентекләп өйрәнгән галимнәр хезмәтеннән укып белә алабыз.

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гали Халит болай яза:

«Атасы Камалетдин бик иске карашлы һәм каты күңелле кеше булган. Шәрифнең анасы Зөләйха абыстай исә нечкә күңеллелеге, самимилеге белән аерылып торган. Ш. Камал ата-анасы арасындагы әнә шундый рухи каршылыкны бик кечкенәдән үк сизенә башлаган һәм үскән саен авыррак кичергән. Атаның тупаслыгы һәм ананың ягымлылыгы, кешелеклелеге һәм күркәм сурәте аның күңел түрендә капма-каршы характерлар булып урын алганнар. Язучы булып киткәч, Ш. Камал үзенең әсәрләрендә дә шундый характерларны күз алдына бастырды».

Күрдегезме, күренекле галим әдипнең холкыннан чыгып, иҗатының үзенчәлеген әйтте.

Әдип холкына үзебездән тагын бер сыйфат өсти алабыз. Егет чагында Шәриф Камалның бармаган урыны, күрмәгән җире, эшләмәгән эше, өйрәнмәгән һөнәре калмаган... Югыйсә хәлле генә гаилә баласы бит ул. Димәк, тынгысыз холыклы егет булган.

Без быел язучының Октябрь революциясенә кадәрге чорда иҗат иткән әсәрләрен өйрәнәбез.

Шәриф Камал — «Таң атканда», «Матур туганда» романнары, «Акчарлаклар» повесте, «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Таулар», «Томан артында» пьесалары һәм күп санлы хикәяләр, мәкаләләр авторы.

Әүвәл-әүвәл заманда

(Хикәя)

Алар, чатыр[1] эченә сыенып, яңгыр туктаганны көтә иделәр. Көймәче карт, үзенең ак вә озын кашлары астыннан юлчыларга күз салгалап, имән бармагы белән тәрәпкәсенең көлләрен өстән әзрәк бастыра вә төзәткәли торып сөйләнә,

[1] Чатыр — яңгырдан, җилдән ышыклану урыны.

сораштыргалый иде. Юлчылар озайтмыйча гына җаваплана һәм үзләре дә карттан тирә-як вә юллар турында сораша иделәр. Алар эшчеләр: имеш, файдалырак эш эзләп йөриләр...

Алар икәү иделәр. Берсе — озынча буйлы, сирәк сакаллы, урта яшьле ябык бер кеше, икенчесе егерме яшьләрендә, таза гына гәүдәле бер егет иде. Көймәче карт күбрәк аңарга карап сөйли иде.

— Хәзер инде, энем, ул бәхет дигән нәрсәне эзләп маташырга да ярамый: ул инде юк,— диде көймәче.

Егет, бу сүзгә гаҗәпләнгән төслерәк, картның күзенә карады.

— Аның югалганына күп заманнар, күп еллар инде! Менә синең кебек егетләр борынрак заманда ук эзләп маташканнар икән дә, булмаган... Ничек, дисең. Менә алай булса, мин сиңа аның хикәясен сөйлим.

«Әүвәл-әүвәл заманда, ди, Бохараи шәрифтә булган бер егет. Бер әби карчык анасы булган да япа-ялгыз берүзе. Анасы бик картайган. Яткан инде үләргә.

— Балам,— дигән,— мин инде үләм, бәхил бул. Син яшь кеше, каласың дөнья көтәргә. Зинһар, тик ятма, бәхетеңне эзлә.

Карчык, әлбәттә, үлә. Егет нишләсен — бер көн елый, ике көн елый, дигәндә, бервакыт анасының васыяте исенә төшә... Китә бәхет эзләргә. Ул кешедән сорый, бу кешедән сорый — юк! Берәүдән дә юньле-башлы җавап ала алмый... Бервакыт тәмам инде тәкатьтән язгач, берәү әйтә моңар: бар, ди, фәлән җирдә, фәлән урманның артында тау тишегендә бер дәрвиш булыр; туп-туры аңарга бар, ул ни әйтер сиңа...

Егет дәрвишне таба вә елап-елап ялвара: «Ышанычым синдә генә,— ди,— табып бир бәхетемне!»

— Һммм...— дип әйтте ди дәрвиш.— Анаңның әйткәнен ялгышрак аңлагансың икән... Шулай да зарар юк; син эзли торган нәрсә дөньяда бар ул. Минем азрак чыгып йөрисем дә бар иде. Әйдә, алай булса минем белән, табып бирим мин сиңа аны.

Болар «йа Алла» диләр дә чыгып китәләр. Шулай итеп барганнар, барганнар, көн барганнар, төн барганнар, ай барганнар, ел барганнар. ...Берничә вакыттан соң болар «Кодес» шәһәренә килеп җитәләр...

— Менә,— дәрвиш әйтә, ди,— җиттек... Әнә теге зур мәчетне күрәмсең, төн уртасында бервакытны адәмнәр авыр йокыга

талгач, җен вә пәриләрнең аксөякләре шул мәчеткә җыелалар: безгә шул җен таифәсе[1] белән эш кылырга туры килер,— ди...

...Кич белән ястү намазыннан соң җәмәгать чыгып таралганда, болар мәчетнең караңгы бер почмагында яшеренеп калалар, ишекләр дә шалтырап бикләнә...

Шул көе торганда, бервакыт, умарта шаулаган төсле, йомшак бер шавылты кузгала... төтен кебек, аксыл күләгәләр күренә башлый... Күләгәләр һаман ешлана... Берзаман... дивардан бер тартма кебек нәрсә ачыла да, бөтен мәчет эче кинәт яктырып китеп, дәрвиш белән егетнең бераз вакыт күзләре камашып тора... Дәрвиш, яшеренгән җиреннән чыга да кычкырып:

— Әй мөхтәрәм таифәи җен! Сөләйман пигамбәр йөзеге хөрмәтенә миңа юл бирүегезне үтенәм,— ди. Вә туп-туры алга барып, тартмадан йөзекне ала. Ул йөзекне алганда, үткен бер сызгыру тавышы белән нечкә генә каһкаһәләп[2] көлү тавышлары ишетелә!.. Мәчет янә тып-тын булып кала. Болар да чыгып китәләр...

Дәрвиш егеткә әйтә:

— Менә,— ди,— инде бу — бәхет йөзеге, кашына язылган олы исемне генә укыйсы — һәммә теләгең була!— ди.

Бервакыт таң яктыру белән, дәрвиш куеныннан йөзекне чыгара да, яктыга тотып, йөзек кашындагы язуны укымакчы була.

Ни күзе белән күрсен, каштан җилләр исә, фәкать урыны гына калган! Ул бик тирән бер аһ итеп ала да:

— Менә,— ди,— ул каһкаһәләр бушка булмаган икән. Шунда ук эчем курыккан иде... кашны урлаганнар, мәлгуньнәр! — ди.

Көймәче, сүзеннән туктап, авызына тәрепкәсен алган иде, юлчылар икесе бердән:

— Соң?— диделәр.

— Соң шул инде,— диде көймәче,— дәрвиш, кашсыз йөзекне ачуыннан бәреп ыргытып җибәргәч, теге егет һәм сезнең шикелле: «Соң, инде нишлибез?..» — дигән.

— Булмады инде,— дип әйтте, ди, дәрвиш,— хәзер үз-үзеңә генә ышанырга калды. Шулай итеп, кире үз ватаннарына,

---

[1] **Таифә** — төркем.
[2] **Каһкаһәләп** — мәсхәрәләп.

Бохарага кайтып киттеләр, ди, шул...» Ә менә яңгыр да туктады икән, әйдәгез инде, күчерим мин сезне.

Алар чатырдан чыктылар. Көймә бәйләгән җирендә әкрен генә чайкалып тора, су буендагы камышлар, яфраклар да яңгыр артыннан яшәргән, тазаланган, матур гына тирбәлеп тора иделәр.

Көймәче бу кешеләрне суның аръягына күчергәч тә, куллары белән күрсәтеп, юллар тәгъриф итә[1] иде... Тагын килгән юлчыларның берсе, бу яктан каты тавыш белән кычкырып:

— Йә! Ни анда әкият сөйләргә тотындың?! — диде.

1910 ел

Биремнәр

1. Хикәягә анализ ясагыз: ике өлешкә бүлегез. Өлешләрне берәмберәм җентекләп өйрәнегез. Ике өлеш арасындагы бәйләнешне табыгыз.
2. Соңгы абзацта яңа юлчылар көймәчене «әкият сөйлисең» дип гаеплиләр. «Әкият сөйлисең» сүзләренә автор нинди мәгънә салырга мөмкин?

Акчарлаклар

(Повесть)

Диңгез көлә

Җәй башы иде. Каспий диңгезе буендагы балык промыслоларында елдагы рәвешчә хәрәкәт башланган; «сельдь» тотарга хәзерләнәләр...

Һәр көн иртә-кич тимер юл станцияләреннән төркем-төркем дә, берәм-сәрәм дә эшче халык диңгез буена тарала һәм промыслоларга урнаша торалар иде.

Мартның калган атнасы, чалт аяз һәм салкынчарак бер көн иде...

Эшчеләр баракка җыелгач, десятник Исак үзе белән ике кеше ияртеп керде дә:

— Менә монда сезнең земляклар да бар. Теләсәгез, алар белән бергә эшләргә мөмкин булыр,— диде һәм, мондагыларга карап, эш турысында сөйләп китте...

Бу шулай сөйләп торган арада, сары мыеклы бер эшче, яңа килгәннәрнең берсенә төбәп, шатланган тавыш белән:

---

[1] Тәгъфир итә — аңлата.

— Әй, синме бу? Кайдан болай? Таныр хәл дә юк,— диде дә, нык кына кул кысышып, алар белән күреште.

Аның исеме Хөснетдин иде, тик аны монда Солдат дип кенә йөртә иделәр...

Чын да ул ике-өч ел гына элек солдатта булган икән. Ул, яңа килгән егетләрнең сумкаларын алып, сәкегә үз урыны янына урынлаштыргач, аларны мондагы иптәшләренә дә таныткан булды:

— Болар минем настоящий дус кешеләр... Әлеге, таза дип, мактап сөйләгән идем ич сезгә, Гариф исемле егет менә шушы егет инде ул! Сигезәр потлы капчыкларны уйнатып ала торган егет,— диде.

Солдат шулай дигәч, төрле яктан бу егеткә берничә күз төште, гүя сокланып карый иделәр.

Ул карарга да таза күренә, өсте-башы да иптәшенекеннән шомарак иде. Аның шактый эре башында арзанлы, бәйләнгән бүрек белән өстендәге иске генә кышлык пальто да никтер килешле күренә иде.

Солдат аларның кайларда йөреп, кайдан монда килеп чыкканнарын сораша башлады...

Алар көзен Солдат белән аерылышкач, Дербендка килгәннәр. Дербендта бераз вакыт пристаньда эшләп, соңыннан Бакуга килгәннәр. Анда кыш буе нефтьтә эшләп, инде менә «балыкка» чыкканнар икән...

Ул сөйләгәндә, башкалар күңел куеп тыңлый, аның авызына карап тора иделәр. Ул үзе дә, тәмам үзсенгән рәвештә, янындагы кешеләргә һәм баракның буена сузылган сәкегә күз йөртә иде. Үзенерлек тә бар шул: менә алама-шалама сөйкемле генә егетләр — һәммәсе дә үз кешеләр, әнә сәкедә түшәлгән җыйнак кына, риясыз гына аларның урыннары...

Алар сөйләшеп торган арада, аш килде. Буланып торган бәрәңге өйрәсен яңа килгән егетләр дә яратып ашадылар...

Шул арада ишектән дәү генә бер кеше килеп керде. Аның башында йончылган кара эшләпә, өстендә кыска гына иске соры чикмән, чикмәннең алгы чабулары ике якка ачылып киткән; күксел-кара күлмәгенең изүеннән йонлы күкрәге күренеп тора иде. Буе уртачадан озын булмас, тик иңбаш араларының киңлеге, кулбаш әгъзаларының эрелеге аны шактый дәү күрсәтә иделәр.

Ул, яңа килгәннәрне күрмәгәнгә салышып, илтифатсыз гына:

— Солдат, шашкы уйныйбызмы? — диде. Солдат, гафу үтенгән сымак:

— Бик арыган идем шул, Шәрәфи абзый. Менә иптәшләрне дә сагынылган, серләшәбез әле үзләре белән...— диде. Шәрәфи карт, боларны яңа күргән булып:

— Ә, якташлар, кайсы губерна? Ә өяз кайсы? Бәләбәй диген... Бәләбәйдән минем бер дус кеше бар иде. Хәер, мин үзем мишәр, Красный-Слабудский өяз...

Сафа моның сүзен бүлде:

— Шәрәфи абзый, сүзеңне оныттырмыйм, Красный-Слабудка өязендә бер генә дә юньле кеше юк, диләр бит, һәммәсе дә ат караклары, ди!

Шәрәфи карт, аңар җавап бирмичә, сүзендә дәвам итеп:

— Хәер, авылныкы булгач, сез аны белмәссез, бик һәйбәт кеше иде,— Сафаны күрсәтеп,— әнә шундый агач авызларга күп лыгырдарга бирмидер иде ул, чалт иттереп авызга куя да җибәрә, чүплә инде аннан соң тешләреңне идән буеннан... Атаң белән тиңдәш кешене мыскылламассың икенчедән,— диде.

Сафа, оятлы булган кебегрәк:

— Юк, Шәрәфи абзый, мин бит тегеләй генә, мыскылларга Ходай сакласын...— дип, сүзне шаяруга сабыштырды. Шул арада Солдат, Гарифны күрсәтеп:

— Менә бу егет монда калса, мин инде шашканы икегезгә тапшырам, Шәрәфи абзый. Бу кеше, баксаң, сиңа да нужник биргәләр,— диде...

Монда, эштән туктаган арада, еш кына шашка уйнап маташа иделәр, әмма картка каршы уйнаучы юк иде. Шәрәфи карт:

— Ярый, хушыгыз... Кайтып йоклап карыйк...— диде һәм салмак кына хәрәкәт белән ишеккә таба юнәлде.

Ул яланаякка арты басылган чүәкләр генә элэктергән, ялангач аяк үкчәләре арттан әллә нишләп бик килешсез һәм дә күңел өшеткеч булып күренә иделәр.

Ул чыккач, Солдат яңа килгән иптәшләренә аның кемлеге... турында сөйләде; ул монда солильщик (сельдь тозлаучы) икән.

Сүз мондагы эш җаена күчте. Солдат та, башка иптәшләре дә яңа килгән егетләрне мондагы эшкә кызыктыра һәм үзләре белән калырга димли иделәр.

Эш кызыгырлык иде шул! Алар болай простой айлыкчы булып түгел, «сдельный» керешкәннәр бит...

Шәрәфи агайның тәҗрибәсе буенча, суның җылылыгына, акчарлакларның хәзердән үк чит буйларда очынып йөрүләренә караганда, быел да балык күп булырга чамасы юк түгел, имеш...

Кайсыберләре хырылдап йокыга да киттеләр. Сөйләп торганнарының да тавышларында инде йокы көе ишетелә иде.

Тышта ай яктысы, йомшак кына салкын җил исә иде. Ерак-еракларга җәелеп киткән газәмәтле диңгез ай яктысында аклы-күкле ялтырап, очсыз-кырыйсыз нур һәм серле күләгәләр эчендә гүя күңелсез генә көлемсерәп ята иде... Аның кырыенда адәм балалары күбрәк балык тотып, аена кырыгар сум акча эшләү өмете белән, һәм дә әллә кайларда, зиннәтле бүлмәләрдә йомшак түшәкләр өстендә сузылып яткан промысло хуҗалары шул ук балык хисабына кырыгар мең сум төшерү хыялы белән ләззәтләнеп төш күрә-күрә йоклаган чагында, табигатьнең матур һәм аңгыра мәхлуклары — балыклар һичнәрсәдән хәбәрсез, бертуктамый айга каршы сикерә, уйный иделәр...

Калдылар

Иртә белән көн томанлы иде. Кичә килгән ике егет белән Солдат конторага киттеләр. Солдат ике иптәше белән барактан чыккач та, тонык кына шакылдаган тавыш ишетелә иде — Шәрәфи карт нәрсәдер юнып ясап маташа иде. Аның турысына җиткәч, Солдат:

— Алла куәт бирсен, Шәрәфи абзый,— диде.

— Шулай, без картларга ансыз ярамый. Канторгамыни киттегез? Кайтканда якташларны чәйгә алып кер, хәзер әбинең самовары кайный...— диде дә, балта тоткан учына төкереп, тагын эшенә тотынды.

Кызы чибәр генә

Алар конторадан чыкканда, томан сыекланган һәм дә диңгез ягыннан аксыл томан аркылы тонык кына нур чәчеп торган кояш шактый югары күтәрелгән иде... Һава кичәгегә караганда шәп иде. Сыек кына томан белән өртүле диңгез өстендә очынып йөргән акчарлакларның гыйгылдап көлгән шикелле үткен һәм күңелне кытыкландыра торган тавышлары диңгез өстендә асылынып торган әллә нинди тылсымлы сарайлардан ишетелгән шатлык шаркылдауларына охшый иделәр.

Бу өч иптәшнең рухлары шактый күтәренке иде...

Гариф, Солдатның иңбашына кулын салып:

— Әй, картка нишлибез, кирәбезме? Чәйгә чакырган иде ич,— диде. Солдатның авызы ерылды, күзләре көлә иде... Ул Гарифны иңбашыннан этеп җибәрде дә:

— Газизәгә күзең төшмәсен, дим, кяфер! — диде.

Кечкенә казарма алдында Шәрәфи карт үзе юк иде... Болар казарма ишегалдында туктадылар.

— Шәрәфи абзый өйдәме?— дип, Солдат кычкырган иде, озакламый ук ишек ачылып, ишек арасында мөлаем гына бер кыз күренде:

— Ул хәзер генә лабазга дип чыккан иде... Әйдә, керегез, Хөснетдин абзый... Ул хәзер кайтам дип әйткән иде... Сезгә керергә кушты...

Гариф күңеленнән: «Шул була инде, күрәсең, Газизә...» — дип уйлап алды. Үзенчә исе китмәгән гади һәм гөнаһсыз рәвештә тегеңәр күз төшергәли иде. Ул төс-баш күренеше белән шәһәрләрдәге урта сыйныфтан түбәнрәк татар гаиләсендәге бер кыз иде; өстендә тубыктан югарырак торган иске генә аксыл ситсы күлмәк, аягында да каюлы һәм искерәк кенә кызыл читек белән ялтыравы беткән сары резинка галошлар иде. Аның аз гына кызгылт ак йөзе, кош борынына охшаулырак килешле борыны, уйчан кара күзләре дә бер караштa гади генә күренәләр. Нәфис гөл чәчәге кебек иреннәре гадәттән тыш матур иде. «Калфак кисә, тагын да шәп буласы икән...» — дип, Гарифның күңеленә килде.

Алар берничә минут керергәме-кермәскәме дип икеләнеп торгач, картның үзе белән бергә килергә булып, керми киттеләр.

Лабазга җиткәндә, Солдат, Гарифның янтыгына төртеп:

— Ну, ничек? — диде.

— Нәрсә ничек?

— Газизә?

— Ә... Газизә зарарсыз. Чибәр генә...

Булыр әле

Башлап беренче мәртәбә невод салган көн, иртәдән үк промыслода гадәттән тыш хәрәкәт, кайнашу башланды.

Гариф белән Солдат һәм дә Гарифның иптәше Муса — өчәү бергә чыктылар... Лабазның аръягы буеннан ялпакланып киткән комлыкта диңгез читенә якын ук неводчы

казаклар җыелган иде. Аларның кайсылары җылынырга өчен шаярып сугыша, кайсы көрәшә, кайсылары йөгерешеп куыша иделәр. Тик кенә торып, невод салырга киткән көймәне карап торучылар да бар иде... Көймә читтән бер чакрым чамасы эчтә булганлыктан, андагы кешеләрнең нишләгәнлекләре аермачык күренми, тик анда биш-алты кешенең кырмыскалар көбек хәрәкәтләнеп, казынып торганлыклары гына күренә иде.

Гарифның промыслода эшләгәне юк иде... мондагы эшләр аңа шактый сәер тоела иде. Менә инде лабазда аның гаҗәпләнеп караган һәм кечкенәрәк авылны чорнап алырлык дип уйлаганы — биш йөз саженьлык неводны көймәдәге кырмыскалар диңгезгә ыргыта киләләр... Солдат бер дә исе китми генә карап уйга калган төслерәк тора иде.

Гариф аңар:

— Бер очы кайда соң? Ике яклап тартыргадыр бит? — диде.

— Ә... неводны әйтәсең? Әнә тегендә барак турында казык!.. Шуңар аркан бәйләп китәләр, бире, казарма турысына урап чыгалар...

Көймә инде әкренләп кырыйга якынлаша иде. Инде ачык күренә. Ике кеше ишеп килә, өчәү невод ыргыталар, бер кеше, югары койрыкта торып, көймәне турылап килә иде.

Казаклар[1] шаярудан туктадылар, лямкаларын иңбашы аркылы киеп, төзәтенә-төзәтенә, диңгез ягасына җыелдылар. Дүртәү сөйләшеп торган егетләрне күрү белән, Исак, бик эшчән кыяфәттә алар янына килеп, Гарифка:

— Ну, господин артельщик. Кайда башка иптәшләрегез? Лямкаларыгыз[2] да юк, ах сез, болай ярамый бит!..— диде.

— Әнә киләләр!— диде Солдат.

Чын да тегеләр, барактан чыгып, ашыкмыйча гына бире таба килә иделәр...

Гариф үзенең артельщик булып китүенә аптырый һәм көләсе килә иде. Эш болай булды: бер-ике көн элек Исак аларга үз араларыннан бер кешене артельщик итеп билгеләргә кушкан иде... Үз араларында тәртип карарга бер кеше кирәк,

---

[1] **Казаклар** — элеккеге хәрби өлкәләрдә туып үскән крестьяннар.

[2] **Лямка** — авыр ятьмәләрне кулбашына киеп тарту өчен киң каеш.

имеш... Солдатның Гарифны берничә кат иптәшләренә укымышлылыгы белән мактавы аркасында, бер авыздан аны артельщик итеп сайлаганнар иде... Инде менә бүген иптәшләренә булышлык кылуы да таләп ителә башлагач, ул шактый уңайсызлык хис итте. Мондагы эшнең рәтен белми бит ул, үзеңнән күп белгәннәргә башлык сөр[1], имеш!

Хәйрулла белән Сафа лабаздан лямкалар алып килгәндә көймәдән арканны кырыйга ыргыткан иделәр инде. Тула ыштанлы, күн чабаталы казаклар, кырмыскалар кебек, аркан буена тезелделәр. Безнең егетләр дә арада иделәр... Йолкынган чәүкәләргә охшаган сәләмә бер төркем халык, карасу җепшек ком өстендә борыннары белән җиргә хәтле иелә-иелә, калын бер аркан тарталар... Аркан бик акрын тартыла... Беренче мәртәбә күргән Гарифка бу эш ярыйсы гына ошады, һәм бу халыкның шушы эштә пешеп чыккан кешеләр икәнлегенә ул тәмам канәгатьләнде.

Шулай итеп, байтак вакытлар тарта торгач, невод очы килеп чыкты...

Кырыйга якынлаша торган невод өстендә, көмешле йомычкалар төсле, ак балыклар бертуктамый ялт та йолт сикереп маташалар...

Очы-кырые күренми җәелеп яткан матур диңгез өстендә әллә нихәтле акчарлаклар өермәгә эләккән яфраклар төсле буталып очыналар һәм, акылдан шашкан кешечә, эчләре катып көлгән яисә үчегеп ярсыган шикелле гыйкылдап, йөрәкләрне кытыкландыралар. Әллә алар шушы сәләмә кешеләрнең дә үзләре кебек оча алмауларыннан һәм тамаклары өчен борыннары белән җиргә абынып тырмануларыннан көләләр, әллә болар балыкны бетерәләр дип көнләшә һәм үчегеп елыйлар...

Башлангыч шәп булмады. Шулай да бөтенләй үк буш түгел иде. Биш-алты тачка йомычка балык, сельдь, унбиш-егермеләп биреш, эре генә өч сазан чыкты.

Ике вагонлык чан төбенә егерме, егерме биш пот балыкны сибеп салгач, Шәрәфи агай:

— Хәере белән булсын! — диде.

Шәрәфи картның авызына карап, тачкачылардан да кайсыберләре авыз эченнән аның соңгы сүзен тәкрарладылар:

— Булыр әле...

---

[1] Башлык сөр — башлык бул.

Невод сала башлаганнан соң, бер атна буе эшләр бер көйдәрәк барды: балыкның чыгуы биш-алты тачкадан артмады.

Беркөн төш алдында беренче неводны чыгаргач, нык кына җил кузгалды. Көн иртәдән бирле болытлы булып, инде диңгездә давыл булырга охшый иде, шунлыктан барактагы егетләр, бүген инде икенче мәртәбә невод салынмас дип уйлап, төш ашыннан соң кайсы йокларга ятты, кайсылары шашка уйнарга тотындылар.

Бервакыт Исак барак ишеген ачты да аптыраган тавыш белән җикеренергә тотынды:

— Чыгыгыз, әйдә тизрәк! Неводка әйдә! Аркан ычкынган!..

Ул ишекне япмыйча ук тавышлый-тавышлый китеп барды. Сафа белән Хәйрулла шашка уйнап утыра иделәр.

— Аптырадыңмыни, шайтан! — диде Сафа.— Давыл кузгалса, невод салдырмыйлар аны! Бәдбәхет!

Гариф өч-дүрт иптәше белән алдан китте... Лабаз артыннан әйләнеп үткәч, кинәт бик газәмәтле[1] күренеш алдына чыктылар. Диңгез кузгалган... Күз күременчә зур су түтәлләре, ак күбекләр пошкырып, бер-берсен куа киләләр.

Солдат кычкырып җибәрде:

— Иххи! Карагыз, көймәне кайда илтеп ташлаган!

Сафа алга карады да, күтәренке тавыш белән:

— Неводны харап итә, егетләр! — диде, һәм үзе, йөгереп, неводчылар җыелган җиргә китте. Сафа артыннан башкалар да йөгерешеп киттеләр. Исак белән Шәрәфи агай да анда иделәр. Гадәттән тыш аптырау, кычкырыш бара иде. Читтән биш-алты саженьлап эчтә невод көймәсе әллә ничә уңайга бәргәләнеп, чайкалып тора, көймәдә биш-алты кеше — невод салучылар — йомычка кисәгенәябышкан булдыксыз һәм кызганыч тараканнар шикелле аумаска, ычкынып китмәскә тырыша иделәр... Ухылдап торып килгән дулкыннар бер бәреп көймәне югары сикертә, кире кайтып, комга утыртып куя, тагын бәрә дә тагын сикертеп җибәрә... Койрыктагы курщик, бер кулы белән руль тоткасына ябышып, аяктан егылмаска тырыша, икенчесен бутап-бутап, бар көче белән кычкыра, кемнедер сүгә.

Гариф, Шәрәфи карт янына барып:

---

[1] Газәмәтле — олы, бөек, мәһабәт.

— Нәрсә ул, ни булган? — диде. Теге, салкын кан белән генә:

— Арканны ычкындырганнар, курщик тагын дүрт ишкәкче сорый, баручы юк! Эт — эткә, эт койрыкка җибәрә...— диде.

Гариф кинәт, кирәкле хәбәр ишеткән төсле, күзләрен уйнатып:

— Мин барам! — диде һәм сикереп үк су янына йөгерде... дулкын эчкә кайткан арада, Гариф сикереп торып көймәгә ташланды... аны көймәгә тартып алдылар. Аңар ияручеләр дә тиз табылды... Җансыз сөяк кебек чайкалып торган шактый зур көймә кирәкле кешеләрен алгач та җанланды; өч пар ишкәкне алты кеше бер уңайга күтәреп сала башлагач, ул, килешсез кара бер җанвар кебек дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп китте. Ул, читтән ераклашкан саен, көчсез һәм кызганычрак күренә, гүя хәзер батарга, югалырга тора иде.

Җил улый, сызгыра, диңгез һаман дулкынлана, дулый бара иде...

Гарифның иптәшләре, аптырап, Шәрәфи агай янына җыелышканнар, аның авызына карыйлар, ул акрын гына Исакны сүгә:

— ...Кирәкми, дим, невод салдырма, давыл күтәрелә... Юк, тыңламый бит, шайтан! Менә хәзер дә аркан ычкынган икән, бер яктан гына тарттырасы, ярты сәгатьтә эше бетә!.. Юк, имеш, алай невод ишелеп, чуалып бетәр... Невод чуала дип, кешеләрне күрәләтә батарга җибәрә, мәлгунь! ...Бер яктан тартып, невод бер дә чуалмый... Аны үзе дә белә... Пае бар ич, юккамы шулхәтле тырыша дип беләсең? Ул үзе өчен тырмана... Гариф тагын нәрсәгәдер юләрләнеп китте. Минем аңар ачуым килә! Тотып та өлгерә алмадым, ичмасам...

Николай... болар янына килеп туктады... да, нык кычкырмыйча гына:

— Дурак безнең артельщик,— диде. (Гарифны күздә тота.— *А. Я.*) Ул төшмәсә, тегеләр берсе дә төшәселәр түгел икән...

Ул, тавышын тагын да акрынайтып:

— Беләсез тегеләр нәрсә ди... Әгәр көймә кайтмаса, әнә теге ике господинны буып, суга ташламакчы булалар,— диде.

Еракта дулкыннар арасында бер югалып, бер калкып торган көймә һаман да бер урында төсле күренә, кырыйга елышканлыгы да, эчкә таба китеп барганлыгы да күренми иде.

Байтак вакыт шулай тынычсызланып торганнан соң, кешеләргә җан керә башлады: көймә кайтып килә иде.

Көймә һаман якынлый иде; ул тискәре һәм усалланган дулкыннар белән җан-фәрманга көрәшеп килә; бер дулкын сыртыннан алга сикереп киткәндә, икенчесе бәреп аны чигерә, ул тагын да алга үрмәли, тагын сыртка күтәрелә, тагын сикерә, тагын үрмәли иде...

Шәрәфи карт, баскан җирендә тора алмый кулларын уыштырып:

— Ризамын, егетләр! Шулай кирәк! Юләр бул да, егет бул! Батып калсагыз, сүгәр идем, инде афәрин, шайтан икәнсез! — дип сөйләнә-сөйләнә йөри иде.

Хәзер инде көймә булдыксыз, кызганыч ябалак кебек түгел, йөрәкле карчыга шикелле матур һәм сөйкемле күренә иде. Көймәдәге егетләр дә көчсез һәм йомшак тараканга түгел, гайрәтле үткен кырмыскаларга охшый иделәр.

Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә ...көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады... Халыкның бер өлеше тиз-тиз генә көймәне корыга сөйри башлады... Тачкачылар Гарифны урап алганнар иде. Ул, утырып, итекләренә тулган суларны түккәч, Шәрәфи агай, аны читкәрәк тартып:

— Күлмәк-ыштан бармы? Тиз генә барып алмаштыр... Булмаса мин бирим... Бездән барып ал...— диде. Гариф оялган сыман көлемсерәде:

— Бар, Шәрәфи абзый, үземдә бар, борчылмагыз, зинһар...— диде.

— Ну бар, тиз генә алмаштыр да безгә кил, ишетәмсең, йомыш бар... Йөгер инде, әйдә, тиле.

Гариф көймәдә бертуктамый көч биреп ишкәнгә күрә кызган иде. Көймәдән төшкәч тә ул кадәр салкынлык хис итмәде. Әмма баракка килеп кергәч, баракның бушлыгы, шакшылыгы, нар буена җәйгән салам урыннар, озын такта өстәл буенда чәчелеп яткан чүп һәм икмәк валчыклары, нәкъ уртада асылынып торган иске лампа, диңгезгә караган бер генә тәрәзә, ...гүя аның йөрәгенә боз булып утырдылар. Ул калтырана, туңа башлады. Бигрәк тә тәрәзәнең бозылган бер күзеннән улап кергән җил тавышы белән бергә тонык һәм тирәннән гөжләп килгән дулкын тавышлары аның эчен чымырдатып, чәчләрен терпәйттерә иделәр. Ул коры күлмәкләр киеп алгач... Шәрәфи агайның җылы һәм уңайлы өен күңеленә китерде.

Ул бер исәп белән туры неводчылар янына китәргә дип тә уйлаган иде, ләкин картның чакыруын илтифатсыз калдырырга уңайсызланды.

Бу ишектән керүгә, Шәрәфи агай кадерле бер кунак көткән кебек каршы ук алды.

— Әйдә, Гариф, әйдүк, туган,— диде...

Карчык белән Газизә аңа гаҗәпләнгән сымак күлемсерәп карадылар. Гариф бераз кызарынды. Өстәлдә ярты савыт аракы, бер чәй чынаягы утыра иде. Гариф утырмас борын ук Шәрәфи агай бәрәкәтле генә иттереп чынаякны тутырып куйды да, җитди генә чырай белән:

— Әйдә, эчеп җибәр шуны! — диде. Гариф, аның күзенә карап, аптыраган сымак:

— Юк, Шәрәфи абзый, мин бит ул нәрсәне эчми идем,— диде... Карт, эшлекле кыяфәтен бозмыйча гына, чынаякны моның борын төбенә үк сузып:

— Дару өчен, юләр! Юкса хәзер бизгәк эләктерерсең...— дип, бик кыска бәйләнде...— Шушы салкында муеныннан суга чумды бит ул! Бир әле монда борыч савытын... Бераз борычлап җибәрик!— диде. Газизә тиз генә борыч савытын табып китерде...

Гариф, көләсе килеп, эченнән: «Җыйнаулашып дарулагач, инде карышып торырга килешмәс»,— дип уйлады...

— Менә шулай,— диде карт.— Бизгәк ул — кабахәт нәрсә, Ходай сакласын... Монда бит Раси түгел... Диңгез ул, кабахәт!

Ишегалдына чыккач, Шәрәфи агай чикмәнне Гарифка тоттырды.

— Бар, әйбәтләп кенә төренеп ят!

Гариф карышмады, тагын баракка китте.

Барак тагын шулай ук ямьсез, кызганыч, буш көе тора... Солдатның иске шинелен салам өстенә салып, үзенең пальто кисәге һәм картның чикмәне белән баштан ук ябынып ятты... Ул чикмәнгә бик нык төренгәнгә күрә, тәрәзәдә улаган җил һәм дулкын гөрләүләре аермачык ишетелми. Тик әллә кайсы почмакта гүя әллә кем акрын тавыш белән ярсуланып-ярсуланып бертуктаусыз елый иде... Аһ, мескен, кем соң син?.. Гарифның әнкәсе генә шулай елый иде... Әнә аның эткәсе — кара күзле, таза гәүдәле, исерткечкә мөбтәлә[1]

---

[1] Мөбтәлә — хирыслык, дучар булу.

мулла... Ул балаларын, якыннарын сөя, ләкин аны сөюче юк... Менә ул базар авылыннан пар ат яллап кычкыра, җикерә, җырлап кайта...

Әнкәсе тавыш чыгармый, бер җирдә качып, әкрен генә елый... Менә мәчеттә тавыш чыгып, ул намаз укытмыйча, күзләрен бөтенләй кан басып өйгә кайткан... Тагын әнкәсе елый... Менә... аның «указы» алынган... Менә аның урынын тартып алган «сары җиләнле мулла» инде аның җеназасы өстендә иелеп, бөгелеп, әрле-бирле йөгерә... Бу чагында инде әнкәсе тавышсыз түгел, өзелеп-өзелеп тавышлап ярсый...

Гариф шушы күңелсез хатирәләргә бирелеп торган чагында, кинәт ишек ачылып аны сискәндерде. Чикмәнне азрак ачып карагач, бераз аптырап китте: Газизә кергән иде.

— Гариф абзый, йокламыйсың икән... Юеш әйберләреңне әнкәй сораган иде, кухняга илтеп җәясе үзләрен...— диде.

Гарифның бер читкә ташланган тужуркасы белән күлмәкләрен Газизә җыештырып алып чыкканда, Гариф утырган җиреннән: «Мәшәкать булыр, борчылмагыз, Газизә...» — дип сөйләнеп калды.

Газизә чыгып киткәч, ул беркадәр аптыранган рәвештә ишеккә карап торды-торды да тагын бөркәнеп ятты. Кайсыдыр почмакта әллә нинди моңлылык эчендә һаман бернәрсә елый иде. Ләкин бу юлы аның елавы Гарифның күңеленә тупас өметсезлекләр, ачы кайгылар салмый, бәлки аның күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык катыш эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде. Аз гына элек Гарифны кара хатирәләр, тупас өметсезлекләр белән газаплаган шушы билгесез моңлылык гүя аны юата, иркәли, шатланырга, шатланып, үзе белән бергә еларга куша...

Киң күкрәкле, юлбарыстай көчле һәм матур егет иске чикмән астында әкрен генә елый иде.

Матур бер иртә, моңлы бер кичә

Давыл башланганга ике тәүлек тулып, өченчегә киткәч, кич белән җил басылган, диңгез шактый күтәрелеп чайкалса да, күбекләр пошкырмый, йомшак кына тирбәнеп тора иде.

«Балык, балык...» Һәркемнең авызында шул сүз иде.

...Ике көн эшсезлек аркасында йөрәкләрне әкрен генә кимереп торган эч пошу артыннан эш көне гадәтчә бер бәйрәм кебек күңелле башланды.

Невод кырыйга якынлашкан саен, халыкта рух арта, йөзләр көлә иде... Өметләр бушка чыкмады... Ике вагонлап балык чыккан иде.

...Чыккан балык күп диярлек түгел иде әле, тик давылдан соңгы бу беренче невод өметне генә арттырды.

Икенче невод төш вакытларында чыкты. Ләкин көннең иң һәйбәт, кызу вакытында зур өметләр баглап, дөнья күкрәтеп җыр-көй белән тартылган бу ау шатландырмады. Балык иртәнгенең яртысы гына иде.

...Кичкырын гына пар атта хуҗа үзе килеп төшкән иде... Болар халык янына барып туктагач, Исак, күзләрен ялтыратып:

— Менә безнең тачкачылар,— диде.

Хуҗа көлемсерәп кенә эшләпәсен кузгатты да:

— Ә, князьләр[1] икән... Яхшы халык... Яратам мин аларны, эшчән булалар...— диде.

...«Князьләр» ...аның эшләпә кузгатуына каршы үзләренең иске-москы бүрекләрен гүя башларыннан төшмәгәнме икәнлеген белер өчен генә тотып куйгач, акрын гына икенче якка шуарга, неводчылар арасына кушылырга карадылар.

Шәрәфи агай, фонарен тотып, тачкачылар белән бергә сөйләнә-сөйләнә, лабаздан чыкты.

Сүз хуҗа турында иде. Ул, лабаз йозагын шыгырдатып тотып бикләп алгач:

— Кешесе карарга әйбәт, тик артык комсыз малай,— диде...— Үткән ел балык аз булгач, буыла башлаган, мәлгунь! Анасы белән сеңлесе генә чак коткарып калганнар. Хәер, байларның һәммәсе дә шундый мәлгуньнәр.

Әйт шуны

Пасха көне иде... Ике чирекне түр почмагына куеп, өстән бер чикмән белән ябып куйдылар... Шул арада Исак килеп керде. Аның бер кулында беркөнге чиләк бар иде; китереп шуны өстәл уртасына куйды. Димәк, ул яктан булган өметләр дә бушка чыкмады була...

...Бу юлы Исак кулында рюмка түгел, кечкенә генә кружка иде.

Һәммәсенә берәр рәт биргәч, Исак чиләкне алды да:

---

[1] Князьләр — элек татарларны руслар шулай атап йөрткәннәр.

— Ну инде ашагыз әйбәтләп. Анда неводчылар да кетәләр булыр,— диде.

Балыкчыларга эш кушучы Исак исемле кеше сыеннан авыз иткәч, егетләрнең күңелләре күтәрелә. Көлешәләр, үртәшәләр. Ләкин көлеп үртәүне берәүләр аңлый, берәүләр чынга ала. Шул сәбәпле сугыш башлана. Гариф сугышучыларны ике якка «ыргытып җибәрә». Сафа, ачуыннан чынаяк ыргытып, маңгаен яралый. Сабыр холыклы булса да, гайрәтле Гариф бу эшкә түзеп тормый, сугыш чукмары Сафага әҗәтен кайтара да чыгып китә.

Берничә рус хатын-кызлары лабаз алдында кояшка каршы тезелешкән, чыр-чу килеп көнбагыш чиртеп утыралар. Газизә дә шунда иде.

Газизә, аптыраныл һәм кызганган тавыш белән:

— Гариф абзый, нишләдең болай? Битең каный ич!..— диде. Гариф аңар якын гына бер мичкә өстенә килеп утырды да, җитди һәм тынычландыра торган тавыш белән:

— Бернәрсә юк ла! Берсе ялгышлык белән әйбер ыргытканда тидереп, аз гына тырнап алды шунда...— диде...

— Бир әле яулыгыңны,— диде Газизә,— мин юып килим...

Биргәнне дә көтмичә ул, Гарифның канлы яулыгын кулыннан алып, диңгез кырыена йөгерде.

Ул бүген Гарифка гадәттән тыш сөйкемле күренә иде...

Гариф, битеннән каннарын юарга уйлап, эре-эре адымнар белән Газизә янына төште...

Газизә, аның янына ук килеп:

— Тукта әле, яулык белән...— диде.

Газизә, чыланган яулык белән аның яңагын сөртә-сөртә:

— Җылы су булганда әйбәт буласы икән... Су тигәч ярамас бит, әрнер...— дип, кызганган тавыш белән, балаларча сөйләнә иде...

Аның болай чын ихластан кызганган рәвештә шөгыльләнүе Гарифны эчтән көлдерә дә, елата да, тәмам үзәген өзә иде. Хосусән ул, шулай бик мөһим эш эшләгән төсле дикъкать белән яулыкны чылатып-чылатып, Гарифның яңагыннан каткан каннарны сөртеп маташканда, аның алсу йөзе Гариф йөзенә шактый якын торуы Гарифны үтерә иде... Ул Гарифның күзенә карамый, барлык дикъкате белән җәрәхәткә су тигезмәскә тырышпа, гөл чәчәгенә охшаулы ираннәре беленер-беленмәс кенә тетри... Гарифның хәзер бу беркатлы һәм сөйкемле туташның гадәттән тыш үзенә якынлык күрсәтүенә

җаны рәхәтләнә иде. Алар элекке урыннарына утыргач, Гариф, хикәя сөйләргә башлаган рәвештә:

— Бер атна-ун көннән соң, Газизә... монда акчарлаклар тавышы гына яңгырар...— диде.

— Нишләп?

— Эш бетә ич, шуннан таралышабыз...

— Авылыңа кайтасың, әйе?

— Анысы әле билгеле түгел, ничек булыр...

— Юк, авылыңа кайт, Гариф абзый, авылыңа кайт, яме? Туганнарың көтәләр булыр... Сагынганнардыр үзеңне. Менә кайтырсың бервакыт...

Гариф көлде:

— Минем белән барсаң, кайтам! — диде. Газизә кызарынып китте...

— Мин нәрсәгә! Мин әткәйләр белән ич! — диде.

— Ә мин ялгыз гына авылга кайтмыйм...

Газизә, кызарып, куллары белән йөзен каплады.

Гариф... кинәт эчтән борчыла башлады: Газизә аңар рәнҗегән шикелле тоела иде. Ул бигрәк тә шушы минутта үзенең Газизәне алдамакчы булмаганлыгына кешеләрне ышандырырга мөмкинлек юкка борчыла иде. Ул җитди һәм акрын тавыш белән, Газизәне юаткан рәвештә сөйләргә тотынды:

— Мин сиңа тагын мондый сүзләр сөйләмәм... Мин сине кардәш урынына күрәм. Җаным... Син мине бу юлы кичер... Мин кардәшемне алдамыйм, мин кемне дә алдарга теләмим... Мин сине туган сеңлем кебек яратам. Сине генә түгел, Шәрәфи абзый белән Сәгыйдә апайны да яратам... Сез мине үз итәсез, сезнең игелегегезне кайтарырга кулымнан килмәгәнлектән мин оялам. Минем күңелем борчыла, мин сине бит чынлап яратам. Синең матур чәчләрең, ачык, килешле маңгаең минем күзләремә рәхәт, җаныма җылы бирә... Мин сине сөям, күз нурым. Чиксез бәхетле булуыңны, чиксез сәгадәтеңне... күңелем тели! Шушы теләкләремне булдыра алмауга җаным газаплана, аягыңа егылып елыйсым килә...

Газизә башта хәзер торып китәргә генә уйлаган төсле аптыранып торса да, сүзнең соңгысы аны бераз ачып җибәрде:

— Әллә нәрсәләр чуалтасың, бернәрсә аңлар хәл юк! — диде. Шушы арада... Сафа белән Солдат, чак-чак кына аяк өстендә торып, кочаклашкан көе, лабаз артыннан килеп чыктылар... Сафаның күз төпләре шешкән иде... Алар ерак түгел бер читтәрәк утырдылар.

Гарифның эче тырный башлады. Сафа аңар чынлап кызганыч күренә. Күз тирәләре күгәреп ямьсез шешкән; сөйкемле генә чырае тәмам үзгәргән, бозылган иде...

Мин сине көтәрмен

Апрель ахырлары иде инде... Еракларданн күренгән газамәтле таулар, таулардан түбән тимер юлы буендагы болынлык һәм таллар гүя чем-яшел хәтфәгә бөркәнгән көе ерактан торып көлә һәм матур җәй башлануын сөйлиләр...

Безнең тачкачылар, балыкны бик күп тотып та, кырыгар сум акча эшләү хыялларына инде бит сыпырган иделәр... Ләкин балыкның аз булуы аларны өметсезләндермәде. Җәй башының көләч кояшы, матур яшел хәтфәгә бөркәнгән серле таулар аларга әле бик күп нәрсә ышандыра, мең төрле вәгъдәләр бирә иделәр.

Алар инде гел киту турында сөйлиләр...

«Фабрикант» үткән ел Пятигорскида корзинка белән күтәреп булки сатып йөргән. Ул шушы эшне мактый. Николай Кисловодскида постройка һәм паркларда туфрак эшен бик файдалы тапкан... Солдат Бакуга барырга исәпли. Нәрсә юкны йөрергә? Кайчан ки, нефть промыслоларында сторожлыкта рәхәтләнеп торып егерме биш сум алырга була, ди...

Невод салу туктагач, алар берничә көн лабазда эшләделәр... Газизә дә шунда алар арасында эшли иде... Егет-җиләнн Газизәгә әдәпсезлек күрсәтми иделәр. Газизәнең сөйкемле һәм җитди чыраенда, садәлек[1] катыш чын кыланышында, кешенең күңелен үзенә тарту белән бергә аны бертөрле хөрмәт иттерә торган бер хасият бар иде: мондагы татар егетләре, үзләре сизмичә, аны эчтән хөрмәтле тоталар, аңардан әдәп саклыйлар. Әлхасыйль[2], иң дөресе — һәммәсе диярлек эчтән аны сөя иделәр. Шунлыктан аны хөрмәтсез итәргә, оялтырга берсенең дә күңеле бармый иде.

Шулай да актык чан бушатылган көн Сафа байтак кына аның белән шаярып сөйләнде. Бер арада:

— Якташ,— диде,— киләсе ел монда булырсың бит?

— Бер дә әйтә алмыйм... әткәйләр нишләр...

— Әгәр син булсаң, без дөньяның дүрт почмагыннан монда җыелабыз, өйрәнеп киттек инде...

---

[1] Садәлек — гадилек.

[2] Әлхасыйль — озын сүзнең кыскасы.

Газизә тагын кызарынды: «якташлары», назланган сөйкемле балага караган кебек елмаеп, аңар карап тора иделәр. Гариф тиз генә эшне искә төшерде:

— Ну, егетләр, кич була бит!— диде...

Тачкачылар актык чан төбендәге актык балыкларны ашыгып-ашыгып сөзәргә тотындылар. Хатын-кызлар, нечкә һәм моңлы тавыш белән җырлап-җырлап, актык мичкәләрен тутыра иделәр.

Газизә... тавышы ачык ишетелми, рус хатын-кызларыныкы арасында югала иде.

Иртән аяз, ләкин шактый салкын һәм җилле иде... Исәптә вак-төяк әйбер һәм акчалата алганнары чигерелеп, һәммәсенә йөз ун сумлап акча бирелде. Баракка җыелып, аны үзара бүлештеләр.

Алар бporактан чыкканда, кояш инде, бик түбән төшеп, болытлар артына яшеренгән... Җил йомшаган, һава иртәгедән җылы һәм күңелле иде.

Гариф белән Солдат иң арттан чыктылар. Гариф кинәт туктады да:

— Карт белән исәнләшәсе иде бит,— диде...

Гариф барганда, Газизә күлмәкчән генә, кара шәл бөркәнеп, ишегалды баскычында утырып тора иде. Ерактан ул Гарифның күзенә күңелсезләнеп, кайгырып утырган төсле күренде... Кинәт үзенең... җиңел баштан Газизәне авылга алып кайту турысында яшелле-кызыллы сүзләр сөйләп ташлавы исенә килеп, күңеле һәм оят, һәм ачу тойгылар белән тулды...

Газизә чын да күңелсез иде. Гариф аның янына җиткәч тә:

— Безнең китеш, Газизә туташ...— диде. Газизә күңелсез генә елмайды...

— Менә Гариф абзыйга ышанып тор! Мине дә авылга алып кайтырга әйткән идең ич...— диде.

Гариф, акрын гына кулын Газизәнең башына куеп:

— Мин озакламый Саричинга кайтырмын... Аннан менә авылга барырбыз. ...Туй да ясарбыз, ярыймы, җаным?— диде дә, Газизәнең ачык һәм килешле маңгаена иреннәрен куеп, эч өзгеч бер мәхәббәт белән үпте... Шул арада бер-берсенә ишетелерлек, өзек-өзек шыпырт кына тавыш белән, алар вәгъдәләшә иделәр:

— Мин озакламый... Саричинга кайтырмын, җанашым...

— Мин сине көтәрмен...

Гариф ишегалдыннан чыгып киткәндә, Газизә тагын аның артыннан кычкырды:

— Кара, мин сине көтәрмен...

Гарифның иптәшләре инде байтак еракта, бер төркем булып, диңгез кырыйлап туктаусыз бара иделәр. Солдат алардан артка калган, Гарифны көтеп, туктый-туктый бара иде.

Гариф, канатланып очкан шикелле, аны җитәргә дип йөгерә иде. «Мин сине көтәрмен» дигән җөмлә аның колак янында әллә нинди югары һәм эч өзгеч ноталардан җырланып бара, аның җанын ләззәт белән катыш ачыта, сызлата иде.

Газизә байтак вакыт, ишек яңагына сөялгән көе, китеп баручылар артыннан карап торды. Кояш та иңгән йә иңмәгән! Ул якны инде болыт каплаган иде... Диңгез өстендә сирәк-саяк акчарлаклар күренгәли; алар, ак канатларын селтәп-селтәп бер югары, бер түбән очып, тонык һәм эч пошыргыч тавыш белән елаганга да, көлгәнгә дә охшашлы гыйкылдап-гыйкылдап кычкырыналар... Газизә хәзер аларны карамый, ул диңгез кырые буйлап очмыйча гына китеп барган канатсыз акчарлакларны гына карый иде... Тик боларның тавышлары гына, үкереп елаган шикелле булып, аның колагында чыңлый иде. Ул бераз торганнан соң өйгә керде һәм мендәренә капланып, әкрен генә үксеп-үксеп елый башлады... Бик тирән эч пошу аның йөрәген өзә иде...

1914 ел

Биремнәр

1. «Әүвәл-әүвәл заманда» һәм «Акчарлаклар» әсәрләренең охшаш сыйфатларын әйтегез.
2. Повесть жанрының үзенчәлеген исегезгә төшерегез. Повестька анализ ясагыз.

Йомгак ясыйк

Шәриф Камал әсәрләренең уртак якларын да, аермалыкларны да күрдек. Әсәрләрнең уртак якларын барлыйк:

Әдип революциягә кадәр язган әсәрләрендә бәхет темасын кабатлый.

Шәриф Камал барлык хикәяләрендә дә, повестенда да күренешләрне ашыкмыйча, төпченеп, аларның вак-вак сыйфатларына кадәр язарга ярата. Ә инде метафорадан файдалануга килгәндә, үз заманында аңа, гомумән, тиңдәш булмаган. Бала елатса да, акчарлак кычкыртса да, диңгез шаулатса да, автор һәрвакыт аларны төп вакыйга эчтәлеге белән бәйләп куя.

Шәриф Камалның бу сыйфатларын да **язучы буларак үзенчәлеге** дип исәплик.

Тагын бер үзенчәлеге шунда: аның персонажлары көләләр дә, шаяралар да, ләкин бервакытта да эчке борчу-хафаларын онытмыйлар, һәммәсенең күңел кыллары киеренке, юк кына сәбәптән дә өзелергә тора.

Фатих Әмирхан

(1886—1926)

Фатих Әмирхан (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов) 1886 елның 1 гыйнварында Казанның Яңа Бистәсендә мулла гаиләсендә туган. Әтисе Зариф мулла улын шөһрәтле «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә илтә. Монда алты яшьлек Фатих бик яхшы укый. Рус телен өйрәнергә Самарага китә. Казанга кайткач, күренекле большевик С. Н. Гассардан дәресләр ала. С. Н. Гассар укучысын русчага өйрәтү белән генә чикләнмәгәндер, билгеле. Кешеләрне ничек бәхетле итәргә дигән сорауга ул, большевикларча: бәхет — азатлыкта, ләкин азатлыкны корал көче белән яулап алырга кирәк, дип җавап биргәндер.

Фатих Әмирхан бөтен гомерен татар халкын бәхетле итү өчен көрәшкә багышлый. 1905 елгы революциядә актив катнаша: укытучысына ярдәм итә, шәкертләр хәрәкәтен җитәкли... Булачак әдип үзенең икеләнү белмәгән укытучысыннан дөньяны танып белергә өйрәнә. Ләкин өйрәнү — ышану түгел әле ул. Көчкә көч белән каршы чыгу күп корбаннар сорый. Ә Фатихның яшь күңеле тулы игелек. Әти-әнисе аны явызлыкка каршы явызлык белән җавап бирмиләр дип тәрбияләгәннәр. Татар халкының канына сеңгән бу әхлак кагыйдәсе егетнең үз карашына да бик хуш килә. Көчкә көч белән каршы чыгаргамы, башка юл эзләргәме? Фатих Әмирхан, бу сорауга җавап эзләп, татар әдәбиятын нык лап өйрәнә, рус әдәбиятын һәм философия китапларын укый. Париж Коммунасы тарихы турында хәтта мәкалә дә язып чыга.

Фатих Әмирхан 1917 елгы Февраль революциясен бик шатланып каршы ала. Ә Октябрь революциясен кабул итә

алмый. Укытучысы большевик Гассар карашы ялгыш дигән нәтиҗәгә килә.

Фатих Әмирхан белемен арттыру нияте белән Мәскәүгә, Петербургка барып чыга. Анда курсларда укый. Ә Казанга кайткач, «Әлислах» исемле газета чыгару артыннан йөри башлый. «Ислах» — «үзгәртеп кору» дигән сүз. Фатих Әмирхан татар халкының тормышын кешеләрнең белемен арттыру һәм аларны әхлаклы итеп тәрбияләү юлы белән үзгәртергә кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Шул теләк белән янып йөргәндә, 1907 елда кинәт авырый башлый һәм бик зур бәхетсезлеккә юлыга — ике аягы да йөрмәс була. Йөрмәс аяклары егет кешенең бик күп якты өметләрен җимерә. Ләкин ул төшенкелеккә бирелми, күңел көрлеген, шаянлыгын, эшләү сәләтен саклап кала. Шул хәлендә әдип «Әлислах» газетасын чыгара башлый. Бик тиз арада аны иң шөһрәтле газета югарылыгына күтәрә. Бу эштә аңа фикердәшләре һәм дуслары Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, С. Рәмиев ярдәм итә.

Газетада эшләүче кеше үзе дә мәкаләләр язарга тиеш. Фатих Әмирхан шулай итә дә. Тиз арада ул сәләтле журналист булып танылa. Аннан соң «Ялт-Йолт» сатирик журналында, «Кояш» газетасында эшли. Шуның белән бергә, «Фәтхулла хәзрәт», «Урталыкта» исемле романнарын яза. «Яшьләр», «Тигезсезләр» исемле пьесалар һәм бик күп хикәяләр иҗат итә.

Фатих Әмирхан — гаять дәрәҗәдә үткен телле юморист. Татар әдәбиятында беренче сатирик романны да ул яза, ә хикәяләренең яртысыннан күбесе — көлкеле әсәрләр.

Әдип әсәрләренең күбесендә муллалардан, ишаннардан көлә. Әмма бу әсәрләрендә дингә дә, дин башлыкларына да каршы көрәшми. Ул һәр үзгәрешкә һәм яңалыкка аяк чалучы хакимият биләүчеләргә каршы чыга. Чөнки тормышны үзгәртү аларны җылы урыннарыннан мәхрүм итә, яки иске гадәтләрен һәм белемнәрен яңартуны сорый. Фатих Әмирхан иҗат иткән чорда дин башлыкларының шактые яңалыкка, үзгәрешләргә каршы чыга. Яңалыкка аяк чалучыларга «консерватор» диләр. Фатих Әмирхан консерваторлардан көлә. Революция алды елларында консерватор дин башлыкларына каршы күренекле язучыларның барысы да, хәтта муллалар үзләре дә көрәшә.

Октябрь революциясеннән соң әдип төрле газеталарда эшли. Совет матбугатында аны буржуаз язучы дип, нахакка

рәнҗетеп, мәкаләләр, хәтта китаплар язалар. Әдип аларның берсенә дә җавап бирми.

Үзенең яраткан язучысын хаксызга гаепләү белән халык риза булмый. Аны ел саен Казанда үткәрелә торган Сабан туеның абруйлы рәисе итеп сайлыйлар. Мәйдан уртасына әдип утырган арба кергәндә, аны халык аягүрә басып, кул чаба-чаба каршы ала торган була.

Фатих Әмирхан хикәяләрендә кабатланган тема

Безгә бишенче сыйныфтан ук таныш булган «Нәҗип» хикәясен искә төшерик. Бу хикәядә Нәҗип исемле малай үзенең кимчелекләрен күреп ала һәм әсәрнең башыннан ахырына кадәр үзенең көнчелеге, тәкәбберлеге белән көрәшә. Үзен үзе шул рәвешле тәрбияли. Әсәр ахырындагы Нәҗип белән өй түбәсенә менгән Нәҗип арасында җир белән күк арасы. Ул үзгәрә, үсә.

«Бу әсәр нәрсә турында?» дигән сорауга, кыскартып, кешенең яман гадәтен үзе җиңеп үсүе, үзгәрүе турында дип җавап бирә алабыз.

Фатих Әмирхан «Ул үксез бала шул!» хикәясендә кабат шул ук темага әйләнеп кайта. Бу әсәрдә дә кеше, үз хатасын төзәтеп, үзен үзе тәрбияли, үсә. «Ул үксез бала шул!» хикәясендә хәтта берьюлы берничә малай үзгәрә. Ә менә «Корбан» хикәясендә төп персонаж начар холкын үзгәртми. Шуңа күрә гомере буе газап кичерә. Ләкин «Корбан» хикәясендә дә шул ук тема кабатлана. Ул бары тик башка яктан гына ачыла. Фатих Әмирхан исемнәре аталган ике хикәясендә дә көчле ихтыярлы малайларның уңай үрнәкләрен тасвирлый. «Корбан»да шуларның киресен — үз хисенә буйсынып яшәүче малайның язмышын гыйбрәт итеп сурәтли.

Хәзер шул ук теманы әдипнең күләмле әсәрендә эзләгез. «Хәят» — татар әдәбиятында иң матур повестьларның берсе.

Хәят

(Повесть)

1. Ах, Хәят, нинди матур син!..

Майның бер якшәмбесе, көндезге сәгать өчләр иде. Бер сәгать кенә моннан әүвәл явып киткән җиңел яңгыр шәһәр урамнарының тузанын баскан һәм, һавадагы кызулыкны

җиңелчә язгы җылылык белән алмаштырып, көнне ямьлелекнең чигенә ирештергән иде. Әле һаман һавадан җуялып бетмәгән яз җиле кояш батышы ягыннан аерым бер акрынлык вә тынычлык белән исә дә дөньяга яңару вә яшәрү исләре чәчә һәм бөтен җанлы вә җансыз нәрсәләрне үзләренә бертөрле тереклектә коендыра иде.

Гыймадовлар йортының капкасы төбенә килеп туктаган кечерәк кенә тарантастан гимназия формасында киенгән уналты-унҗиде яшьлек... бик куе сары чәчле бер кыз төште дә җиңел адымнар белән ашыкмый гына капкадан кереп китте һәм... калын йөзле асрауны туктатып:

— Биби, Хаечка дома? — дип сорады...

Биби, ни өчен икәнен үзе дә белмичә, бик киң итеп елмайды һәм, җәһәт кенә адымнар белән ишегалды түрендәге бакчаның челтәрле коймасы янына килеп:

— Хәят апа, Лиза килде! — дип кычкырды.

Бер минуттан соң бакчадан Хәятның йөгереп чыкканлыгы күренде. Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсуак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде. Ул:

— О, Лиза! Менә гакыллы, дустын онытмаган! — дип, шатлыклы йөгереп, гимназистка янына килде. Дуслар, бик күптән күрешми торган шикелле, үбешеп күрештеләр дә өйгә кереп киттеләр...

Кунак кыз Хәятның анасы Газизә абыстай белән ике куллап күреште дә хәзер Хәятны үзләренә кунакка алырга килгәнлеген сөйләде...

Кызлар Хәят бүлмәсенә керделәр. Хәятка өстен алыштырырга һәм чәчен прическаларга кирәк иде... Хәят әле бары уналтынчыда гына булса да, быел кыш ул, кинәт үсеп китеп, буе-сыны белән инде җиткән кызлардан аермасыз булган иде... Аның быел тектергән ал ефәк декольте[1] күлмәге инде җиткән кызлар кия торган модаларның иң соңгысы белән тегелгән иде...

Ал кием безнең Хәятка бик килешә: ул аның эчендә ал фәрештә шикелле була. Бүген дә ул шулай ук булды. Моны күргән беркатлы (садә) Лиза:

---

[1] Декольте — муен, беләкләр һәм күкрәкнең бер кисемен ачык калдыра торган күлмәк.

— Ах, Хәят, нинди матур син! Син бәхетле, бик бәхетле! — дими чыдый алмады.

Дуслар киттеләр... Кояш алар өстенә ак болытлар арасыннан карап, оялчан гына көлеп тора иде.

2. Ике тормыш

Хәят белән Лиза бала вакытларыннан ук бергә уйнап үскән дуслар иде... Лиза, сигез яшеннән быелга кадәр гимназиядә укып, хәзер урта белемне тәмам итә иде. Хәят, җиде яшеннән ундүрткә кадәр Мәлихә абыстайда укып, үткән кыш... сабак абыстаена йөрүдән туктаган иде...

Мәлихә абыстай... аңар бик озаклык вә читенлек белән язу танытты, аннан соң мөселман кеше тормышы өчен борынгыдан эшләнеп килгән берничә кагыйдә өйрәтте... Хәятка каршы сөйләү һәм шик итүне күтәрми торган, дини вә дөньяви бер караш бирде дә шушы нәрсәдән дөрес, болардан туры вә болардан кирәкле нәрсәләр дөньяда юк инде дигән фикер урнаштырды...

Борһан абзый гади бер татар купецы вә гади татар бае тормышы белән торган кеше иде. Шуңа күрә аның йортындагы һәр кеше, үз теләге вә үз тойгыларына буйсынудан бигрәк, борынгыдан эшләнеп килгән кагыйдәләргә буйсынырга вә шулар билгеләп куйган юлдан чыкмый барырга тиеш иде. Мясниковлар гаиләсендә, берничә генә нәрсәне исәпкә алмаганда, һәркемнең үз теләге, үз тойгылары бик күп урында бик күп нәрсәләрдән алда тотыла иде... Хәят тормышны икегә аера: мөселман тормышы — монысы үзләренекечә (Гыймадовлар) булырга тиешле; рус тормышы — монысы Мясниковларныкыча булырга кирәк дип ышана иде...

Борһан абзый быел кыш Хәятны биш-алты ай русча да укытты... Кирәк Борһан абзыйга вә кирәк Хәятның үзенә шулкадәр нәрсә бөтенләй җитә иде.

4. Мәҗлес күңелле иде

Мясниковлар тора торган дача... төрле пыялалы тәрәзәләр белән бизәлгән җәйлек өе иде... Кызлар өй эчендә озак юанмадылар: бакчага чыктылар... Дуслар юлларның берсеннән киткәннәр иде, каршыларына Лизаның агасы Михаил очрады һәм, шат елмаеп, Хәятка кулын сузды:

— Кемне күрәм мин! Ничә җәйләр, ничә кышлар! Бер кыш эчендә сез, Хаят, танымаслык үсеп киткәнсез, тагы да матурлангансыз,— ди-ди, кызлар белән бергә китте.

Михаил да, Лиза шикелле үк, Хәятның кечкенәдән бергә уйнап үскән иптәше иде. Ул, үткән көз Казан университетына кабул ителгәнлектән, бу кышны Казанда уздырып, кичә генә N шәһәренә кайткан иде.

Алар өчәүләп яр өстеннән Иделгә карап тора торган эскәмиягә килеп утырдылар... Күптән күрешмәгән дусларда сөйләшер сүзләр күп табылды... Бервакыт Михаил:

— Карагыз әле, Хаят, сез әле мин киткәндә генә бала идегез, җиде-сигез айда инде бөтенләй җиткән кыз булып өлгергәнсез: сез үзегез белми торгансыз, сез хәзер шәһәребезнең беренче гүзәле бит...— дип, тагы комплиментлар әйтә башлаган иде, Хәят кызарып китте дә күзләрен җиргә төшерде һәм:

— Фу, черкиләрегез нинди усал,— дип... бу кечкенә «залимнәрдән» зарланырга тотынды. Аннан соң урманнар, елгалар, сәяхәтләр турында сүзләр башланып, бер-бер артлы коелдылар. Мәҗлес күңелле иде.

6. Хәят, мин сезне сөям!

...Якшәмбе булганлыктан, бүген дачникларның һәммәсенә дә кунаклар килделәр. Мясниковларга да шәһәрдән Лизаның ике иптәш кызы агалары белән килгәннәр иде... Яшьләр төркем-төркем төрле тарафларга таралдылар... Хәят... үз артында Михаилның адымнарын ишетте. Яңадан бер-ике адым — ул килеп тә җитте һәм, Хәятның күренешеннән куркып киткән сыман каранып, йомшак һәм пошынган тавыш белән:

— Дускаем, бу кадәр үз-үзегездән югалып, ни уйлыйсыз? — дип сорады да, җавап көтмичә, кулындагы чәчәкләр бәйләмен Хәятка сузды... Чәчәкләр Хәятка карап көләләр һәм әллә кай җирләреннән генә аның борынына берничә исне берьюлы сирпеп торалар иде.

Михаил, сынын ия төшеп, Хәятка култыгын сузды. Алар... читкә аерылып киткән бер юлга чыктылар. Таррак кына, кызыл ком белән түшәлгән бу юлның як-якларында озын һәм эре агачлар тезелеп, батып бара торган кояшның кызгылт нур тамчыларын челтәрләндереп төшерәләр, чит-читкә утыртылган резедалар көчле исләре белән юл өстендәге бөтен һаваны аңкыталар; яфраклар арасына яшеренгән кошчыклар адәмнәр аңламый торган җырларын көйлиләр дә бөтен бу юл, бу кызыл тамчылы нур һәм бу резедаларның тормышларына бер серлелек бирәләр иде.

— Хаят, сез бая гына нинди шат идегез, хәзер әллә нинди бик тирән уйга баткансыз, кояшта сулган чәчәк шикелле булгансыз,— дип, Михаил Хәятка табарак бөкрәйде. Аның уйчан тавышы күңеленең тирән җиреннән чыккан шикелле иде.

Хәзергә кадәр җиргә карап килгән Хәят, күтәрелеп, Михаилның йөзенә карады...

— Юк, бернәрсә дә уйламыйм. Озак кояшта йөрсәм, мин арам бугай, ахры,— диде. Үзе, Михаилны әүвәл мәртәбә күргән шикелле: «Кара, мәхәббәтле генә бит бу рус малае»,— дип уйлады.

Юл өстендәге эскәмияләрнең берсенә килеп утырдылар. Сүз әллә ничек җайланып китми иде. Башка вакытта шулкадәр сүзчән Михаилның хәзер генә сүз таба алмый утыруы Хәятка сизелми калмады:

— Сез мине уйга баткан дисез, әмма үзегез хәзер уйга баткансыз,— дип, Хәят күзләрен Михаилга төшерде. Михаилның күзләре очкыннар чәчеп торалар иде. Ул салмак кына елмайды да, Хәятка туп-туры карап:

— Мин уйга чумган? Аның сәбәбе бар... Сез гаепле аның өчен...— дип башлаган иде, Хәят аңар, сүзен бетерергә ирек бирмичә:

— Михаил Алексеевич, Казанда торганда йортыгызны сагынгансыздыр, әйеме? — дип, сүзне икенчегә борды.

Михаил бобрик белән кыскартылган чәчләрен кирегә сыпырып куйды да:

— ...Казанда торганда йортым исемә дә кереп чыкмады, бары сезне генә сагындым,— дип, сынын Хәятка табарак бөкрәйтә төште. Хәзер аның йөзе Хәятның йөзенә якын ук килгән иде. Хәятның күзләре бу үзләренә якын ук тора торган сөйкемле йөз һәм очкынлы, уйчанрак карый торган коңгырт күзләргә төштеләр. Күңелендә ниндидер бер тойгы кабынды да электрик токлар сыман бөтен барлыкка таралды. Бу тойгыны Хәят үзендә әүвәл мәртәбә сизә иде...

Хәят Михаилның үзенә нәрсәдер, бик кирәкле бер нәрсә әйтергә теләп тә, әйтеп бетерә алмаганлыгын томанлы гына сизенә, ләкин, никтер, ул кирәкле нәрсәнең әйтеп бетерми калганлыгын теләгән шикелле була иде. Кулындагы чәчәкләр бәйләмен борыны янынарак китерде дә, шул чәчәкләргә әйткән шикелле итеп, ул:

— ...Сез әүвәлләрдә бик матур җырлыйдыр идегез. Җырлагыз әле берәр нәрсә,— диде.

Михаил чәчәкләргә карап әйтелгән бу сүзнең үзенә әйтелә икәнен белә иде... назланып тормады:

— Юк, Хаят, мондый тавыш белән җырлаганны тыңлап утырганчы, әнә ул агачта сайрый торган кошчык сайравын тыңлагыз. Ул сезнең өчен сайрый һәм сезнең матурлыгызны мактап сайрый,— диде.

Чынлап та, нindидер бер кошчык, башкаларыннан аерым бер осталык вә аерым бер дәрт белән, болар утырган эскәмия каршысындагы агачның яфраклары арасына яшеренеп сайрана иде. Соңгы сүзләрне әйткәндә Михаилның тавышы бик чынлыклы вә бераз каушанкырак чыга иде. Хәятның йөрәге тыпырчынган шикелле итеп тибә башлады: Михаилга әйтергә аның теленә җавап килми иде. Бер минутлык тик торыштан соң Михаил, уң кулы белән Хәятның сул кулыннан йомшак кына тотып, уйчан гына тавыш белән:

— Ачуланмагыз, Хаят, мин сезне сөям... Минем күңелемдә сез генә...— дип башлаган иде, Хәят кулының үз кулыннан ычкынган икәнен сизде.

Хәят болай итеп әйтелгән «сөям» дигән сүзне әүвәл мәртәбә ишетә иде... ул, ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

— Сез бик мәхәббәтле!..— диде дә, йөзен куллары белән каплап, олы юлга таба йөгерде...

Хәят үзенең кызарганлыгын белә, колакларының ялкынсыз янганлыгын да сизә; һәм хәзер генә булып узган эш аның алдында томан эченнән карап, шатлыклы елмаеп торган шикелле була да, йөздәге кызыллык, колаклардагы яну тагы да көчәя иде.

Яңадан бер минут — Хәят күңелендә куркугарак охшый торган бер китеклек сизде: кинәт бу бик күңелле һәм бераз оялткычрак эшнең бер чите җимерелеп төште. Кай җире җитешми? Кай чите китек? Анысын әле Хәят белеп җиткерми иде. Ләкин сизгер яшь йөрәк бу китеклекне тойды. Бары акыл гына әле аның кай җирдә икәнен анык билгеләп өлгерә алмады...

7. Хәят кызлык вакытын күңел ачлыгы белән үткәрде

Төнге сәгать өчләрдә Мясниковларның аты Хәят вә аны озатырга килгән Михаил, вә Лизаны Борһан абзыйларның капка төбенә китереп җиткерде. Михаил, звонок биреп, ишек ачтыргач, Хәятның кулын каты гына кысып күрешеп, шыпырт һәм яшерен генә тавыш белән:

— Мин җавап көтәм,— диде һәм, шуңар ук ялгап... берничә теләкләр теләде.

Хәят, ишек ачарга төшкән асрау кызга кулындагы чәчәкләр бәйләмен биреп:

— Суга утыртып, минем бүлмәгә кертерсең,— диде дә, үзе аякларының очлары белән генә басып, йөгереп менеп китте һәм, бүлмәсенә кереп, тиз генә өске кат киемнәрен ыргытты да караватына ташланды. Бөтен тәндә рәхәт арганлык тоела, бит урталары яналар, әле генә узып киткән күңелле кичнең төрле-төрле тойгылары башта чуалышып бетеп кайнашалар, Михаилның «мин җавап көтәм» дигән сүзе яшерен тавыш белән колакларны җулатып тора иде...

Хәят, ялкау гына урыныннан торып, бакчага караган тәрәзәне ачып җибәрде. Күрше бакчада, бөтен һаваны яңгыратып, сандугач сайрый иде. Таңның нурлылыгы, сөеклесе гөл чәчәгенең матурлыгы сандугачны шулкадәр җанландырган иде ки, ул үзе белгән көйләрнең иң матурларын сайрый вә шул кечкенә гәүдәсенең әллә кай җирләреннән меңәр төрле ноталар чыгара һәм вакыт-вакыт үз-үзен һәм, гөл чәчәгеннән башка, үзен чолгаган бөтен дөньяны оныткан шикелле, үз тавышында үзе җуяла иде. Хәят бер минутка бөтенләй тик калды, тын да алмады. Аның хәтеренә Михаилның «ул кош сезнең өчен сайрый һәм сезнең матурлыгыгызны мактап сайрый» дигән сүзләре килде. Аннан соң, кечкенә кулчыклары белән тәрәзә бусагаларына таянып, гәүдәсенең яртысын тышкы якка чыгарды да ләззәтле бер дәрт белән, сандугачны аерым бер бирелү белән тыңларга тотынды.

Сандугач, чынлап та, Хәят өчен сайрый, аның матурлыгын мактый, ул матурлыкка әллә нинди якты бәхетләр, күңелле киләчәкләр вәгъдә кыла шикелле иде. Бөтен барлык ниндидер бер рәхәт онытылуга чумды; аллы-гөлле нурга чолганган бәхет, яшь канга аралашып, иң вак тамырларга кадәр үтте; бөтен йөрәкне шундый бер ләззәт чолгап алды ки, андый ләззәтне дәртле, моңлы югарылыклы, ләкин тәҗрибәсез яшьлек кенә татый ала вә аның гына әле бер дә алдану ачысын белмәгән гаклы ышаныч белән каршы ала ала. Хәят, берничә минутлар шул хәлендә калганнан соң, хәтеренә кинәт бернәрсә килеп төшкән кешенең ашыгычлыгы белән, тәрәзә яныннан китте дә ридикюленнән зур төргәк хатлар чыгарды. Бу хатлар узган кичтә уйналган «почта» уены вакытында алынган хатлар иде. Боларны Хәят, вакытында берәр, хәтта икешәр

кат та укып чыккан булса да, һәммәсен бик тикшереп, яңадан берәр кат укып чыгудан үзен үзе тыя алмады. Хатларның берсеннән башка һәммәсе комплиментлар белән генә тулы иделәр...

Арадан бер хатны Хәят, яңадан укып та чыкмыйча ерткалап, тәрәзәдән ыргытты. Бу хат ирләр язуына охшатып язылган булса да, кызлар язуы икәнен белгертеп тора иде. Мәгънәсе дә кыска: «Сүз юк, сез матур, ләкин үзегезнең мөселман кызы вә мондагы егетләрнең рус егетләре икәнен онытуыгыз гына килешми»,— диюдән гыйбарәт иде. Вакытында бу хат Хәятның бераз ачуын китергән иде дә тиз онытылган иде. Хәзер шул ачу яңадан кузгалды һәм, әүвәлге эчен пошырган сурәткә кушылып, яңа бер сурәт, белемсез, кәефне җибәргеч сурәткә әйләнде... Ул тәртипсез булып бөтен гәүдәсе өстенә таркалган чәчләрен яңадан бер кат иплән кенә көлтәләндереп куеп, менә инде чынлап йоклыйм дигән шикелле иткән генә иде. Михаилның күзгә күренми торган сурәте Хәят колагының нәкъ янына гына бөкрәйде дә, акрын вә уйчан тавыш белән:

— Мин көтәм,— диде. Бер секунд эчендә уй яңадан эшкә керешге: «Чынлап та, Михаилга ни дип җавап бирергә кирәк инде?.. Михаил матур бит, Михаил сөйкемле бит... Мин аны сөямме?.. Мин... Михаилны?.. Михаил рус малае бит ул!» Менә башка шушы соңгы уйлар килгәндә, Хәят кинәт Михаил белән үз арасында үтеп булмый торган чокыр барлыгын сизде... Бакчада, Михаилдан йөгереп качканда, күңеленә килгән китеклекне ул хәзер генә аңлап җитте: «Михаил мөселман түгел бит, ул кяфер бит». Хәятның күңелендә әллә нинди бер салкынлык, сызлавыклыга охшашлы салкынлык туды...

Хәят, чалкан әйләнеп, бер беләген маңгае өстенә куеп ятты да: «Үзегезнең мөселман кызы икәнегезне, мондагы егетләрнең рус егетләре икәнен онытуыгыз килешми»,— дип язылган хатны исенә төшерде...

— Әстәгъфирулла, Илаһи, үзең сакла,— дип, тагы Аллага сыенды... Моннан соң Хәят: — Раббем, соң мөселман егетләре беткәнмени? — диде дә одеялын яңадан ачып җибәрде...

Бервакыт Хәятның башына Михаилның мөселман була алуы уе килеп, күңеленә ләззәтле җылылык чәчә башлаган иде, кинәт җуялды: ул яшь вакытында анасыннан мөселманлыкка чыккан русларның асылып үтереләләр икәнлеген ишеткән иде... Хәят яшьрәк заманында бервакыт Газизә

абыстайдан әллә кайсы мөфтинең руска гашыйк булып, чукынган кызлары турысында ишеткән иде... алар әүвәлдә бик матур булганнар да, чукынгач, йөзләреннән иман нуры китеп, зәңгәрсу акланып калганнар шикелле; алар әүвәл бик яшь булганнар да, чукынгач, карчыкланып, дуңгыз ите ашап утыра башлаганнар төсле тоела иде... Ул, йоклап киткәч тә, тиз генә тынычлап җитә алмады...

Бу вакытта ике фәрештә кояшны алтын зынҗырлар[1] белән Каф тавы артыннан өстерәп чыгардылар: дөнья нурга манчылды; урамнарда тереклек кайный башлады.

Шулкадәр аптыраш, шулкадәр уйлану белән үткәрелгән бу төн Хәятның үзен чолгаган рус җәмгыятенә карашын бөтенләй үзгәртте... Ул, яшьлек теләве буенча, бу җәмгыятьнең сөйкемле егетләрен читкә кагып җибәрә алмаса да, алар белән катнашуын бик гади бер дәрәҗәдән уздырмаска, артык бер мәгънә күрсәтә торган иттермәскә, бары тышкы яктан гына ясап, күңелгә һичбер төрле итеп катыштырмаска тырыша иде.

Үз-үзенә ясап куйган бу рамкасы бәгъзе вакытларда аны бик каты кыса, бик күп уңайсызлыкларга сәбәп була, ләкин ул шулай да бирелми, нинди авырлык белән булса да җиңеп чыга иде.

Бик күп вакытларда аңар яшь йөрәгендә яңа гына туып килә торган бик матур тойгыларны буып ташларга туры килә дә соңыннан күңелне әллә нинди бер бушлык, бер эч пошу каплап ала иде. Ләкин ул һаман үзе билгеләп куйган рамкадан чыга алмый, чөнки ул рамканың як-ягын коточыргыч сакчылар — әллә кайсы мөфтинең чукынган кызларының сурәтләре саклап торалар иде. Ул кызларның әле һаман битләреннән нур суырылып чыгарылып тора: алар әле һаман дуңгыз итен ашап утыралар; алар әле һаман ата-аналарын сагынып елашалар шикелле була иде. Хәят йөрәгенең капкачларын бик ныгытып ябып вә бикләп куя иде.

Менә бу ясалма бикләнү Хәятның бөтен кызлык вакытын күңел ачлыгында үткәрде.

8. Намазны ул булдыра алган хәтле тиз тотты

Кышның озын кичләре, һәрбер уртача тормышлы урта татар өйләрендәге шикелле, Борһан абзый өендә дә бик акрын һәм эчпошыргыч уза иде... Татар йортларында музыка-фәлән

[1] Зынҗырлар — чылбырлар.

шикелле нәрсәләр белән шөгыльләнү юк, иң кимендә, эшсезләр эше хисаплана. Әле бу мин яза торган чакларда татарча китаплар да бер дә юк диярлек дәрәҗәдә аз, булганнары да инде берәр генә кат түгел, икешәр кат укылып беткән...

Хәят бу кич туганымнарына чакырылулы иде. Ул... аягындагы каюлы читекләрен ботинкалар белән алмаштырырга гына тотынган иде, аның янына Газизә абыстай керде һәм, кызының киенә башлаганын күреп:

— Хәзер аш булды, Хәят. Аш ашап, намазыңны укып барырсың,— диде.

Хәят туганымнарында ужин (кичке аш) була икәнен һәм намазны да анда баргач укыячак икәнен сөйләп караса да, Газизә абыстай:

— Һай, кызым, шул намазга ялкаулыгыңнан бик куркам мин синең. Үз бәхетеңне үзең генә киметмәсәң ярар иде. Безнең әти, мәрхүм, бер генә намазны калдырган өчен дә эт итеп тирги торган иде... Намаз калдырганга атаңның да бер дә ризалыгы юк...

Шулай итеп, Хәят, теләсә дә, теләмәсә дә, аш ашарга вә намаз укырга ирексез иде... Намазны ул булдыра алган хәтле тиз тотты...

Хәят үзен көтеп тора торган атка чыгып утырганда, яңа гына чыккан ярты ай кучерның сакал вә мыекларына каткан бәсне яшькелт сыман итеп яктыртып тора иде.

9. Алар безгә, без аларга буласы түгел

Хәятның туганымы Әминә N шәһәрендәге иң бай татар Мостафа Рәхимов кызы иде.

Гыймадов һәм Рәхимов гаиләләре быел җәй көне генә йөрешә башлаган иделәр... Туганымын каршыларга чыккан Әминә аны:

— Ник бу кадәр соңга калдың, туганым? — дип каршы алды да: — Мин абыйга әйтим, залдан чыксын,— дип, туганымыннан алдарак китте.

Хәят, Әминәнең агасы Сәгыйтьтән гади татар кызлары шикелле үк итеп качмаса да, аның белән бер мәҗлестә утырмый иде.

Хәят залга кергәндә, Сәгыйть аны борылып карый-карый чыгып китте. Залда Әминәнең апасы Рокыя, боларның мөгаллимәләре Анна Петровна, җәй көне кечкенә ир балаларын укытып торган, хәзер укый торган шәһәрләреннән бәйрәмнәр

уздырып китәргә кайткан студент Николай Иваныч һәм... бик купшы киенгән бер яшь егет утырып торалар иде. Хәят болар белән күреште... егет кечкенә ир балаларны тәрбияләргә килгән француз икән...

Әминә Хәятны залда озак тотмады, үз бүлмәсенә алып чыкты...

Бүлмәнең сул стенасына эленгән кыйммәтле урман рәсеменә каршы уң стенага бик яхшы рам эченә тыгылган, хатты куфи[1] белән язылган «Аятелкөрси» куелган иде вә, «урман», хатты куфигә карап, көлеп тора, хатты куфи «урман»га карап, кашларын җыерып, ачуланып тора шикелле иде.

Кызлар бүлмәгә кергәч тә, теге француз турысында сөйләшеп алдылар... Әминә французны бик чибәргә куя, бигрәк тә мыегын бөтенләй кырганлыгын бик килешле таба иде. Әминә бу сүзләрне сөйләгәч, Хәят, матур гына көлемсерәп, аңар бармак селкеде дә:

— Степанов мыегын кырып йөри шул,— диде. Әминәнең бит урталары алсу нур белән яктырып китте, ул, ялкынлы тавыш белән:

— Степанов дигәннән, бүген тагы күрәм бит мин аны. Бүген спектакльдә ул да уйный бит,— дип, Хәятның янына ук килде... Хәят туганымының ялкынланганын рәхәтләнеп һәм сөеп карап торды; аннан соң кашларын уйчан гына күтәрде дә:

— Син, туганым, әле һаман белеш түгел бугай аның белән? — дип сорады.

Бу сорау, утлы күмергә сибелгән су шикелле, Әминәне сүндерде... астки иренен йомшак кына тешләде дә берәр минут җавап бирми торды; аннан соң тигез генә тавыш белән:

— Юк, белеш түгел; белешергә теләмимдә: андый егетләрне читтән торып сөяргә генә ярый... Сөй, сөймә, барыбер, туганым, алар безгә, без аларга буласы түгел бит инде,— диде.

Ахыргы сүзләрнең никадәр дөрес икәнлеген Хәят тойгысы белән аңлый иде...

10. Без нәрсәгә әни сүзенә карыймыз?

Купецлар клубында бүген «Ревизор» куелачак, уен тәмам булгач, сәгать өчкә кадәр танецлар булачак иде. Сәгать сигез ярымнар булганда, клубның артык зур түгел залы халык

[1] Хатты куфи — гарәпчә бик матур итеп язу.

белән тула башлады. Икенче рәт эскәмияләрдән җидесен Рәхимә абыстай кызлары вә кунаклары белән килеп биләде...

Пәрдә ачылды. Бераз вакыт узгач, Бобчинский ролен уйнаучы Степанов сәхнәдә күренде. Әминә сискәнеп китте... Аның йөрәге сикерә һәм бөтен гәүдәсе кытыкланган шикелле була иде...

Пәрдә төшкәч, Әминә башкалар туктап беткәнче кул чапты һәм иң ахырдан нечкә генә, сәхнәгә ишетелмәслек тавыш белән:

— Браво, Степанов! — дип кычкырды.

Йөри торгач, бүлмәгә (фойега) чыктылар. Монда халык, шау килеп, бүлмә буенча йөренә иде.

Рәхимә абыстайлар төркеме дә, халык арасына катышып, ул бара торган якка юнәлде... Бераз йөргәч, Рәхимә абыстайлар төркеме бүлмә кырыйларына тезеп куелган эскәмияләргә утырды...

Хәятның матур йөзе бөтен узып баручыларның күзләрен үз төркемнәренә тарта иде.

Ул үз тирәсендәге рус егетләре белән сөйләшеп торганда, бервакыт үз өстенә кемнеңдер бик төбәп караганлыгын тойды да шул караш килгән якка күзләрен төшерде һәм ерак түгел генә җирдә утырган бер студентның үзенә бик тугры, ләкин йогышлы карап торганлыгын күрде. Студент садә генә, ләкин килешле киенгән, ябык кына битле, коңгырт чәчле, яңа гына мыек чыга башлаган егет иде. Хәятның күзләре студентның күзләре белән очраштылар да бер генә минут бер-берсенә карашып тордылар.

Студентның ачыграк кына зәңгәрсу күзләре Хәятта бик матур тойгы калдырдылар: ул күзләр зәңгәрсу хәтфәдән ясалганнар иде. Хәятны кадерләп, тирбәтеп торалар шикелле; студентның йөзендә шул зәңгәрсу хәтфә күзләре булган йөз бик тулы вә бик сөйкемле шикелле иде. Хәят яңадан бер кат күтәрелеп карады. Хәтфә күзләр яңадан аны кадерләделәр, йомшак кына тирбәттеләр...

Ул Әминәнең колагына табарак бөкерәйде дә:

— Кара әле, туганым, әнә нинди сөйкемле күзләр,— диде. Әминә күтәрелеп студентка карады һәм, күзләрен аннан алмыйча гына:

— Бу студентның моңар кадәр һич күренгәне юк иде; чит шәһәрнеке булырга кирәк,— диде.

...Бераз вакытлардан соң Хәят үз төркемнәреннән кузгалган Николай Иванович артыннан хәтфә күзле студентның киткәнлеген күрде дә эченнән генә: «Бу студент безнең белән танышырга тырышып йөри инде»,— дип уйлап куйды...

Хәятның уйлаганы яңлыш чыкмады: хәтфә күзле студент фойега Николай белән бергә, аның белән нәрсәдер сөйләшә-сөйләшә кайтты да Хәятлар төркеменнән ерак түгел бер эскәмия янында гына аннан аерылып калды. Николай Иванович Рәхимә абыстай янына килде һәм:

— Менә шушы карточка иясе, студент, сезнең белән танышырга тели,— дип, аңар бер визитный карточка тоттырды.

Рәхимә абыстай карточканы акрын гына оештырып укыды. Анда русча «Гали Мөхәммәт углы Арсланов. Москва университеты студенты» дигән сүзләр язылган иде. Ул күзләрен олуг сымак кына Николай Иванычка төшерде һәм карточкадан гына аңлап бетмәгән шикелле:

— Ул мөселманмыни? — дип сорады. Николай Иванович:

— Әйе! — дип җавап биргәч; салкын вә кыска гына тавыш белән:

— Мөмкин түгел дип әйтегез,— диде. Әминә:

— Мөселман булса, нәрсә булган соң инде, әни? Безне ашамас бит,— дип карышып караган иде дә, Рәхимә абыстай аны бик кыска туктатты:

— Син мине өйрәтергә яшьрәк әле,— диде.

Хәятка студентның татар икәнлеген белгән минут тормышындагы бик санаулы гына изге һәм җанга якын минутлардан берсе иде. Бу минутта ул күңеле һәм тойгысы белән гомер итеп калды: кинәт зәңгәрсу хәтфә күзләр аңар гаҗәп якын, гаҗәп үз булып киттеләр дә йөрәгенең иң нечкә тамырларына кадәр үтә торган ләззәтле нур чәчрәтеп тора башладылар. Ләкин бу кадерле минут озакка сузылмады. Рәхимә абыстайның «Ул мөселманмыни? Мөмкин түгел дип әйтегез» дигән сүзләрен ишеткәч тә, Хәят, күңеленә һәм тойгысына бөтен көче белән каршы килеп, эченнән генә: «Чынлап та, мөселман булгач, танышып булмый шул инде»,— дип уйлады. Хәтфә күзләр әллә кая, еракка, югарыга киттеләр дә аларга Хәятның йөрәгенең буе җитми башлады. Аларның нуры да хәзер инде Хәят өстенә түгел, әллә кая читкә чәчри иде. Изге, җанга якын минут Хәятның күңеленә тиеп кенә китте дә җуялды... Хәтфә күзләр җуялдылар: алар Хәят өчен түгел иделәр.

Күңел үзенең ирексезлеген һәм әллә нинди бик тупас бау белән буыла икәнен сизенеп пошынды. Хәятның эчендә нәрсәдер, аның үзенә белеш түгел бер нәрсә, күңелнең пошынуы белән сугышырга тотынды...

Хәят тирәсендәге кешеләргә беленерлек булып сүнде...

Пәрдә ачылганчы, Әминә, еш-еш борылып, күзләре белән арттагы эскәмияләрдән кемнедер эзли-эзли утырды да, уен башлангач, Хәятка:

— Әйдә, туганым, уборнаяга[1] барып килик,— диде. Туганымнар, халыкны ерып, уңайсыз гына чыгып киттеләр... Әминә, үткен карый торган, булдыклы соры күзләрен җәһәт кенә уйнатып:

— Без нәрсәгә әни сүзенә карап торамыз соң, туганым? Әйдә, барабыз да теге мөселман студенты белән танышабыз. Аның әни белән танышырга теләве, билгеле инде, безнең белән танышыр өчен генә бит... Мөселман, имеш! Мөселман булса, ни булган соң? Мөселман булса, бигрәк яхшы; шулай бит, туганым? Бигрәк яхшы! — диде. Бу вакытта Әминәнең тулы гына ап-ак йөзе батырлык һәм ирек сөю күрсәтә, ялкынланган үткен күзләре очкыннар чәчәләр иде.

Хәят аптырашта калды: аның да танышасы килә, хәтта бик килә иде. Ләкин ниндидер бер курку күңелен каплый да бөтен батырчылыгын һәм танышасы килү тойгысын югалтырырга тырыша иде. Аның башына төрле-төрле уйлар килделәр: менә ул хәтфә күзле студент белән танышкан да татарча сөйләшеп йөри; менә аның үзен дә, Әминәне дә Рәхимә абыстай карышып танышкан өчен бик ачулана; менә Газизә абыстай һәм Борһан абзый да вакыйганы белгәннәр, алар бик рәнҗиләр, тиргиләр; менә мөселман студент белән танышканны бөтен татар хатын вә кызлары да белгәннәр; алар колактан колакка гына: «Хәят яр сөя икән»,— дип сөйли башлаганнар...

Әминә, Хәятның җавап бирә алмый торганын күргәч, эшкә ныграк тотынды: туганымының култыгыннан тотты да буфет ишегенә таба китте...

Гали буфетта юк иде... Әминә, шыпыртрак тавыш белән:

— Кайда китте соң ул җәфа? — дип куйды.

---

[1] Уборная — юына торган бүлмә.

11. Яшәсеннәр рус кызлары!

Гали Арсланов юридический факультетта укучы татар егете иде. Ул бу шәһәргә берничә көнлек кенә эш белән килгән иде... Бу егет... бары рус гаиләләре белән генә таныш булганга, татар кызлары хакында... аларны кабыгына яшеренеп ята торган әкәм-төкәмнәр шикелле итеп кенә күз алдына китерә ала иде.

Кинәт ул бу шәһәрдә... үз-үзләрен рус кызлары кадәр үк ирекле тота ала торган калфаклы татар кызларын күрде. Бу минут аның өчен онытылмаслык минут иде... Бу калфаклы кызлар аңар әллә нинди якты, нурлы булып күренәләр, болар аңар кардәшләр, якыннар, болар аңар бөтен мөселман хатыннарының коллыктан котылуының алдынгы галәмәтләре булып күренәләр иде... Хәтта бу калфаклы кызларның берсенең (Хәятның) шулкадәр матур булучанлыгы аның җанында әллә нинди милли мактаныч кузгатты. Ул, ничек итеп булса да, бу мөкатдәс кызлар белән танышырга карар бирде...

Гали Рәхимә абыстайның һәм кызларның үзе белән танышуны кабул итүләрендә бер дә шик тотмый иде...

Николай Иваныч килде... һәм:

— Сезнең мөселман икәнлегегезне белгәч, танышырга мөмкин тапмадылар,— диде.

Галинең күңелендә әллә нәрсә җимерелеп төште...

Әле күптән түгел генә аңар мөкатдәс булып күренгән калфаклы кызлар хәзер инде бөтен мәгънәләрен җуйдылар. Галинең зиһенендәге төркем-төркем әкәм-төкәмнәр янына тагы ике әкәм-төкәм кушылды... Гали... үз-үзенә генә ишетелерлек тавыш белән:

— Нәрсәгә миңа татаркалар? Яшәсеннәр марҗа кызлары! — диде дә буфеттан чыгарга ашыкты.

12. Без белешмәсәк тә, белешүче табылган

...Уен тәмам булды. Халык, залның тирәсенә түгәрәкләнеп утырып, танецлар башланганны көтеп калды...

Бервакыт Хәят сөйкемле генә бер кыз белән култыклашып залга кереп килә торган Галине күрде... Җан коры гына сызланды; аның әллә нәрсәсен кисеп алганнар шикелле иде. Хәят, Әминәнең тезенә төртеп, күзләре белән Галине күрсәтте дә:

— Без белешмәсәк тә, белешүче табылган әле,— диде һәм үзе коры гына елмайды...

Гали Хәят белән Әминә өстенә күз салды да, аларның үзенә караганлыкларын күргәч, күзләрен тиз генә янындагы кызга күчерде...

15. Эч пошу

Март числосының бер пәнҗешәмбе киче иде. Борһан абзый ясту намазыннан соң, һәр пәнҗешәмбедәге гадәтенчә, намазлык өстендә килеш моңлы һәм карт тавыш белән кычкырып, «Ля ястәви» укый башлады.

Йортта тавыш-тын бетте... Озак бер догадан соң картлар, сәгатьнең тугыз гына булуына карамыйча, йокларга да яттылар...

Җил бик ачы тавыш белән сызгыра, бик калын тавыш белән үкерә, әле ыжгырынып, бүре улаган тавышлар чыгара, әле җен алмаштырган бала шикелле елый да тагы үкерә, тагы сызгыра, тагы ыжгыра башлый иде... Түбә калайлары урыннарыннан кубарга теләп шалтырыйлар. Яфраксыз агачлар, тагы әллә нәрсәләр шатырдыйлар, ыңгырашалар, өметсез күтәрелеп бәреләләр. Тәрәзәләр чатырдыйлар. Ишекләр яман хәбәр китерүчеләр тарткан шикелле шылтырыйлар иде...

Хәят урынына сеңеп калды: аны курку дисәң — курку гына да түгел, эч пошу дисәң — ул гына да түгел, бер тойгы каплап алган иде...

Башта бу пошыну билгесез генә, курку белән катыш башланды да, минутлар узган саен киңәеп вә шуның белән бергә үк билгелерәк-билгелерәк була барып, саф эч пошуга әйләнде һәм Хәятның бөтен барлыгын каплап алды...

16. Барыбер кайчан да булса бер бармый хәл юк

— Фу, Ходаем, кай җиреннән телгәнмен бит,— дип, Хәят кулындагы кайчысын өстәлгә куйды да хәзер генә икегә кискән батистын карап тора башлады. Батист чынлап та кирәкмәгән җиреннән теленгән иде. Хәят батист кисәкләрен берничә төрле итеп әйләндереп карады, бер-берсе янына китереп бакты, ләкин файда чыкмады.

— Кирәкмәгән җиреннән теленгән, хәзер инде күлмәкнең иң күренә торган бер җиренә ялгау керергә тиеш.

Хәятның кәефе бозылды, ачуы килә башлады да кайчыны бераз арырак төртеп җибәрде, ялгыш киселгән батистларны караваты өстенә атты. Кайчы ялгыш кисүдә, батистлар ялгыш киселүдә гаепле табылганнар иде...

Газизә абыстай мондый эш булып киткән чакларда, йөзенә кәефсезлек чыгарып, Хәятны бераз кыздыра... иде. Ләкин бүген... йомшак кына елмайды һәм...

— Йә, кызым, юкка борчылма. Монысы бозылса, икенчесе бетмәс әле,— диде һәм әллә ничек уңайсызланып кына кулындагы конвертны Хәятка сузды да:

— Менә шушы кешене таныйсыңмы дип күрсәтергә кергән идем әле мин сиңа,— диде дә, бик кирәкле бер эше исенә төшкән сымак, җәһәт кенә бүлмәдән чыгып китте.

Конверт эченнән бер егет портреты килеп чыкты. Башының артынарак киелгән кәләпүше егетнең мөселман икәнен күрсәтеп торганга күрә, Хәят анасының бу портретны күрсәтүе тиктомалга түгел икәнен сизенде: «Яучы килмәгәндә, ана кеше нишләп үз кызына егетләр портреты күрсәтеп йөрсен!»

Хәят портретны бик пөхтәләп карарга тотынды. Аның йөрәкчеге уйнаклап тибә башлаган иде.

Егетнең йөз кыяфәте һәм сынын тотышы, портрет күрсәтүенә караганда, бик сөйкемле иделәр: ачык маңгай, кәкрәебрәк килгән шактый киң кашлар, очлары югарыга каратылып куелган кие вә озын мыек һәм күкрәген киерелдеребрәк, егет сымак торыш Хәятка мәхәббәтле күренделәр.

Егетнең кәләпүшеннән башка бөтен киеме иң соң мода белән европача тегелгән нәрсәләр иде. Портрет иясе бу яктан да Хәятка ошады.

Хәят портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты. Шулай карый торгач, бервакыт аңар егетнең кәләпүше артыграк артка киелгән шикелле тоелды да, ул: «Кәләпүшен бераз алгарак киертәсе бар икән»,— дип уйлады.

Аннан соң, Газизә абыстайның аяк тавышы ишетелгән шикелле булгач, Хәят портретны тәрәзә төбенә ташлады да бүленгән эшенә тотынган сыман итте... Газизә абыстай уңайсызрак елмайды да:

— Таныдыңмы, кызым? — дип сорады.

Хәят, йөзен бер дә үзгәртмәскә һәм тавышын илтифатсыз ясарга тырышып кына:

— Юк, таный торган кешем түгел,— дип, анасына сузды.

Газизә абыстай бу егетнең Г шәһәрендәге Салих Фатихов исемле яшь бай, бик тәүфыйклы вә бик белемле кеше икәнлеген сөйләде һәм берникадәр сүзләрдән соң шул егеттән яучы

килгәнлеген вә шушы бер-ике көн эчендә аңар бер җавап бирергә кирәк икәнлеген дә әйтте...

Хәят иң әүвәл кулына туры килгән бер китапны алды, эченә акрын гына карточканы салды да бакчага чыгып китте.

Бакча киң, җәйге кояш уенчак һәм шат иде.

Хәят... кулындагы китабын ябык килеш тезләре өстенә салып, күзләре белән агачларның яшь яфраклары арасыннан үзенә белемсез бер нәрсә эзләргә тотынды. Ләкин ул нәрсә табылмады. Шул нәрсәнең табылмаганлыгыннан булырга кирәк, кояш, яфраклар арасыннан челтәрләнеп, Хәятның күзләренә төште дә бик ачык итеп көләргә тотынды. Кояш көлә, матур кара күзләр оялалар...

Хәят китапны ачты да яңадан карточканы карарга тотынды. Карточка әүвәлгедән бераз үзгәргән, кәләпүш хәзер, бераз алгарак килеп, кирәкле урынын тапкан шикелле иде.

Бераздан соң Хәят Салихны сөйләтеп карады. Салих әүвәл бас (калын тавыш) белән сөйләгән иде дә, Хәят аны картсынгач, баритон (ачык вә урта калынлыктагы тавыш) белән сөйли башлады. Салих, моннан да күчеп, нәзек тавыш белән сөйләмәкче булган иде дә, Хәят рөхсәт итмәгәч, аны таплап, яңадан баритонга күчте.

Хәят күзләргә дә билгеле бер төс бирергә тырышып караса да булдыра алмады: алар коңгыртлык белән чем-кара арасында билгесез килеш калдылар.

Моннан соң Хәят Салихның йортын һәм йортындагы тормышын күз алдына китерә башлады: йорт Рәхимовларныкына охшашлырак кына бер йорт; эчендә рояле дә бар; Салих һәрвакыт ак якаларын куеп йөри; кайвакытларда, өстәл янына утырып, счет сала; төнге икеләр-өчләрсез йокларга ятмый; ун-унберләрсез тормый... Театрлар, концертларга йөри итеп бер сурәт ясады. Ләкин сурәтләр аермачык чыкмыйлар, әллә ничек томан эченнән генә күренәләр иде.

Хәят карточканы китап эченә салды... Хәят, бер-ике мәртәбә яңадан Салих турысында уйларга тырышып караса да, аны инде булдыра алмады...

Яңадан портретны карарга тотынмакчы булган иде, ләкин бу вакытта ишегалдында Әминә тавышы ишетелгән шикелле булгач, чабып аңар каршы китте:

— Бире, туганым!

Хәят уйчан гына көлемсерәде дә... аңар бөтен бүгенге вакыйганы сөйләп, Салихның портретын тоттырды...

Әминәнең озак һәм дикъкатьле карашында ошатканлык сизелә иде. Кинәт Әминә күзләрен ялкынландырды вә үзе бөтенләй ялкынга әйләнде дә:

— Барамсың, туганым? — дип сорады. Хәят күзләрен уйчан гына елмайтты һәм:

— Барыйммы соң? — дип, сорауга сорау белән җавап бирде. Әминә уналты-унҗиделәрдә үк кияүгә чыкканда, кызлык вакыты бик әрәм кала; бик яшьтән балалар белән җәфаланасы була; боларга искитмичә бармакчы булганда да, холкын, табигатен белмәгән, күрмәгән һәм танымаган, ул сине сөяме, син аны сөя аласыңмы икәнен белмәгән кешегә гомерлеккә хатын булу куркыныч дип уйлый иде...

Хәят та туганымы күрсәткән сәбәпләрне ватты:

— Холкын, фигылен белмәгән кешегә бару, дисең син. Барыбер, кайчан барсаң да, шулай була бит инде ул...— диде дә Хәят, теләгән нәрсәсен әйтеп бетерә алмаган шикелле итеп, сүзен кисте.

Әминә уйга баткан иде. Бер-ике минут тик тордылар.

Моннан соң Әминә кинәт кенә күзләрен Хәятка төзәде дә, батыр вә катгый тавыш белән:

— Бар, туганым, бар! Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк,— диде.

17. Йә әле, син шәпме?

...Ул бүген, көне буе бары шул мәсьәлә турысында, Салихка бару-бармау турысында уйлап йөрсә дә, бер карарга килеп җитә алмады... Бару-бармау мәсьәләсе, Әминә белән сөйләшкәннән соң, бигрәк буталды, бигрәк томаланды:

— Бар, туганым, бар... Портретына караганда бик матур булырга охшый... Портреттан карап бернәрсә дә әйтеп булмый, туганым. Әнә теге шадра Варяны беләторгансың, портретында бернәрсә беленми, менә дигән матур дип уйларсың... Бар, туганым, бар...

Хәят шадра Варяны белә. Ертлач-ертлач шадрасының портретта бөтенләй беленми икәнен дә, чип-чибәр чыга икәнен дә һәм үзенең, Салих шулай булып чыга калса, сөю түгел, аның йөзенә туры карый да алмаячак икәнен дә белә һәм шул белүе белән газаплана иде. Хәят, куркынып, зиһенендәге бу шадра Салихны куарга тотынды һәм, аның китмәгәнен күргәч, үз-үзен мыскыллаган тавыш белән:

— Буламы соң? Килешмәгәнне! «Ул» нишләп шадра булсын? — диде. Болай дигәч, Салих, шадрасы бетеп, портрет күрсәткәнчә матур булып калды. Алай да Хәят, әүвәл бер күрмичә торып, риза булмаска уйлап куйды... Ләкин... кинәт аңар яучылагач кына, кияүгә бару өчен генә танышу оят төсле, мәгънәсез шикелле күренә башлады...

Бу нәрсәләрне уйлаганда Хәят чын-чынлап кызарды да, куллары белән йөзен каплап:

— Юк, юк, булмас, булмас, мәңгегә булмас...— диде. Хәзер инде ул Салих белән никахка кадәр танышуны теләү түгел, Салих үзе танышмакчы булса да, риза була алмас иде...

Бүгенге төн Хәятка, үзенең салкынчарак кына аязлыгы, язлыклы хуш исе эченә төрендереп, катгый бер карар да китерде.

Хәят, һәр көнге гадәтенчә, бакчага ачылган тәрәзәсе төбенә килеп утырды да, бакчадан керә торган салкынча һаваны зурзур йотымнар белән эчеп, әлеге үзенә билгесез тойгының томанлы рәхәтлегенә талды һәм, шул томанлы рәхәтлек эченә төренеп, иртәдән бирле башын әйләндергән мәсьәләне салмак вә тыныч кына чишеп ташлады.

Карар булды: Хәят Салихка барырга риза!..

Айның күтәрелүе белән кыскара барган агач күләгәләре хыялый картина тудырдылар: әнә шул күләгәләр арасында плащка төренгән, башына зур битле кара эшләпә кигән Салих килә!.. Салихның кулында... бер думбрасы бар икән. Ул, шул думбрага бик матур чиертеп, кычкырып җырлап, Хәят утырган тәрәзәгә таба килә икән...

Боларны хыялына китергәч, Хәят чынлап та кытыкланып китте, кызарынды һәм, үз-үзеннән оялып, мендәренә барып капланды да:

— Илаһи, мәхәббәт бир! Илаһи, гомерлек мәхәббәт бир инде! — диенде.

Бу теләк кызлык вакытының иң ахыргы вә шуның белән бергә иң куәтле теләге иде.

1911 ел

Әсәрдәге сюжет сызыклары

Беренче сюжет сызыгы — өч гаилә белән бәйле вакыйгалар.

Гыймадовлар турында Фатих Әмирхан гади татар бае гаиләсе ди. Гыймадовлар — яхшы кешеләр. Хәятның әтисе дә,

әнисе дә тату яшиләр, кызларын яраталар. Шәһәрдә абруйлы гаилә саналалар. Әмма бу гаилә әгъзалары, моннан йөз ел элек бабалары ничек яшәгән булса, хәзер дә шулай яшиләр.

Икенче сюжет сызыгы — Хәят күңелендәге хисләр алмашынуы.

Бу сюжет сызыгы өч вакыйгадан гыйбарәт. Беренчесендә Михаил Хәятны, Хәят Михаилны ярата. Кызда мәхәббәт хисе уянуын автор сандугач сайравы белән бәйләп сурәтли. Михаил Хәятка «ул сезнең өчен сайрый» дигән иде. Хәят, өенә кайткач та, бакчаларында сандугач сайравын тыңлый. Сандугач сайравы кинәт кенә Михаилның сүзләрен исенә төшерә. Мәхәббәт хисенең көчәя баруын автор болай сурәтли:

Бөтен барлык ниндидер рәхәт онытылуга чумды; аллыгөлле нурга чолганган бәхет, яшь канга аралашып, иң вак тамырларга кадәр үтте: бөтен йөрәкне шундый бер ләззәт чолгап алды ки, андый ләззәтне дәртле, моңлы югарылыклы, ләкин тәҗрибәсез яшьлек кенә татый ала вә аның гына әле бер дә алдану ачысын белмәгән гаклы ышаныч белән каршы ала ала.

Ләкин шуннан соң хис белән намус арасында көрәш башлана.

Башта Хәят мәхәббәтендә ниндидер «китеклек» барлыгын тоя гына. Ә бераздан ләззәтле хисләрендәге «китеклек»нең үзенең намусы булуын аңлый. Хәзер шушы «китеклек» үтеп булмаслык чоңгылга әйләнә. Чоңгыл Хәятның намусы икән. Ул — рус егетенә кияүгә чыгуның гөнаһ булуын кисәтә. Хәят борчыла, хәсрәтләнә. Михаилны мөселман итү кебек хыяллары белән юанырга тырыша. Ләкин уе, дәлил өстенә дәлил китереп, юану хисләрен пыран-заран китереп җимерә. Ниһаять, уйлары кызның «матур тойгыларын буып ташлый». Хәят үзендә көчәйгәннән-көчәя барган хисләрен җиңәрлек ихтыяр көче таба. Җиңү — һәрвакыт тантана, шатлык ул. Ләкин Хәятның җиңүе — аның бу тормыш киртәләрен үтә алмыйча җиңелүе, фаҗигасе.

Биремнәр

1. Мясниковлар һәм Рәхимовлар гаиләләренә дә бәя бирегез. Йорттагы тәртипләр турында тулырак итеп сөйләгез.
2. Икенче сюжет сызыгындагы калган ике вакыйга турында сөйләгез.

Нәтиҗә:

Әти-әнисе Хәятны үгетләмиләр дә, ачуланмыйлар да, тыймыйлар да. Иске тормыш аның үзендә, тәрбиясендә, бөтен барлыгын чорнап алган милли хисендә. Аның мәхәббәтенә каршы үз тәрбиясе көрәшә. Хәятның иң зур фаҗигасе — үзенең шәхесен ирексезләүдә, яшьлектә генә була ала торган беренче мәхәббәтеннән ваз кичүендә. Димәк, Хәят, үзенең бәхете өчен көрәшкән саен, бәхетсезлеккә якыная гына бара, үзен үзе җиңгән саен, киресенчә, җиңелә генә бара.

Әсәр ахырында сюжет сызыклары бергә кушыла: хәзер Хәят бер мәртәбә дә күрмәгән, белмәгән, барлыгын да ишетмәгән Салих исемле егетне яратырга тиеш. Шул максаттан чыгып, үзенең хисе белән көрәшә. Моның өчен барлык ихтыяр көчен, барлык хыялын эшкә җигәргә кирәк була. Хәят бары тик шуннан соң гына Салихны үзе белергә теләгәнчә күз алдына китерә ала. Хыялында тудырган егетне яратырга үзен үзе мәҗбүр итә.

Хәят үзе уйлап тапкан мәхәббәт хисенең бәхет китермәвен яхшы аңлый. Шулай булса да шатлана. Күңелендә мәхәббәт хисенең тууына, үзен үзе тагын бер кат җиңә алуына куана. Кыз алдана, ә без, укучылар, аны кызганабыз.

Кеше язмышындагы газаплы, аянычлы кичерешләргә бу кешенең **драмасы** диләр. Димәк, Фатих Әмирхан «Хәят» повестенда үзе яшәгән чордагы кыз бала драмасын сурәтләгән.

Йомгак ясыйк

1. Сез Фатих Әмирханның күп кенә әсәрләре белән таныштыгыз. Әсәрләрендәге эчтәлекләрнең дә, персонажларының да төрле булуын белдегез. Әмма шул ук вакытта әсәрләренең уртак якларын да күрдегез. Аның персонажлары — бар да көчле шәхесләр. Алар үзләренә үзләре чит кеше күзе белән карый беләләр, хаталарын таныйлар һәм үз-үзләрен уңай якка үзгәртү өчен көрәшәләр.

2. Персонажның үз-үзе белән көрәшүе еш кына газаплы эчке кичерешкә әйләнә. Фатих Әмирхан персонажларының эчке кичерешләрен тәмамланган вакыйга, сюжет итә алган.

Бергәләп тапкан әнә шул сыйфатлар **Фатих Әмирхан иҗатының үзенчәлеге** дия алабыз.

Иҗади эш

Фатих Әмирхан Хәятның өч төрле рухи халәтен күрсәтә: башта кыз мәхәббәтеннән үз теләге белән баш тарта. Аннары баш тартырга мәҗбүр була. Ә соңыннан мәхәббәтен уйлап чыгара.

«Хәят» повесте басылып чыккач, авторга күп санлы хатлар килә. Халык Фатих Әмирханнан әсәрнең дәвамын язуын үтенә. Бар да Хәят язмышы белән кызыксына, һәм әдип әсәренең дәвамын яза да. Кызганычка каршы, бастырмый. Кулъязма югала.

Сюжетны дәвам итегез. Хәятның холкы турында Фатих Әмирханның иҗат үзенчәлеген истән чыгармыйча уйлагыз.

«Хәят» әсәре басылып чыккач, Галимҗан Ибраһимов рецензия яза. Сезнең өчен яңа булган жанр белән танышыйк.

> Яңа әсәргә уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтеп бәя биргән язмага **рецензия** диләр.

«Хәят» повестена рецензия

Муллаларга тиеп тә, шәкерт вә мәдрәсә яманлап та, аның авыр тормышын сөйләп тә, җаның-тәнең белән бизәрлек дәрәҗәдә туелган татар ишаны вә татар хәлфәсенең тәмсез вә кызганыч тормышын укый-укый косасы китерерлек мәртәбәгә җителгән. Инде ничек кенә булса да, һич булмаса бер генә сәгатькә, тик бер генә минутка булса да, ул тормышлардан аерып, яңа, ят, рәхәт һәм күңелле галәмгә алып китәрлек вә бик аз гына булса да ял итәрлек вә рухың илә хәл алырлык бернәрсә укыйсы, шуның илә юанасы килә, шул теләнә иде.

Шундый бер дәвердә «Хәят»ның килеп чыгуы бик урынлы булып китте.

Әсәрнең бөтен җирендә җиңеллек, каләм осталыгы, бәйрәм, яшьлек вә шатлык хис кыйлына.

Әүвәлге сәхифәсен ач та укый башла: шунда ук шатлыклы май аеның бәйрәме — якшәмбе килә. Мәгъсум[1] ике дуст, ике фәрештә күрешәләр. Аннан соң дача; аннан сәхрә, табигать, яшьләр, җыеннар. Уен-көлкеләр, сандугач сайравы, яшел чәчәк арасында яшь күңелдән чыккан беренче мәхәббәтләр... Бары да рәхәт, бары да җиңел һәм күңелле.

---

[1] Мәгъсум — гөнаһсыз.

Җиңел вә җитез кулдан, җиңел вә оста каләм белән, матур, җанлы рәвештә язылган бу җиңел хикәяне мин әдәбият мәйданына чыккан яңа бер хадисә[1] итеп карыйм.

Монда мөхәррир үзе фәлән вакыйга булганын сөйләп кенә килми, бәлки каһарманнары үзләре сөйлиләр, кунакка йөриләр, театрга баралар, кешеләр илә танышалар, уйныйлар, көләләр, төннәр була, сандугачлар сайрый. Хасил[2] монда әллә кемнәр хакында кыйсса сөйләнми, бәлки каһарманнар үзләре яшиләр.

Дәхи бер җәһәте: башка күп хикәяләрдәге кеби, башкортның бөтен су буена сузылган озын җыры рәвешендә бер адәм хакында гына кыйсса сөйләнми. Унбиш вә егермеләп адәм кертелә.

Монда Лизаның дачасында әллә ничаклы яшьләр җыела; монда бар Борһан абзый гаиләсе; монда бар Гыймадовлар гаиләсе; монда үзенең вөҗүде[3] илә һәр җиргә нур вә ямь биргән татар кызы Хәят алдында бөтен рус яшьләре сәҗдә итә[4]. Монда берсе, рус студентына гыйшык тотып, тын кичләрдә ялгызы бикләнеп еглый, рус артисты Степановка ерактан вә яшерен мәхәббәт саклап йөри.

Шулар илә әсәрнең сай чыккан җирләре дә күп. Аның картиналары бөтен хәяты илә тулып, җанланып күз алдына килми. Монда яшь күңелләрнең беренче мәхәббәте сыек чыга. Хәят тибының табигый икәнлеге хакында да бик зур шөбһә бар.

Әсәргә «милли хикәя» диелгән. Мин моның яңлышлыгы хакында кул кисеп бәхәсләшә алам. Үзе татар булган өчен генә татар студентын читкә каккан Рәхимовлар гаиләсендә «татар рухы» эзләү габәс[5] булган кеби, Борһан абзый гаиләсенең дә татарлык ягы аз ялтырый.

Хәзергә хикәянең беренче кисәге генә нәшер кыйлынган. Шунлыктан бу хикәядә алынган типларның табигый эшләнеп чыгып-чыкмавы хакында кисеп бер нәрсә әйтеп булмый, аны әсәрнең икенче бүлеге чыкканчыга калдырып торам. Шаять озак көтәргә туры килмәс.

---

[1] Хадисә — вакыйга.

[2] Хасил — бар булу. *Бу урында:* шулай.

[3] Вөҗүде — булуы, яшәве.

[4] Сәҗдә иту — баш ию.

[5] Габәс — буш, файдасыз.

Кәгазе, басылуы бик матур, бик нәфис чыккан. Бу җәһәте илә нәширләре мактауга лаек. Һәркемгә укып чыгарга тәкъдим итәм.

Биремнәр

1. Галимҗан Ибраһимов повестьның уңышлы якларын санап чыга. Ул әсәрнең нинди сыйфатларын мактый? Шул урыннарны табып, дәфтәрләрегезгә мөмкин кадәр кыска итеп языгыз.
   Мәсәлән, Фатих Әмирханны яңа тема күтәргән өчен мактый. Шул рәвешле дәвам итегез.
2. Галимҗан Ибраһимов әсәрнең үзе уңышсыз дип тапкан сыйфатларын санап чыга. Шул сыйфатларны үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз.
   Мәсәлән, күрсәтелгән беренче кимчелекне болай язып була: Фатих Әмирхан әсәрендәге сурәтләр табигый түгел... Галимҗан Ибраһимов күрсәткән башка кимчелекләрне дә шул рәвешчә план итеп языгыз.
3. Галимҗан Ибраһимов күрсәткән кимчелекләр белән сез ризамы? Риза булмасагыз, ялгышын әйтегез.

Галимҗан Ибраһимов

(1887—1938)

Галимҗан Ибраһимов — татар язучылары арасында аеруча күп иҗат иткән, Октябрь революциясенә кадәр үк иң талантлы әдипләрнең берсе итеп танылган язучы.

Ул 1887 елның 12 мартында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе Солтанморат авылында (хәзерге Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) мулла гаиләсендә туган. Әтисе Гыйрфан абзый соңрак муллалыгын ташлаган, гаиләсен игенчелек белән шөгыльләнеп туйдырган.

Октябрь революциясенә кадәр иҗат иткән әдипләрнең тормыш юллары бертөслерәк. Аларның күбесе мулла гаиләсендә туган. Иске татар мәдрәсәсендәге укыту тәртипләре белән риза булмыйча, укуларын ташлап киткәннәр. Барысы да югары уку йортларында белем алу турында хыялланганнар. Мәдрәсә биргән белем белән имтихан тотып булмаганга, төрле курсларда укып йөргәннәр. Казанда хыяллары тормышка ашмагач, уку йортлары эзләп башка шәһәрләргә киткәннәр. Ләкин татар балаларын башка шәһәрләрдә дә колач җәеп каршы алмаганнар. Безнең әдипләр, башлыча, үзләре укып белемгә ирешкәннәр.

Алар берсе дә үз бәхетләре өчен генә яшәмәгәннәр. Гади кешене бәхетле итү юлларын эзләгәннәр. Шул сорауга җавап эзләп, илнең төрле почмакларына барып чыкканнар.

Тормыш юллары һәм максатлары уртак булган татар язучыларының әсәрләрендә тема һәм проблема уртаклыгы булу бер дә гаҗәп түгел.

Галимҗан Ибраһимов та нәкъ шундый ук тормыш юлы үтә. Укыган мәдрәсәсен ташлап чыгып китә. Казакъ далала-

рына, Дагстан чүлләренә, нугайлар яши торган төбәкләргә, Урал заводларына, Одессага, Сухумига барып чыга. Барган җирендә төрле эшләр башкара. Кешеләр тормышын, башка халыкларның гореф-гадәтләрен, холкын өйрәнә. Белем алу теләге белән, Киев шәһәренә китә. Университетка ирекле тыңлаучы булып укырга керә. Монда ул мөселман студентларының яшерен оешмаларында катнаша. Кулга алына. Шул вакыйгадан соң кая гына барып чыкмасын, ни генә эшләмәсен, аның һәр адымы күзәтү астында була.

Галимҗан Ибраһимов Казан һәм Уфа шәһәрләрендә төрле газеталарда эшли. Үзе кайчандыр укып йөргән «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Октябрь революциясе көннәрендә һәм аннан соң, җиң сызганып, революция эшенә чума.

Галимҗан Ибраһимов та,— татар язучыларының күбесе кебек, Сталин режимы корбаны. Ул Казан төрмәсендә үпкә авыруыннан үлә.

Үзенең беренче хикәясен әдип «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дип атый. Әсәр 1907 елда басыла. Шушы өйрәнчек әсәрдән үк Фатих Әмирхан авторның талантын күреп ала: «Менә бу — безнең татар әдәбиятының киләчәге! Менә монда талант чаткылары күренеп тора. Менә бу безгә әле калын-калын милли романнар да бирәчәк»,— дип яза.

Фатих Әмирханның зирәк күңеле ялгышмаган. Галимҗан Ибраһимов дистәдән артык хикәя, «Татар хатыны нилэр күрми» повестен, «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» романнарын иҗат итә. Шуның белән бергә, аерым язучылар иҗатына, татар халкының тарихына, мәдәнияткә багышланган бик күп мәкаләләр яза.

Октябрь революциясен әдип хуплап каршы ала. Революциядән соң аеруча нәтиҗәле эшли. Элек язган әсәрләрен кабаттан эшкәртеп чыга. «Яңа кешеләр» исемле пьесасын, «Тирән тамырлар» романын, «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр» кебек хикәяләрен иҗат итә.

«Кешеләрне ничек бәхетле итәргә?» дигән сорау, Шәриф Камалны борчыган кебек, Галимҗан Ибраһимовны да өзлексез борчый.

«Яшь йөрәкләр» романында ул хакта бер герой: «Бер адәмнәр мохиткә[1] җиңелү түгел, язмыш агымына буйсыну

---

[1] Мохиткә — тирә-юньгә, тормышка.

тугел, мохитнең үзен җиңәләр, язмышны үзләре теләгән якка борып җибәрәләр.

Әмма калганнары... гомер буена мохит вә язмышның колы булалар»,— ди.

Бу сүзләрне Галимҗан Ибраһимов иҗатының фокусы итеп алырга була. Аның персонажлары да тормышның үзен җиңүчеләр яки язмышның колы булалар.

Күп әдипләрне борчыган бәхет темасы, гомумән, бу чор әдәбиятының төп темасы була. «Ә бәхеткә ничек ирешергә?» соравына җавап эзләү төп проблемага әйләнә. Без моны язучы иҗатын өйрәнгәндә күрербез.

«Көтүчеләр», «Алмачуар» хикәяләрендә Галимҗан Ибраһимов та, Шәриф Камал кебек, «бәхетне көтеп ятмыйлар, бәхет кешенең үз кулында» дигән фикер әйткән иде.

Без быел әдипнең революциягә кадәр язган әсәрләрен өйрәнәбез. Бу елларда язучы ничек фикер йөрткән? Ни өчен борчылган? Нинди кызыклы образлар һәм типлар иҗат иткән? Әсәрләрен ничек төзегән? Язучы иҗатын өйрәнгәннән соң, бу сорауларга җавап табачакбыз.

Уты сүнгән җәһәннәм

I

...Төн. Сәгать ике. Мин зур, караңгы өйнең аулак бүлмәсендә ялгызым утырам. Баярак лампа яна иде. Хыялның чәчәкләнүенә манигъ[1] булганга, аны сүндердем. Бүлмәнең карт агачлар белән тулган зур бакчага караган бердәнбер тәрәзәсе бар... Күзләремне тышның куе һәм шомлы караңгылыгына юнәлдергән хәлдә, төннең тынлыгына күмелеп тик кенә утырам...

Баярак күк күкри, куәтле яшен яшьни, каты җил дә исеп куя, ара-тирә калын, катлаулы болыт артыннан тулган ай карап, бөтен дөньяга матур гына бер елмая да тагын югала иде. Инде бары да тынды. Ай да яңадан күренмәслек булып катлаулы болыт артына ышыкланды. Дөнья тагын да тирән, куе караңгылык эченә күмелде. Күк йөзе тәмам капланып, яңгыр коярга тотына.

---

[1] Манигъ — киртә, комачау итү.

...Йокы каядыр качкан. Шул тигез, вак һәм туктаусыз коелган яңгырны озак, бик озак тыңлыйсым килә; йөрәгемне кайнаткан, җанымны дулкынлаткан бүгенге вакыйга уңае белән очсыз-кырыйсыз хыялга ихтыярсыз тартылып барам. Мин, гомумән, төнге яңгырны бик яратам... Рухымның әллә кайчаннан бирле эзләп тә таба алмый йөргән теләге шул вакыттан, шул караңгы төндә өзлексез коелган вак яңгырның шыбырдавы астында табылгандай тоела. Шуның тәэсирендә бай вә киң бер хыялга чумып, барын да онытам... Бу вакытның хыялында да аерым бер тәм, бөтенләй башка булган бер ямь була...

Бу көн, хосусый бүгенге көн исә рухымны бик тирәннән дулкынландырган башка бер вакыйга да бар.

Биремнәр һәм сораулар

1. Укыган беренче бүлекнең иң әһәмиятле өлешләрен генә калдырып сөйләү өчен план төзегез.

> Әсәрдә тема, сурәт, вакыйга, сүз кабатланса, эчтәлек табу өчен ачкыч була ала.

II—III

Иртәнчәк хатыным белән тәмләп кенә чәй эчеп утыра идем... Кинәт бер кыңгырау тавышы ишетелде... Шул минутта берничә малай, күзләрен акайтып, безнең өйгә чабып керделәр дә, берсеннән-берсе ашыгып:

— Мулла абзый, мулла абзый!! Сезгә зимский нәчәлник килде,— дип акырыштылар...

Яңа тарантаска җигелгән ике яхшы кара атны, әйбәт киемле кучерны, арбага ята төшеп утырган, бөтенләй европача киенгән алтын күзлекле русны күреп, башта эчем жу итеп китте. Ләкин... Ни күзем белән күрим — земский дип каршыларга чыккан адәмем бөтенләй башка кеше, үземнең яшьлек елларымның күбен бергә уздырган бер танышым булып чыкты.

Мин мәдрәсәдә чагымда... байларча гына яши идем... Мин, әлбәттә, үзем самовар куеп, пешеренеп йөрмәдем. Минем мондый эшләремне бер ярлы ятим шәкерт үти, ул бичара акча алмый, тик тамак ялына эшли иде.

Бу шәкертнең йөзе күңелсез, өсте-башы һәрвакыт ертык һәм керле булганга, сабакка да чамалы күренгәнгә, аны

бер дә санга сукмыйлар иде... Аның урыны мич буеннан күчмәде... Аны һәммәсе кимсетәләр... исеме белән дәшмичә, башы зурлыктан «Тубал» дип кенә йөртәләр иде...

Ул бер елны үзгәреп китте, һәрвакыт сагышка батып йөри башлады...

Уразаның егерме җидесендә Кадер кичәсе булды... Кайтсам, Тубалдан җилләр исә, әйберләре дә күренми... Шул юктан юк.

Мин үзем тагы малай таптым; шул көннән аны исемнән чыгарып, инде исемен дә оныткан идем... Каршымда теге алтын күзлекле франт адәм эчендә шул Тубалны таныгач, шаша калдым... Ул уйга килмәслек дәрәҗәдә үзгәргән... Аңа хәзер Тубал дигән исем ятмый да...

IV

Аның чын исеме Гыйльман икән, фамилиям — Каһиров, ди. Ул, миндә кичкә чаклы торып, кояш баер алдыннан гына китте. Кыш көне шәһәрдә укуда булып, җәйлигә безнең күрше авылдагы бер байның балаларын укытырга килә. Миңа шунда барышлый кергән. Аның белән күп һәм иркен сөйләштек. Бигрәк ул сөйләде... Адәм үзгәрсә үзгәрә икән, Ходаем! Ул бөтенләй икенче кеше булган — ул ачык, ул мәдәни, ул белемле. Аның башыннан әллә ниләр кичкән. Ул, безнең мәдрәсәдән киткәч, казакъ хаҗиларына ияреп, Мәккәгә барган, аннан, кире Истанбулга килеп, мәктәптә берничә ел укыган да, Русиягә кайтып, мөгаллимлек кылган. Соңра фикере үзгәреп, мөгаллимлектән җыйган акчасы белән русча укырга тотынган. Шуннан бирле һаман укыган, әле дә укый. Ни турында гына сүз чыкмасын, миие күмә дә ташлый... Мин үземнең бернәрсә дә белмәүне, минем һәр сүзем коры «авыз фәлсәфәсе» генә идеген бүген Каһиров белән сөйләшкәннән соң ачык белдем... Ул алдагы көннәргә бөтенләй икенче төрле карый... Ул ерак югары һәм алга омтыла... хәяттән алуы мөмкин булган насыйбына[1] ирешергә үкереп бара...

2. Икенче — дүртенче бүлекләрне дә, кыскартып, иң әһәмиятле өлешләрен үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз.

---

[1] **Насыйбына** — теләгенә.

V

Мин бик бай хыяллы, хәяттан бик күп нәрсә өмет итүче адәмнәрдән бере идем. Халык хезмәтчесе булу минем баш теләгем иде. Мин ул чакта алдымда бик күп, бик олуг эшләр, мәртәбәләр[1] барлыгына ышана, шуңа омтыла идем...

Була вакытлар: ачсың, эчең тырный, бер кабым икмәккә мохтаҗсың, ә шулвакыт хыялың барлык авырлыкларны оныттырып, алдагы нәрсәләр белән җуата. Лампаны басып куясың да киләчәкне уйларга тотынасың. Ул төрлечә күренә: кайбер вакыт үзеңне... атаклы бер галим ясап, яки халыкның мәдәни күтәрелүе юлында иң зур урын тоткан бер адәм итеп уйлыйсың. Ләкин һичбер тәкъдирдә, ялгыш кына үзеңне бер караңгы авылга мулла булып... гомер итүең уйланмый...

Менә мин хыялым белән шундый идем... Ни дә булса булган, мин, күктән егылып, әллә кая төпкә, астка, коточкыч түбәнгә киткәнмен... Хәят мәңгелеккә җимерелгән, алдагы көнең хәзергедән дә күп түбән, күп караңгы булыр шикелле тоела, шул йөрәгеңне яра.

VI

Салмак кына, тигез һәм әкрен генә шыбырдап торган яңгырны тыңлый торгач, мин бик әз генә шагыйрь дә, бик әз генә фәйләсоф[2] та булып китәм бугай... Уйлыйм: ничек, дим, табигать хозур. Бүген көн буена аяз булды... Дөнья рәхәтләнде, көлде... ләкин бу бәхет озакка бармады, кичкә таба болыт чыкты. Дөньяны яшен-гөрелте, ут, куркыныч караңгылык каплады. Яңгыр башланды, әле һаман да коя. Менә тагы иртәгә... тагы якты, шат көн туар... Шулай итеп, табигатьтә ямь белән тәм алышынып тора... Ә бездә, адәмнәрнең хәятында, алай түгел. Безнең хәятыбызда «яз» кыска... Алгы көндә ничек булуымны хыялым ирексез эшли: балагы чыккан, иске җилән киеп, үзе ышанмаган җәннәткә халыкны өнди торган бер мулла.

Зиһенемә шагыйребезнең, заманында ятлап та, әллә кайчан оныткан бер шигыре килә:

Караңгы һәм дә таңы ерак,—
Уты сүнгән җәһәннәм минем төн.

---

[1] Мәртәбә — дәрәҗә.
[2] Фәйләсоф — философ. *Бу урында:* галим.

...Ул, ул — уты сүнгән җәһәннәм — мине көтә.

Яңгыр туктады. Баягы тынлык бетеп, болытлар катлаулана, җил тагы сызгыра башлады... Йөрәк ашкынып, яңа бер куәт белән сикерә, ни өчендер баягыча баягы урында тын гына утырасы килми... Үзеңнән үзең риза булмаучылык чигенә җитә... Уйлыйм, тәмуг, дим, юктыр, булса — минем хәзерге минутым үзе тәмугдыр.

Минем уем нәкъ шул җиргә җиткән чагында, куәтле бер яшен яшьни, бөтен дөньяны сәер бер яктылык ала; вә шул яктылыкның караңгылык белән аралашып киткән актык секундында хыялымда өзгеч бер күренеш ялтырап китә, гүя мин, нурдан егылып, чиксез караңгы төнгә, түбәнгә, коточкыч астка киткәнмен дә, шуны аңлап, кабаттан өскә чыгарга талпынам, ләкин куәт юк, канат кисек булганга, кире йөзтүбән, әүвәлгедән дә тәпкәрәк китәм, имеш...

Тагы бер кат яшен яшьнәде дә, коеп яңгыр яварга тотынды.

Мин дә, авырып, ватылып, гәүдәмне чак өстерәп, хатыным янына барып яттым.

1911 ел

3. Соңгы бүлектә Садыйк үзенең рухи халәтен җәһәннәм ди. Ни өчен җәһәннәм ди?
4. Садыйкка һәм Гыйльманга бәя бирегез. Алар холкындагы төп сыйфат нинди? Садыйк кичерешләренең эчтәлеген сөйләгез.

Хикәянең эчтәлеге

«Уты сүнгән җәһәннәм» — үзенчәлекле әсәр. Аның сюжеты юк диярлек. Садыйк авылда үз тормышыннан бик канәгать булып, балалар үстереп яшәп ята. Көннәрнең берендә ул үзенең яшьлек танышы, сабакташы белән очраша, һәрьяктан да үзеннән түбән булган шәкерттәше хәзер белемле, әдәпле бай кешегә әйләнгән. Садыйк аның алдында чүп кенә булып калган.

Берничә юлга сыярлык бу вакыйга Садыйкның тыныч күңелендә мәхшәр тудыруга сәбәп була. Хикәянең күп өлеше шул мәхшәрне, ягъни геройның кичерешләрен, уйларын тасвирлауга багышлана.

Лирик әсәрләрдә без хисләрнең дәрәҗәсе сурәтләнгән урыннарны, эчтәлекне ачкан сәбәпләрне эзли идек. Бу юлы да шулай итик.

Үзен Гыйльман белән чагыштыру геройда көнчелек хисе уята. (Хис сәбәбе.) Кайчандыр үзенә самовар куеп йөргән малай шул дәрәҗәгә житсен әле! Ә ул, Гыйльманнан яхшырак укый торган шәкерт, надан мулла булып калган. Садыйк Гыйльманның уңышка фәкать ихтыяр көче, тырышлыгы аркасында гына ирешүен белә. Ул үзенең җебегән, булдыксыз, җил уңаена гына баручы кеше икәнлеген аңлый. Шулай итеп, герой хисенә тагын бер хис — үзеннән ризасызлык хисе килеп кушыла.

Садыйк хатасын аңлый, әмма ул аны бервакытта да төзәтә алмаячак. Моның өчен аның дәрте дә, ихтыяр көче дә юк. Гомер узган, көч беткән. Көнчелек хисенә өметсезлек хисе кушылды.

Герой чынбарлык тудырган бу авыр тойгыларыннан арынмакчы (юану) була. Зур өметләр, теләкләр белән тулы дәртле яшьлеген исенә төшерә. Хыялында үзен халык азатлыгы өчен көрәшүче егет итеп күз алдына китерә. Кыюлыгы өчен төрмәдә утыруы, чыккач аны бар да зурлап каршы алулары турында хыялый вакыйга уйлап чыгара. Ләкин чынбарлык тудырган ризасызлык, көнчелек, өметсезлек хисе хыял юанычыннан көчлерәк булып чыга.

Хикәянең төп вакыйгасы, димәк, иске таныш белән очрашу түгел. Очрашу Садыйк кичерешләренең бер сәбәбе генә. Гыйльман турында автор, гомумән, бик аз яза. Вакыйгада Садыйкның уйлары, кичерешләре чагыла. Бу очрашуга кадәр дә ул, лампасын сүндереп, төнлә тәрәзәдән яңгыр яуганны карап торырга яраткан. Нигә караңгыда? Нигә төнлә? Хисләренең һәм уйларының чынлыгын ул, күрәсең, башкалардан да, үзеннән дә яшермәкче буладыр.

Икесендә дә бөтен дөньяны яшен яшьнәтеп яктырта. Садыйк яшен яктысын яратмый. Ул, гомумән, яктылыктан курка. Яктыда аның уйдырма хисләренең ялганлыгы күренә. Садыйк тормышындагы караңгылык, күңелсез бертөрлелек эченә Гыйльманның килеп керүе яшен яктысы кебек тәэсир итә. Садыйкның бөтен тормышы, уйлары, хисләре ялган булуы ачыла.

Хикәя вакыйгасы, димәк, геройның уйларыннан, кичерешләреннән гыйбарәт икән. Хикәядә кабатланган караңгылыкның да, яшен яктысының дә мәгънәләре бар — алар метафора.

Күңел дөньясы

Кешенең уй, хис, хатирә һәм хыяллары бәйләнешенә аның **эчке дөньясы**, яки **күңел дөньясы**, диләр.

Эчке дөнья тормыш чынлыгыннан ерак та, аңа бик якын да була алуын күрдек. Шул аермадан чыгып, кешеләрне **романтиклар** һәм **реалистлар** дип ике типка бүлеп йөртәләр.

Үзегезнең көндәлек тормышыгызны гына күз алдыгызга китерегез. Бер көн эчендә, әйтик, әллә ни зур вакыйга да булмаска мөмкин, ләкин шулвакыт эчендә сез берничә мәртәбә шатланырга да, көләргә дә, борчылырга да, көнләшергә дә, үкенергә дә, кемгәдер бәя бирергә дә өлгерәсез. Кызганычка каршы, башкаларга бәя биргәндә, без үзебезне алардан акыллырак итеп күрсәтергә тырышабыз. Көненә әллә ничә мәртәбә «их, башкача эшлисе калган икән» дип, үткән вакыйганы уебызда яңача оештырабыз. Уй һәм хис белән әнә никадәр эш башкарабыз. Ул уйларның һәм хисләрнең уртасында, әлбәттә, сез үзегез торасыз. Сез үзәктә, ә башка вакыйгалар, башка кешеләр сезнең тирәдә әйләнеп йөриләр. Шул вакыйгаларга, кешеләргә бәя биргәндә, билгеле, үзебезгә дә бәя бирәбез. Нинди бәя бирәбез? Һаман үзебезне аклыйбызмы, башкалар алдында юк сыйфатны бар итеп күрсәтергә тырышабызмы? Әллә үзебезнең хатаны үзебез күрә алабызмы? Ә бит без әле шуның өстенә башкалар миңа нинди бәя бирә икән дип тә уйлыйбыз. Болар барысы да — безнең эчке дөньябыз.

Кеше үзенең күп гомерен эчке дөньясында яшәп үткәрә. Бер карасаң, укучылар бар да бер үк нәрсә белән шөгыльләнәләр. Иртән битләрен юалар, ашыйлар, мәктәпкә укырга киләләр, күп мәктәпләрдә хәтта бер үк төсле кием дә кияләр, дәрес әзерлиләр, өйдә зурларга ярдәм итәләр. Ләкин аларның һәркайсы башкача уйлый, башкача кичерә, борчыла, үзенчә алдагы көнгә, җәйгә, кышка планнар кора, үзенчә хыяллана. Кешеләр хәтта бер үк нәрсәне дә төрлечә күрәләр.

Ихтыярлы кешеләрнең эчке дөньясы чынбарлык тудырган хисләргә җавап рәвешендә генә яшәми. Ихтыярлы, акыллы, эшчән кешеләрнең эчке дөньясы тормышның үзен үзгәртә. Галимҗан Ибраһимов татарлар тормышында Садыйктай буш хыяллы, тормышка җайлашып кына яшәүче типлар күп булганга борчыла да. Кызганычка каршы, Садыйктай кешеләр безнең арада да бик күп.

Карт ялчы

Ул елны ике читенлек бергә җыелды. Ашлык искиткеч уңган иде. Шуңа үч иткән кебек, көз бик иртә килде, ничаклы тырышсак та, көннәр корырак чакта игенне ындырга кертеп бетерергә өлгерә алмадык.

Сентябрьнең ахырлары җитеп килә, бу вакытта башка елларда ындырың зур-зур кибәннәр белән тулган була; син шуларга карап, күңелләнә-күңелләнә, суык кышны каршы алырга хәзерләнә башлыйсың.

Ягарга утын китерәсең, өйләрне әйбәтләп ябасың, сылыйсың, ишек, тәрәзәләрне төзәттерәсең, җылы тотсын өчен, яхшылап эргә[1] саласың, арбаларны ныгытасың; тары, карабодай кебек, көзге өлешкә дип чәчелгән ашлыкларны сугып, келәтнең өсәкләрен[2] тутырасың. Аның өстәвенә алу-салу өчен, өй кирәк-ярагы өчен бер-ике йөк ашлык белән калага да барып кайтасың.

Көн-төн эшлисең, җаның рәхәтләнә, аруның нәрсә икәнен дә белмисең.

Ә бу ел... бу ел... ят та үл.

Бөтен басуны, әрәмгә бирелгәндәй күп булып, иген чүмәләләре тутырып утыралар. Ай буена өзлексез яуган яңгыр аларның төпләренәчә үткән: көлтәнең өсте үрә, төбе чери. Җитмәсә, тагы мал чыгып та бик харап итеп бара.

Ике җир бодай бар иде. Ходайның кодрәтенә исең китәр, шулай шәп булып үскәннәр, бу ел арыш икмәге капмабыз, бодай гына ашап чыгарбыз, дип шатланышып тора идек, мал аңар да җитеп бара.

Берничә мәртәбә тотып алып кайткан идек, аннан да файда чыкмады.

Сыеры артыннан мужик бер килә, ике килә, һаман да бирмәгәнеңне күргәч, үзеңне эт урынына сүгә дә:

— Мәңге асрый алмассың әле! — дип кайтып китә.

Аптырагач, иясенең түләп алуыннан өмет өзгәч, сыерны кызгана башлыйсың, ахырда:

— Бу хайванның ни гөнаһы бар? Аны ач тотып ни файда? — дисең дә чыгарып җибәрәсең.

---

[1] Эргә — өйнең тышкы стенасы тирәсенә туфрактан өелгән нигез.

[2] Өсәк — ашлык салу өчен ясалган бура.

Шулар белән борчылып, җаныңны кая куярга аптыравың җитмәгән кебек, тагы бөтен нәрсәсе сиңа каршы төшә. Кояш рәтләп чыкмый. Күк йөзе куе соры болытлар белән каплана. Болар, тау башларына тиеп-тиеп үткән кебек, түбәннән бертуктаусыз агалар. Азрак ачылды бугай дип, атыңны җигеп чыгарга өлгерә алмыйсың, нечкә иләктән сибәләгән кебек, вак кына яңгыр ява башлый.

Яуса явар, яланда калганчы, ындырында чересен, дисең дә, болытына, яңгырына карамастан, атыңны арытып, арбаңны, сбруеңны вата-вата, шул пычракта ташый бирәсең...

Әле дә ярый атлар таза, аларның алдыннан солыны өзмибез. Барганда да, кайтканда да, бушаткан-төягәндә дә көлтәдән башларын алмыйлар.

Башка вакыт көненә дүрт-биш юл бара торган булсак, хәзер басу артындагы җирләрдән алтышар-җидешәр урыйбыз. Шулай булса да атай карт канәгатьләнми. Син чыланып, эштән чыгып кайтасың, ул, хәл сорашып, безгә булышу урынында, ачулы йөз белән каршы чыга да, озын кашларын салындырып:

— Йөрисез шунда ат этләп! Ныграк төяргә кулыгыз чересгәнмени?! Әллә анда баргач йоклап ятасызмы? Сез бер юл кайтканчы, Җамали малайлары икешәр урыйлар!..— дип сукрана башлый.

Аның сукрануына җавап та бирмичә, сикереп кибән башына менәм; энем көлтә бирә, күз ачып күз йомганчы, дүрт-биш арбаны бушатып та ташлыйбыз; куенга бер кисәк икмәк белән берничә бәрәңгене кыстырып, тагын чыгып чабабыз.

Әни, бичара, безне кызганып, самоварын куеп көткән була. Үзенчә, өшеп, күшегеп кайткан улларын чәй белән җылытып җибәрмәкче. Әтинең ачулы йөзен, салынган кашын күргәч, ул да эчтән тына, чәйгә керегез-фәлән дип әйтергә курка.

Чәй кайгысы түгел әле, ничек кенә булса да тизрәк ташып алырга кирәк. Туры килсә, аягүрә генә бер-ике чынаякны аударасың, булмаса, шул икмәк, бәрәңге белән дә бик шәп йөрисең.

Туктаусыз чабудан, йокысызлыктан, яңгырдан бер дә кеше төсе калмады. Өс-баш пычрак, күшегүдән йөз күгәреп, сары йон белән капланган.

Юлларның начарлыгын әйтергә дә юк: пычрак, тайгак, күперләр бозык, юл саен диярлек камыт бавы, тәҗе өзелеп, арба ватылып, теңкәңне корыта. Тау як көлтәсе бигрәк җанга

тия. Анда юллар тигезсез, чокыр-чакырлы. Арбаң аз гына кырын килсә, чана кебек тыз-тыз итеп, тау асты ягына таба китә башлый. Без, бернәрсәгә дә карамастан, һаман чабабыз гына.

II

Син ашыкканда, ул кабалана, диләр. Ашау-эчүеңне онытып, берүзең кырыкка ярылырдай булып йөргәндә, энем, арба башыннан егылып төшеп, уң кулын имгәтте.

Сынганга охшамый, шулай да кара янып, күгәреп чыккан, бераз шешенеп тә тора. Үзе, кулының имгәнүенә карамастан, барырга теләсә дә, мин якын килмәдем:

— Дөнья куам дип чулак булып калыр хәл юк инде; үзем дә ташырмын әле, кулы әзрәк төзәлгәнче өйдә ятсын!

Берүзем дүрт ат белән кичкә каршы көлтәгә барырга булдым. Марҗа басуындагы солыга күрше малы кереп, харап итеп бара. Бүгеннән калдырмый шуларны алып кайтырга кирәк.

Яңгыр яварга чамалап тора. Башка вакытта: «Аз төйисез, акрын йөрисез!» — дип сукранган атай бүген нидәндер бераз йомшарган күренә.

— Атларың да бик өшәнгән, якындагы солыга гына барырга кирәк иде,— ди.

Мин аңа карамадым, фурманга[1] аягүрә бастым да, ут чыккан кебек, чаптырып чыгып киттем.

Безнең атлар начар түгел: таксаң да, буш җибәрсәң дә, бер дә арттан калмый баралар. Энем капкадан чыгаруга:

— Әйдәгез, малкайлар! — дип бер кычкырдым. Шуның белән һәммәсе, җепкә таккан туплар кебек, минем арттан тезелеп очалар гына.

Барачак җирем алты чакрымнар булыр. Ахрысы, бик артык шәп каулаганмындыр: кояш та батып өлгермәде, мин солыга килеп җиттем. Элекке заманның арбалары булса, эш озакка тартылыр, бер кеше төяп, бастырыклап беткәнче, әллә ничаклы вакыт үтәр иде; хәзерге фурман арбаларга көлтә төяве — бу уен гына.

Килеп тә җиттем, күз ачып күз йомганчы дигәндәй, бер арада дүрт арбаны төяп, кайтыр юлга да чыктым. Атларны кызганып, шунда кунарга да уйлаган идем, төн ягыннан явып килгән төсле күренгән кара болытлар куркытты; яуса, көлтә

---

[1] Фурман — арба.

юешләнеп, эштән чыга. Кайтсаң, ичмаса, бушата алмасаң, бер ышык җиргә кертеп куярсың.

Кайтуы кайту инде, анысы — өйрәнгән эш. Юлымда «Яманташ» дигән бер тауны үтәсе бар. Моннан мендерү көн коры чакта да бик җиңел булмый. Хәзерге кебек явым-чәчемле вакытларда бу инде сират кичүдән бер дә ким саналмый.

III

Бүген төштән соң яумады. Шуңа күрә мин, юл бераз сүрелгәндер, атлар акрынлап мендерсәләр кирәк дип, үземне юатыбрак килә идем, эш мин уйлаганча барып чыкмады.

Мин тауга килеп җиткәндә, анда инде бер көтү халык арбаларын мендерә алмыйча газапла免алар иде. Садыйк мәзин малае Вәликәй өч аты белән килеп капкан. Бу — авылда атларының яхшылыгы белән исем чыгарган кеше. Аның алдында тагы байтак атлар бар. Һәммәбез җыелып, алдагы атларны берәм-берәм мендерешеп озаттык. Нәүбәт Вәликәйгә килде.

Мин аның атларының җиңел алып менеп китүләренә бик нык ышанган идем; көн-төн көлтә ташу белән бераз өшәнгәннәр, ахрысы, малкайлар: башта каулап карадык, алай булдыра алмагач, яннарыннан булыша башладык. Юк, эш чыкмый.

Арада Әхми байның ялчысы Шаһи карт та бар иде. Бабай атларының арбаны тартырга тырышып та кире артка таептаеп китүләренә карап торды да:

— Вәликәй, кая соң синең кара атың?! Ул мендерер,— диде.

Егет кулы белән өченче арбага күрсәтте:

— Ул артта шул!

Бабай үзенекен куймады.

— Бар, кара атыңны тугар да, менә бу алдагы арбага китереп җик, ул мендерер,— диде.

Арбалар тау астына таба кирегә тәгәрәп китмәсеннәр өчен, тәгәрмәч асларына агачлар кыстырдык, тиз арада кара атны алдагы арбага китереп җиктек.

Ну, көч бар икән соң малның үзендә! Җигеп «наа...а!..» дияргә өлгерә алмадык, кара ат «эһ» тә димәде, арбаны җилтерәтеп алып менеп китте.

Шаһи карт, тирән бер горурлык белән:

— Әйттем бит мин сезгә! Бер тартуы меň сумлык бар бу малның! Гәрәй карт бияләренең баласы шул ул! — диде.

Үзенең өч арбасын мендергәч, Вәликәй атларын яңадан җикте дә кайтып китте.

Ул: «Сезнең арбаларны да мендертик!» — дигән иде, бабай бер дә якын килмәде:

— Беләм мин синең мәзинеңне! Ул мәзин түгел, мукшы ул, саран мукшы! Әле дә, ни эшләп болай соңга калдың, дип җаныңны алыр. Бар, тукталма, без үз көнебезне үзебез күрербез,— диде.

Мин дә шуңа кушылдым: кара ат көчлесен көчле, шулай да бит, көчле дип, бөтен авылның көлтәсен аңардан тарттыру килешми инде. Шаһи картныкы — ике, минеке — дүрт. Боларның барлыгын бер кара атка өстерәтү — бу инде бер дә ярамый.

Минем үземнең «Ахун» исемле зур туры атым бар. Ул Вәликәйнең карасына бирешмәс дип уйлыйм. Мендерә алмыйлар икән, яланда куну да бит күрмәгән эш түгел.

Вәликәй киткәч, үзебезнең атларны кузгата башладык. Алда Шаһи картныкылар, аның атлары бик йончу. Шулай булмый ни эшләсен, ялчы кулындагы ат әллә кая китә алмый инде. Аның бае Әхми — бик саран нәрсә. Атларга бер солы көлтәсен артык биргән өчен дә, дөнья чаклы тавыш куптара торган адәм. Бу атларның мендерүләренә күңелем җитми. Шулай да, ятып калганчы атып кал дип, атларны кауларга тотындык. Аркалыкларын төшергән булдык, яннарыннан тартышып карадык. Юк, булмагач булмый инде. Безнең акырып-бакырып һайдалавыбызга карап, атлар бер генә атлыйлар да таеп тезләнәләр, егылалар, бабайның мендерүгә күп дәрте күренми. Минем димләвем белән аз-маз кузгалса да, бөтен сүзе, торышы белән:

— Барыбер булмый, хайваннарны юкка азаплыйсың! Иртәгә дә көн безнеке бит! — дип тора.

Минем болай тиз җиңеләсем килмәде. Картның ай-ваена карамыйча, Ахунны тугардым да бабайның алдагы арбасына китереп җиктем. Вәликәйнекеннән ким булмады, җигүгә арбаны шатырдатып алып менеп китә башлады.

Фу... каһәр төшсен, саран байның рәтле сбруе буламы соң аның!

Җенләндереп инде мендереп җиттем дигәндә, сул як тәҗе өзелде, аның артыннан сул як тәртәнең әллә нинди җепләр белән генә бәйләп куйган төбе ычкынды да, арба көлтәсе-ние белән тау астына очты. Әле дә ярый, кендек буш икән, юкса минем атны да өстерәр иде.

Мин әрнүемнән:

— Чукын, җәһәннәмгә кит! — дип сүгенеп калдым. Карт, бер дә исе китмичә, аптырамыйча, бик озын сузып, мине шелтәли башлады:

— Әйттем бит сиңа, юк белән маташасың, Сәфәр... Яшьлегеңә барасың!..

Инде ни эшләргә? Карт белән җаваплашып вакыт уткәрү ярамый.

— Ярый, бабай, эш синеңчә булды! — дидем дә атларымны юлдан бер як читкәрәк чыгарып тугара башладым.

Төн караңгы; мондый вакытта әллә кая чокырга очкан арбаларны чыгарып маташмассың бит инде. Безгә шунда кунарга туры килә.

Үлән бик шәп, атлар рәхәтләнеп ашасыннар. Кара бия — бик йөремтәл нәрсә, ничаклы кыска тыпаусаң да, ничаклы ач булса да, аяк астындагы үләнгә карамыйча, әллә кая китә. Аның артыннан башкалар да иярәчәкләр. Кунарга дип чыкмаганга, минем тышавым да, кешәннәрем[1] дә юк икән... Инде моңа гына калса, бер чарасы табылмый булмый: нукталарның тезгеннәрен алдым, тышау да чыкты, кешән дә булды.

Эшне бетереп арбалар янына килсәм, Шаһи бабай бер атын да тугарып бетә алмаган әле.

— Нихәл, бабай? Нишләп син болай озак маташасың?

Карт ялчы, кемгәдер, нәрсәгәдер рәнҗегән тавыш белән:

— Сөйләмә инде, Сәфәр балам, бер картайгач юнең китә икән ул... Җирән биянең чөйлек бавы чияләнгән... Сүстән ишкәннәр икән, яңгыр белән бүртеп беткән...— дип сукранды.

Никтер картны кызганып киттем. Әхми бай да, Алладан курыкмаса, адәмнән оялырга кирәк иде. Шундый пычрак вакытта, кара төнгә каршы, әлҗерәп беткән җитмеш яшьлек картны көлтәгә җибәрергә ярыймы соң! Ичмаса, аты-арбасы әдәм рәтле булса тагы бер хәл иде!

Сорамыйча-нитмичә үк бабайның камытына килеп тотындым.

— Кая, бир әле, үзем карыйм!

Бабай аптырап читенде. Минем тагы ачуым килде: чөелдерек дигәне — әллә нинди нәзек җепләр белән урап, чуалып

---

[1] Кешән — атның ике алгы аягын тышаулап, бер очын арткы аягына бәйли торган озын бау.

беткән бер нәрсә. Мондый яңгырлы төндә түгел, көндез дә очын табар хәл юк.

— Бабай, мин кисәм моны! — дидем. Карт аптырый төште:

— Иртәнчәк ничек юнәтербез икән соң?

Мин аңа карамадым, тоттым да кисеп җибәрдем. Тиз арада икенче аты да тугарылды.

Картлар сак була бит; аның фурманында ике тышавы бар икән. Бабай шуларны алды да:

— Минекеләр китмиләр, үлән булса ябырылып яталар,— дип, атларын озын гына тышаулап җибәрде.

Атларның кайсы якка таба юл тотканын чамалар өчен, бераз карап тордык та арбаларыбыз янына килдек. Төн караңгылана бара, болытлар куера, көзге вак яңгыр акрын, ләкин туктаусыз һаман сибәли иде.

Минем оек-чабатам эштән чыгып пычранган, эченә су тулып, лаштырдап тора. Өстемдә камзулдан башка һич нәрсә юк, ул да актык җебенәчә юешләнгән. Мин боларны моңарчы эш кызуы белән сизмәгәнмен икән. Арба янына килеп яту, йоклау хәстәрен күрә башлагач, мине бизгәк кебек калтырау алды.

Беребездә дә шырпы да юк. Ул булса, ичмаса, корырак көлтәне ягып, бераз җылыныр идек, башкача җылыну өмете өзелде. Арбаның төбеннән корырак көлтәләрне тартып чыгардым да иң элек дер-дер калтыраган картны шулар белән күмеп ташладым. Аннан соң үзем шулар эченә урандым.

Юеш камзуллар, юеш оеклар салам астында бераз җылына башлады.

Йокларга уйлыйм. Бабай исә нидәндер йоклый алмый. Башта нәрсәдер сорады, аннан соң миңа таба әйләнеп ятты. Картны үзем белгәннән бирле күрә килсәм дә, аның белән болай якыннан очрашканым, озаклап сөйләшкәнем юк иде. «Яманташ» тавы картны миңа бөтенләй танытты.

IV

Атаклы байлары белән тирә-якта дан тоткан Өлкән авылның биек йортларыннан кысрыкланып, читкә чыгарылып ташланган мескен бер балчык өйдә чабатачы Шәмси бабай белән йон эрләүче Гайни карчык үзләренең һаман бертөсле, һаман тыныч, шау-шусыз гомерләрен үткәрә булганнар.

Ходай аларга дүрт бала бирә. Болардан өчесе үлә, тик төпчекләре — Миңнегөл генә үсә.

Аны кияүгә бирәләр. Ләкин ике елдан соң кызлары үлеп, аңардан Шаһибәк исемендә ир бала кала. Кияүләре килделе-киттеле, юаш, юньсез бер нәрсә икән. Хатыны үлгәч, дөнья-сын, чәчкән тарысын ташлап, каядыр чыгып китә, шуннан аның башы югала. Эзләп тә таба алмыйлар. Суга батканмы, бер җирдә үлеп калганмы, үзе теләп киткәнме — мәгълүм түгел.

Кияве белән кызының язмышы бу рәвешле булганнан соң, аларның баласы Шаһибәкне карт белән карчык үзләренә алалар. Үзләренчә кадерләп, иркәләп, актык сыныклары белән сыйлап, баланы үстерәләр.

Шаһибәк сигез яшькә җиткәч, Шәмси карт әҗәл җитеп вафат була.

Бабасыннан соң әбисе белән ике ел яши. Ул арада аңа ун яшь тула.

Бер җәйне аны авылның байларыннан Байморза тырма тырмалатырга алдыра. Малай юаш, акыллы күренгәнгә, аны кайтармыйлар, еллап хезмәткә яллыйлар. Шаһибәк бер уңай-дан Байморзада унбиш ел тора. Яше егерме бишкә җиткәч, бу байның эшләре начарланып, ялчы тотарлык хәле калмый да хәзерге ярлы Әхминең атасына яллана. Хәзергәчә һичбер кая китмичә, җәе-кышы шунда ялчылыкта үтә.

Карт бай бик яхшы булган. Шаһибәкне бик яраткан, аны күп вакыт үзе белән йөрткән. Дөрес, кайбер чакта кирәгеннән артык кызып китеп, Шаһибәкне ни очраса шуның белән бүртендергәнче кыйнап ташлый икән, ләкин бу сирәк була. Бай үзе, ахырдан бу эшенә үкенеп, кыйналган ялчыларының күңелен табарга тырыша башлый булган. Аларга якты йөз күрсәтә, хәлләрен сораша, уен-көлке белән сүз куша икән.

Шаһибәккә юмартлыгы да булган, һәр ел, бик зур төятеп, бер арба гошер[1] бирә, үзенең иске киемнәрен бүләк итә. Һәрбер уразада бер-ике баласының фытырыннан[2] моңа да өлеш чыгара икән.

Шаһибәк карт бай вакытында шундый кадерлерәк ялчы булып яшәгән. Бай, аның белән генә калмыйча, Шаһибәкнең олыгайганын игътибарга алып, аны йорт хезмәтеннән азат итәргә, тик умарта каравылына гына куярга уйлый башлаган

---

[1] Гошер — керемнең, уңышның уннан бер өлеше.
[2] Фытыр — уразадан соң бирелә торган сәдака.

булган. Ләкин, моның бәхетсезлегенә каршы, карт байга әҗәл җитеп үлеп китқән. Аның бөтен йорты, малы, барлык байлыгы белән бергә Шаһибәк тә мәрхүм байның бердәнбер улы Әхмигә күчкән.

Шул көннән Шаһибәк бабайның тормышында зур үзгәреш була, картка авыр көннәр килә.

Мәрхүм бай, моның картлыгына карап, җиңел эшләр генә куша, берәр авыр эш тапшыра башласа:

— Әй син, яшьтәш, кая менә бу эшкә юнең җитәме, булмаса, башка берәрсен кушармын!..— дип сүз башлый икән. Шулай яхшылап әйткәч, авыр эше дә җиңел булып китә булган...

Ә бусы, бу яшь бай Әхми, атасына бер дә охшамый. Шаһибәкне күп ялчылардан берсе саный, аңа авыр дими, җиңел дими, ни туры килсә, шуны куша. «Бабай, нихәл? Бик арып китмисеңме?» — дип сүз дәшү кайда, ул менә бүгенге кебек яңгырлы, пычрак көннәрдә начар атлар, ватык арбалар белән көлтәгә җибәрүдән дә оялмый. Ә карт бай булса, мондый чакларда Шаһи бабай өйдә рәхәтләнеп ятыр, хәл җыяр иде. Бу имансыз Әхми, маңка малай, атасы белән яшьтәш картны башка вак ялчылар белән бер рәткә куя...

«Яманташ»ның тайгак юлларыннан атларыбызны мендерә алмау сәбәпле, караңгы төндә яланда бергә кунарга туры килгән карт ялчы менә шул Шаһибәк бабай иде.

VI

Урта буйлы, шадра битле, куй күзле, йомшак, түгәрәк, саргылт сакаллы, турылыгы, буйсынучанлыгы бөтен йөзеннән күренеп торган салмак авыр йөрешле, әз сүзле бу юаш картны мин бала чагымнан ук күрә килдем. Берничә мәртәбә бергә ат та эзләдек. Ләкин озаклап сөйләшмәгәнгә, миңа ул гомер буена ялчылыкта торган бәхетсез бәндәләрнең берсе булып күренсә дә, ничектер аңа каршы бертөрле якынлык та, кызгану-фәлән дә миндә юк иде.

Мин аны, башкалар кебек, кайчандыр бала булган, уйнап, шаярып йөргән, аннан соң егет булып яшәгән, инде картайган бер кеше иттереп уйлый алмый идем. Ул гүя бөтен гомеречә шул бер төстә булган, әйтерсең шул ертык ак чикмәне, аягындагы хатыннар чабатасы, билендәге чыбыркы, башындагы мөселман бүреге, аксыл-сары сакалы белән дөньяга килгән дә, шул көенчә яшәп, кабергә дә барачак, Кыяматтә дә шу-

лай булачак: «Менә Шаһи колың — мин; теләсәң ни эшләт, миңа барыбер!» — дип, Алла каршысына барачак кебек иде.

Авылда һәр кеше бер эше, бер аерым ягы белән телгә алына. Йә усаллык, йә яхшылык, йә уткенлек, йә караклык, суфилык, хәйләкәрлек,— белмим, тагы ниләр.

Ә Шаһи хакында берсе дә юк. Үзе күренмәсә, һичкем һичбер урында аны телгә алып сөйләми, һичбер эш турында, моны ул эшләр, ул булдырыр, фәлән дип, аны хәтерләми.

Тик әллә кайчан, әллә нинди бер мәҗлестә кемнеңдер, аны кызганып:

— Бичара, юньләп бисмилла да әйтә белми, ике гаеттән башка вакытта мәчет ишегенә аяк басканы юк,— дип, бик артык каралыгы хакында сөйләгәне генә колагыма кереп калган.

Бичара берәр җирдә үлеп калса, бәлки шулай онытырлар. Шаһи карт кая булды дип эзләмәсләр дә иде кебек.

Җәйнең аяз, җылы, айлы кичләреннән бере иде. Мин ялгызым гына атта кайтып килә идем, тирә-якта гаҗәп бер тынлык иде, каршыма бер арбаның якынлап килгәне күренде. Аты өстерәлеп кенә атлый. Арба һаман акрын гына бара. Кемдер урәчәгә яны белән яткан да атның ялкау гына атлавы уңаена ниндидер озын көйгә тирән әчке бер тавыш белән моңаеп бара. Бу моң туры йөрәгемә төште: «Син кем?» — дип дәшәргә телем бармады, баскан җиремдә катып калдым.

Җирәнчеккәй атның, ай, ялларын
Кыйблалардан искән җил тарый;
Үз бәхеткәйләрең, ай, булмагач,
Байга хезмәт итеп кем ярый...

Шул авыр, тирән моң мине басты, үзе дә, ахры, дөньядан югалгандыр, мине күрми үтте.

Җырлап үтүче карт ялчы Шаһи бабай булган икән.

Шул очрашудан соң миндә әллә нинди бер тойгы уянды, аны күргән саен, шул кичә исемә төшә торган булды. Берәр сүз әйтим, күңелен табыйм, дим. Ләкин нәрсә әйтәсең? Ни белән аның күңеленә рәхәт бирә алырсың? Күңел таш түгел бит, уңайсыз бер яктан сүз ачарсың да картның яралы йөрәгенә кагылырсың.

Якыннан күргәндә, дөресен әйтсәм, мин бу картта яралы да, ярасыз да йөрәк юктыр кебек тоям. Ерактан күрсәм, теге

кичә, теге җыры, моңы исемә төшә дә, картның йөрәге яралыдыр кебек бер тойгы, бер кызгану уяна.

Аның йөрәге бардыр, ул яралыдыр, тик аны дөнья баскандыр, һичбер вакыт, һичкем аның хәлен белергә, бергә кайгырышырга теләмәгәнгә, ул үзе дә йөрәгенең барлыгын, аның ярасын оныткандыр, ул бернәрсә дә белми, нәрсә икәнен аңламыйдыр. Йа, Ходай, бу карт турында уйлый башлагач, әллә үзем дә саташам инде!..

VII

Ничек кенә дисәң дә, дөнья — дөнья инде. Ул сине баса, аның кызу эшләре, мәшәкатьләре күңелдәге әйбәт уйларны оныттыра. Башка һәрбер очравымда карт миндә авыр бер кызгану уята торган иде. Әле бүген энемнең кулы имгәнүе, атайның без кайткан саен кашларын салындырып, ачулы йөз белән каршы чыгуы, яңгырлы төндә «Яманташ» тавыннан атларыбызны мендерә алмый азапланулары, бигрәк тә бабайның үзенең бүген ничектер җанлырак, булдыклырак кылануы, Вәликәйнең кара аты хакындагы сүзе дөрескә чыккач, бераз күтәрелеп, бик чак кына мактанган төсен алуы,— ничектер, карт ялчы хакында башка очрауларымда була торган кызгану башта булмады.

Картның тәҗеләре, тәртә төпләре өзелеп, көлтәле арбасы тау астына очкач, мин дүрт атны тугарып, тышаулап, кешәнләп килгәнче, бер атын да тугара алмый, чәбәләнгән чөйлек[1] бавын чишә алмый азапланганын күргәч, бигрәк тә әллә нинди кызганыч, беткән тавыш белән:

— Бер картайгач булмый икән инде ул... Чөйлек бавын киссәң, иртәгә нишләрбез икән соң...— дигән сүзен ишеткәч, карт тагы миңа теге айлы кичтә авыр моң белән җырлап барган бабай булды. Шул хәлдә арбалар астына килеп, аны коры көлтәләр эченә күмеп ташлагач, ул инде миңа бигрәк мескен булып күренә башлады.

Яңгыр сибәли, төн бик артык караңгы... Юеш кием, суык һава йоклатмый.

Карт үзе сүз башламагач, мин аңар:

— Нихәл, бабай? Яшь бай үзеңә бик каты түгелме? — дигән идем, ахры, авырткан җиренә кагылганмындыр: җавап

---

[1] **Чөйлек** — чөелдерек. Камыт агачларын тарттырып бәйләү өчен бау.

бирмичүк, миңа таба борылып ятты, башка вакыттагыга бер дә охшамаган рәвештә сүзгә ачылды. Әйтерсең ярага чәнечтеләр дә, аннан кан китте.

Кеше шулай бит. Ничаклы беткән кебек, юньсез кебек күренсә дә, дөнья ничаклы басып, изеп җанын үтерсә, йөрәген капласа да, кайбер вакыт, яңлыш бер ярасына кагылсаң, аның үлгән җаны терелә, сүнгән йөрәге тибә башлый. Бабайга да шулай булды бугай.

Мин, яшь бай, фәлән-төгән дип, сүз юктан гына әйткән идем, ә шул аның әллә кая төпкә батып, онытылып беткән уйларын тергезде, аңа җан бирде.

— Сөйләмә инде, Сәфәр туганкай... Борынгы картлар юк инде алар... Карт бай мине яшьтәш дип, аркамнан гына кагып йөртә иде. Бусы — бик һавалы нәрсә... Әйтергә җиңел бит, бу бит минем кулымда туды... Мәрхүм бай беркөн мине чакырды да: бар әле, яшьтәш, ди, минем хатын балаларга итә бугай, Фәрхи карчыкны чакырып кил әле, ди. Аягым җиргә тимәде, бер минутта Фәрхине китереп җиткердем... Көн буе анда чаптым, монда чаптым... Әллә кемнәрдән сөенче алып беттем... Үсә башлагач та уеннар ясап бирдем. Тартып, күтәреп йөреттем, чыбыркы иштем. Хәер, яшьлек бик явыз нәрсә иде инде... Бабай, мине күтәреп йөрт дип, муеныма атлана иде дә, авыртамы, авыртамы дип, колакларымны тешләп җәфа чиктерә иде... Карт байга сүзем юк... Мин кергәндә байлыгы чамалы иде... Бик нык эшләдем үзенә... Мәрхүмең, үлгәнче, бу йортларда, бу атларда, бу арбаларда Шаһибәкнең көче бар, хакы бар, дип сөйли иде... Үлгән чакта да, рәнҗетмәгез, авыр эшкә кушмагыз, дип үлгән... Минем бәхетсезлегемә каршыдыр инде, бичараның гомере кыска булган. Ә бусы бөеренә таянган була... Ата күркә кебек кабарына, борынын киерә,— әйтерсең бу дөнья мәңгелек аңа! Карт дип санга санау юк, юньле сүз юк. Карт бай булса, адәм үләрлек көндә мине көлтәгә җибәрер идемени!

Карт ялчы яшь байдан озак зарланды. Мин ни диярге белмәдем. Тик Әхминең рәхимсезлеге хакында ара-тирә берике сүз кыстыргаладым. Бабай исә минем сүзләремә дә күп колак салмый, бер-бер артлы аһ-зарын агыза гына бирә...

Яшь бай Әхминең бу көнге бер катылыгы картның күңелен бигрәк нык рәнҗеткән...

«Төшемдә әбине — мәрхүм Шәмси карчыкны күрдем,— ди,— йөзе караңгы, ачулы»,— ди. Гүя нәрсәдер әйтеп, Шаһины

шелтәли, имеш... йокысыннан кайгырып уянган да, Гыйльман шәкертне алып барып, әбисенең каберендә Коръән укытмакчы булган... Яшь бай җибәрмәгән.

— Син,— дип әйтеп әйтә, ди,— карт җүләр, әллә акылдан шаша башладыңмы?— дип әйтеп әйтә, ди.— Бер кеше кырыкка ярылырга торган мондый кызу эш өстендә,— дип әйтеп әйтә, ди,— кабергә барып йөриләрмени? — дип әйтә, ди.— Менә эш беткәч, теләсәң,— дип әйтеп әйтә, ди,— кабердән бер дә кайтмыйча ятсаң да сүзем булмас,— дип әйтеп әйтә, ди.

Карт: «Мин тиз кайтам, бер самовар кайнап чыгарлык та вакыт үтмәс, мин кайтып килермен»,— дисә дә, бай риза булмаган... Моңа каршы гомерендә кешегә сүз кайтармаган Шаһибәк байның сүзенә буйсынмаска, аның белән карулашырга итеп караган икән, яшь, һавалы бай аяк тибеп кенә кычкырган:

— Ырылдама, карт эт! Күп сөйләшә башласаң, алырсың кирәгеңне!

Боларны ишеткәч, карт ялчының әбисе дә, кабере дә башыннан чыгып очкан, күңеле беткән.

— Юк инде, бәхетле булсак, бәндәгә бәндә булмас идек, балам,— ди.— Инде,— ди,— картлыгым да басты, карт этне йорттан куа башладылар. Бер җылы почмак булса, чабата тукып булса да тамак туйдырыр идем,— ди.— Балакай,— ди,— алгы көн бар бит... Маңгаем сәҗдә күрми үләм бит, Ходай каршына ни йөз белән барырмын, ни җавап бирермен,— ди.

Безнең әти, эш турында каты кеше булса да, карт-корыны, ятим-җәберне бик кызганучан. Аның каршы төшмәвен исәпләп алдым да:

— Шаһи бабай, син безгә күчәр идең, безнең әткәй — картларга йомшак күңелле кеше, бездә җәй көне аз-маз эшләп, кыш тыныч ятар идең, сиңа каты хезмәт кушмас идек,— дидем...

Карт ачык җавап бирә алмады.

— Белмим шул... ничек булыр икән соң?.. Атаң яхшы кеше инде синең,— диде...

Сүз киселде. Карт икенче якка әйләнеп ятты. Мин йокыга китә башладым.

Ләкин бу төндә миңа йокы насыйп түгел икән: инде йокыга киттем генә дигәндә, әллә өнемдә, әллә төшемдә кемнеңдер пыскып елаганына охшаш бернәрсә ишеттем. Йокым ачылды,

иплəбрək колак салсам, йөрəгемə суык йөгерде — төш түгел, өнем икəн, пыскып елаучы кеше юлдашым карт ялчы Шаһи бабай икəн.

Тау артыннан сызылып таң беленə башлады. Мин йокыдан өмет өздем. Акрын гына тордым да, ерак китмəгəннəрме икəн дип, атларны карап килдем.

Карт əзрək ятсын əле, бəлки бераз йоклый да алмасмы, һич булмаса, бераз хəл җыйсын!

Арттагы арбамнан тимер сəнəкне алдым да теге, тау астына очкан арба янына килдем.

Болытлар тарала, күк ачыла. Карт торганчы, көлтəне бушатып, тəҗесен, тəртəсен бəйлəп, яңадан төяп, чыгарып куярга уйлыйм.

Артык кыенлык күренми, кичə бик нык очкан төсле булса да, арбаның башка җире исəн. Чыгарырга да чокыр эченнəн урап юл бар. Үземнең бер арканны алдым да картның тəҗесен, тəртəсен ныгыттым.

Арбаны чыгарырлык урынга китереп, көлтəлəрне яңадан төяп беткəн чакта, бабай да, уянып, минем янга килде: «Айһай, уңган җегет икəнсең, Сəфəр,— ди,— əллə,— ди,— син бер дə йокламагансың»,— ди.

— Өшетте, юньлəп йоклап булмады,— дим.

Атлар җиктек тə кузгалдык.

Атлар хəл алганнар, төн буенча юл да бераз сүрелгəн: мендерү кыен булмады.

Тауны мендерү белəн, дүрт атымны бер-бер артлы тездем дə алдагы арба башына сикереп мендем. Карт миңа иярмəде, атларына утырмыйча, арба яныннан җəяүлəп килə. Ул кызу йөрергə яратмый, кая ашыгасың, ди.

VIII

Бер-берсе мең сумлык бар соң бу атларның! Алты чакрым җирне фурманның өстенə өчəр рəт чыгарып төягəн көлтə белəн чаптырып авылга кайтып җиткəн вакытта, мəзин иртə намазына азан əйтергə яңа гына манарага чыккан иде əле.

Киленнəр сыерга баралар. Акыллы карт сыерлар үзлəре кайтып, хуҗасы капка ачканны көтеп, канау буенда күшəп яталар.

Кайдандыр акрын гына гармун тавышы ишетелə. Əткəй, җиңнəрен сызганып, иртə намазына тəһарəт алып йөри. Аның

йөзендә ачу күренми, кашлары да башка вакыттагы кебек салынмаган. Тәһарәт алуын бүлеп, капкадан минем атларымны җитәкләп кертеште дә:

— Нихәл, ат-арбаң исәнме? Мин берәр нәрсә ватылып ятамы икән дигән идем. Өшегәнсеңдер, атларыңны тугар да кереп чәй эч, көлтәне мин намаздан кайткач бушатырбыз,— диде.

Ындырга барып, очланмаган солы кибәне янына атларны тугарып йортка кайтканчы, кояш та чыкты.

Көн ачыла, атналар буенча туктамый, яңгыр белән йончып, өшеп беткән табигать кызарып, нурланып чыккан кояшны бәхетле елмаю белән каршы ала.

Рәхәт соң, валлаһи, көн буена туктамый җимереп эшлисең, төнен йокламый чыгасың... Көннәр шулай аяз, кояш шулай нурлы булса, тагы атналар буенча, көнен-төнен туктамый эшләргә хәзермен.

Гаҗәп уңган кеше дә инде безнең әни!

Ни арада минем кайтканны күреп калган, ни арада сыерын савып, көтүгә куган, ни арада тагы миңа самоварын кайнатып, бәрәңгеләрен пешереп өлгергән.

Өйгә килеп керсәм, самовар гөжләп утыра, каз йомыркасы кебек эре бәрәңгеләр табак тулып, буланып торалар.

Бер чынаяк эчеп бетмәдем, урамда арба шыгырдаганы ишетелде, карасам: көлтә төягән аллы-артлы ике арба югары таба менеп баралар, алдагы күк биянең яныннан салмак кына атлап минем юлдашым Шаһи бабай бара. Чыбыркы сабын җилкә аша салып, шуның ике башыннан ике кулы белән тоткан, башын аска игән. Миңа ул нидер уйлап бара кебек тоелды...

Үткән төн күз алдымнан кичте. Аның сүзләре, миннән яшеренеп, пыскып елавы тагы йөрәгемә төште.

Ул тагы:

— Бәхетле булсак, бәндәгә бәндә булмас идек! — дигән кебек булды.

Кояшның яктысы, көннең аязлыгы күренмәс булды. Самовар гөжләве, бәрәңгенең буланып торуы баштагы кәефләрне җуйдылар. Аннан-моннан капкаладым да, тагы әллә нинди авыр уйлар белән тышка чыгып, ындырга көлтә бушатырга киттем.

1912 ел

Нәтиҗә:

Галимҗан Ибраһимовның ике әсәрен өйрәндек. Максатыбыз аларның уртак сыйфатларын табып гомумиләштерү иде. Түбәндәге уртак сыйфатлар табылды:

1. Әсәрләрнең өчесендә дә уртак тема — бәхет темасы булуы ачыкланды.

2. Төп геройларының холкын автор үзе әйтеп бирә:

«Бер адәмнәр мохиткә җиңелү түгел, язмыш агымына буйсыну түгел, мохитнең үзен җиңәләр, язмышны үзләре теләгән якка борып җибәрәләр.

Әмма калганнары... гомер буена мохит вә язмышның колы булалар...» — ди.

Бирем

Әдип фикеренчә, язмышын үзләре теләгән якка бора алучылар гына бәхеткә ирешә алалар. «Карт ялчы» хикәясендә дә Галимҗан Ибраһимов иҗатының әнә шул үзенчәлеге саклануын исбат итегез.

Галиәсгар Камал

(1879—1933)

Галиәсгар Камал (Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов) 1879 елның 6 гыйнварында Казанда туа. Аның әтисе Галиәкбәр Камалетдин улы үз кул көче белән гомер итүче ярлы кеше була. Ул вакытта шәкертләрне мәдрәсәләрдә укыту түләүле булган. Галиәсгар, китап сатучыларгаялланып, төрле шәһәрләрдә китаплар сатып йөри. Мәдрәсәдә ул үзе эшләп алган акчага укый.

Ничек укуы турында әдип болай яза: «Мин 1900 елга кадәр элек «Госмания», аннан «Халидия», аннан, 1893 елдан башлап, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм аның янындагы русский класста укып, яз һәм җәй көннәрендә китапчы Мөхәммәтҗан Кадыйров дигән кешегә ялланып, Хан, Мәкәрҗә һәм Буа ярминкәләренә барып, кышын шулардан алган хезмәт хакы акчасы белән укыдым».

Мәдрәсәне тәмамлагач, әтисе мулла булырга бик үгетләсә дә, риза булмый, халыкка аң-белем бирү эшен дәвам итәргә карар итә. Рөхсәт алып, Казанда «Мәгариф китапханәсе» ача. Китап бастырып тарату эшенә керешә. Монда ул татар милләтенең иң алдынгы кешеләре белән таныша. Күп тә үтми, китапханә әдипләрнең, журналистларның бергә җыелып фикер алышу урынына әйләнә. Полиция бу хәлне сизеп ала. Китапханәгә тентү үткәрә. Тентү вакытында хөкүмәтне бәреп төшерү турында язылган китап табылгач, Г. Камалны судка бирәләр.

Алай да әдип китапханәсен саклап кала алган. Китап бастыру һәм тарату эше белән генә канәгатьләнмичә, «Азат»

газетасына эшкә керә һәм үзе дә яза башлый. Ә бераздан үзе «Азат халык» газетасы чыгара. Монда ул бик күп мәкаләләр бастыра.

Газеталардагы азатлык яуларга өндәгән мәкаләләр полициягә ошамый. Г. Камалны, «хөкүмәткә каршы язасың» дип, тагын хөкемгә тарталар. Әмма күпме генә тыйсалар да, әдип милли азатлык таләп итеп мәкаләләр язуын дәвам итә. «Йолдыз» газетасында эшләгәндә, шундый карашлары өчен ул тагын бер тапкыр хөкем ителә. Бу юлы алты айга төрмәгә ябылырга тиеш була.

Яше зур булмаса да, башка әдипләр каршында ул игелекле зирәк аксакалга әйләнә. Галиәсгар Камал ярдәмгә мохтаҗ әдипләргә ярдәм итә, киңәш сорап килүчеләргә киңәш бирә. Алдынгы карашлы кешеләр аны зурлыйлар, хөрмәт итәләр.

Галиәсгар Камал үзен тиз арада үткен телле кыю сатирик итеп таныта. Күп сандагы сатирик мәкаләләрен, пьесаларын ул шушы елларда иҗат итә. Көлкеле рәсемнәр — карикатуралар ясый. «Яшен» сатирик журналын оештыручыларның Галиәсгар Камал белән Габдулла Тукай булуы бер дә гаҗәп түгел.

Үткен телле, гадел «Яшен» журналын тиздән ябалар. Ләкин әдип күңелен төшерми. «Ялт-Йолт» журналына эшкә керә һәм мәкаләләрен бастыруны дәвам итә.

Шундый кешегә ничек тынгысыз җан димисең дә аның ихтыяр көченә ничек сокланмыйсың? Бер үк вакытта Г. Камал татар театры оештыру эшенә керешә.

Театр пьесаларсыз яши алмый. Шуңа күрә Г. Камал пьесалар яза башлый. «Бәхетсез егет» драмасын, «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» исемле комедияләрен иҗат итә. Рус һәм чит ил авторларының сәхнә әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә. Татар театры булдыруга багышлап ул газета-журналларга күп санлы мәкаләләр яза.

«Сәйяр» исемле беренче татар труппасы оешкач, Г. Камал аның режиссеры була, артист булып та уйный.

Беренче театр

(Комедия бер пәрдәдә)

УЙНАУЧЫЛАР:

Хәмзә бай — иске фикерле Казан бае; башында ак бүрек, яшел кәләпүш, өстендә намаз туны, аның эченнән бишмәт, аның эченнән кыска җиңел камзул кигән, чалбар балагын ак тасма белән бәйләгән.

Гафифә — Хәмзә байның кызы.

Вәли — Хәмзә байның кияве.

Хәбибрахман — Хәмзә байның улы, аңгыра.

Факиһә — Хәбибрахманның хатыны.

Биби — Хәмзә байның асравы, аңгыра кыз.

Бай сымак бер өй. Ике якта икешәр ишек. Түрдә тәрәзәләр, тәрәзә арасында көзге. Стена буенда урындыклар. Сул тарафта бер диван. Аның алдында өстәл. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә **Вәли** күренә...

Вәли *(кычкырып)*. Гафифә! Гафифә!

Гафифә *(бүлмәдән сузыбрак)*. Әү!

Вәли. Буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам.

Вәли. Тизрәк бул! *(Халыкка таба карап.)* Гафифә дисәң Гафифә, бер җиргә бара башладың исә, кеше күрә дип коты чыга. Аның каршында «ир кеше» дигән сүз «ерткыч җанвар» дигән сүз белән икесе бертигез. Бары мин генә ул кадәр куркынычлы җанвар түгел. Башта миннән дә коты очты. Кияү булып кергәч, куркуыннан, куян шикелле, бер почмакка посып тик тора. Соңыннан, минем тарафтан шул яшенә җиткәнгә кадәр ата-анасыннан да ишетмәгән тәмле, татлы сүзләрне ишеткәч кенә, бераз җайланды. *(Ян ишеккә барып, ишеккә башын тыгып.)* Һи! Әле тиз генә буласың юк икән. Зинһар, тизрәк була күр! Әгәр каенатай кайтып керсә, аннан ары харап эш. Ничек итсә итәр, гомердә театрга җибәрмәс. *(Башын бүлмә ишегеннән алып, халыкка таба карап, куллары белән хатын-кыз битенә пудра сөрткән төсле итеп күрсәтеп, бераз көлебрәк.)* Бизәнә, мич акшарлаган шикелле итеп, битләрен буяп маташа. Шулай да булса үзенә килешеп тора тагын. Уйлап карагыз, әгәр мин шулай итеп битләремне буйый торган булсам, һич килешмәс иде бит! Онга төшкән таракан төсле булыр идем. Безнең бер асрау бар, йөзе менә нәкъ чуенның ундүртенче кичәсе төсле кап-кара. Беркөнне

шул асрау, абысталары өйдә юк чагында, барган да минем Гафифәнең пудырларын алып ягынган; бөтенләй менә, бигайниһи[1], бер ком гарәбенең битен акбурга буяган.

Көлешә-көлешә алҗып беттек. *(Бик җитди.)* Беләсезме? Ул бит пудыр күп кешегә килешми, хосусән ирләргә бер дә килешми. Ә менә минем бер таныш егетем бар — Әхмәтҗан, ул һәр көнне өчәр мәртәбә сакалларын китәреп, пудырлар сөртеп йөри. Аңа килешә. Миңа бер дә килешми. Ул шул инде аксөяк нәселдән яратылган. Ә безнең нәрсә, без бит мужик! Безнең бабай сука сукалап үскән. Әти, чабата киеп, 12 яшендә калага килгән. Безнең шикелле кара икмәк ашап үскән кешегә кая инде ул ак сөякле булу? Ак кына түгел, миңа карасы да килешми. Бервакыт хатын: «Бик матур була»,— дигәч, котырынып, шушы мыегымны карага буяган идем. Ничә көннәргә кадәр кеше күзенә күренергә оялып яттым. Җитмәсә тагын, мыекка сөртәм дигәндә, битләрне буяп бетердем. Ә аның карасы тәннән һич китми икән... Тумыштан матур булып тумагач, спайланган булып маташу белән генә булмый инде ул. *(Ян ишеккә карый, төсләрен бозып.)* Ул нишләвең инде? Мин монда кайчаннан бирле, кайчан киенеп бетерә инде, дип көтеп торам.

Гафифә *(бүлмәдән)*. Җә, ярар ла, хәзер булам, пудыр матур төшмәгән.

Вәли. Тизрәк бул инде, зинһар! *(Башын бүлмәдән алып, ишекне ябып, халыкка таба карап.)* Менә сиңа кирәк булса, мин инде өстемә пальтоларымны кигәнгә бер сәгать булды. Ә ул әле һаман пудыр ягынып бетерә алмый; пудыр ямьсез төште дип, яңадан битен юып ята. Әле ярый, көзге ямьсез күрсәтә дип, көзгене бәреп ватмаган. *(Уң як ишектән кулына поднос белән чынаяклар күтәреп чыгып, Биби узып бара.)*

Вәли *(Бибине күреп)*. Әй Биби, тукта әле!

Биби *(борылып карап)*. Нәрсә дисең?

Вәли. Кара әле, ә!..

Биби. Карыйм ич инде!

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим, нинди нәрсәдер.

Вәли. Тфү, чёрт! Сөйләп бетергәнне көт!

Биби. Йә, көтәм.

---

[1] Бигайниһи — нәкъ үзе төсле булган.

Вәли. Менә нәрсә...

Биби. Белмим!

Вәли. Тыңлап тор дим мин сиңа!

Биби. Тыңлыйм ич.

Вәли. Менә без хәзер театрга китәбез...

Биби. Нәрсә төятергә?

Вәли. Баш төятергә.

Биби. Нинди баш?!

Вәли. Атаң башы! Мин сиңа төятергә димим, театрга дим, аңладыңмы, театрга дим!

Биби. Йә, аңладым инде, театрга, ул нинди җир соң?

Вәли. Анысы сиңа кирәк түгел. Без киткәч, каенатай кайтыр, ул сорар безне: «Кайда киттеләр?» — дип. Син аңа әйт: «Кодаларга киттеләр»,— дип. «Театрга киттеләр»,— дип әйтмә!

Биби. Сорамаса нишләрмен?

Вәли. Тик торырсың... Син, аңгыра нәрсә, рәтләп әйтә дә белмәссең әле... Йә, әйтеп кара әле, ничек дип әйтерсең икән.

Биби. «Вәли җизниләр театрга китмәделәр, кодаларга киттеләр»,— диярмен.

Вәли *(ачуланып)*. Иштең ишәк чумарын! Мин сиңа алай дип әйттемме?

Биби. Соң ничек дидең?

Вәли. Мин сиңа: «Театрга киттеләр»,— дип әйтмә, «Кодаларга киттеләр»,— дип әйт дидем.

Биби. Мин дә бит «киттеләр» димәдем.

Вәли. Фу, җәфа икәнсең, кайдан башыма бәла алдым! Менә син яхшы тыңла: әгәр дә каенатай безне: «Кая киттеләр?» — дип сораса, «Кодаларга киттеләр»,— диген. Башка сүз әйтмә, бар, юлыңда бул!

Биби. Ярый. *(Кереп китә.)*

Вәли *(үз-үзенә)*. Менә бәла өстенә бәла. Мин үзем дә җүләр: миңа ни эшкә кирәк иде аңар театр дип сөйләп торырга? Мин аңар дәрес әйтәмме? *(Ишектән Гафифә килеп чыга. Аңа карап.)* Нихәл, буласыңмы инде?

Гафифә. Хәзер булам инде. Нәрсәгә шаулашасыз икән дип карарга гына чыккан идем.

Вәли. Әнә шул, бар ич әле, бер адәм имгәге Биби, шуңа сүз аңлата алмыйча аптырап беттем...

Гафифә. Ул һәрвакыт шулай, һич аңламый ул. Мин аны беркөнне Гарифәләргә җибәрдем. «Абыстай: «Гарифәнең

алдырган кислотасы юк микән. Бик күңелләрем болганып тора...» — дип әйтте, дип сора»,— дигән идем, барган да: «Абыстай киез каталарын биреп торсыннар ла»,— дип сорап, миңа кислота урынына киез ката күтәреп кайткан... Гарифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә керердәй булдым.

Вәли. Йә, ярар, аларын башка вакытта сөйләшербез. Театрга барырга соңга калабыз, бар, тизрәк бул!

Гафифә. Хәзер булам. Ә, ни, синнән шуны гына сорыйм дигән идем. Ул театрда кеше күп булыр микән?

Вәли. Һу! Күп булмыймы соң! Беләсең бит, бүген мөселманча театрның беренче башлана торган көне. Шулай булгач инде, анда бөтен шәһәр халкы агылыр.

Гафифә *(борыннарын җыерып).* Әй! Әем! Алай булгач, мин бармыйм ла, анда кеше күп булгач, мин оялам.

Вәли *(үз-үзенә).* Менә сиңа кирәк булса! *(Башын кашып.)* Юк, минемчә, әле бу көн кеше ул кадәр үк күп булмас. Күбесенең картлары җибәрмәс. Кайберсе кеше сөйләүдән куркып калыр.

Гафифә *(янә әүвәлгечә).* Алай булгач, без дә бармыйк: мин дә кеше сөйләүдән куркам. Әти белсә, ул да ачуланыр.

Вәли *(бик тирән уйга калып, башын күтәреп, халыкка таба карап).*Уттан котылдым, инде суга төштем. Моннан инде ничек котылырга? *(Гафифәгә карап.)* Мин бит инде, анда барырга дип, билет та алып кайткан идем.

Гафифә. Кайтсаң ни! Бармый калган булгач, акчаңны кире кайтарып алырсың.

Вәли. Бер алган булгач, кире кайтармыйлар шул аны.

Гафифә. Теләсәң ни эшлә, мин барырга куркам!

Вәли. Анда ерткыч җанварлар юк, сине ашамаслар.

Гафифә. Ашамасалар да, мин бармыйм, кирәкми.

Вәли. Юк инде, бармый калырга ярамый, барабыз! Ул бит бик күңелле була. Үзеңнең дә көлә-көлә эчләрең катып бетәр.

Гафифә. Андый көлкеләрне ат кәмитендә дә бик күп күргән инде. Монда да әллә нинди артык җире булмас, кирәкми, мин бармыйм.

Вәли. Ихтыярың, теләсәң ни эшлә, барасың килмәсә көчләмим, мин үзем генә барам.

Гафифә. Ә, ярар менә, барыр идең бугай, кара син аны, анда ялгыз гына кызлар карарга бармакчы була. Җибәрәмме соң мин сине, Алла боерса, гомеремдә ялгыз җибәрмим!

Вәли. Теләсәң ни эшлә, мин бармыйча калмыйм. Син бармыйсың икән, мин үзем генә тотам да барам! Хуш, сау бул, мин киттем. *(Чыга башлый.)*

Гафифә *(тиз генә Вәлинең артыннан барып тотып).* Җә, җә, бетте. Мин юри генә әйттем. Әйдә, мин дә барам.

Вәли *(кире кайтып).* Ну, әйдә, алайса, барсаң, тизрәк киен!

Гафифә. Хәзер киенәм. *(Бүлмәгә таба бара башлый. Сонра янә борылып.)* Кара әле, анда өскә киенгән көенчә генә утыралармы?

Вәли. Юк, салып утыралар.

Гафифә. Әй! Алай булгач, бик читен икән. Кирәкми, бармыйбыз.

Вәли. Бармыйбыз дип сөйләмә, мин барам, киттем, алайса. *(Чыга башлый.)*

Гафифә. Барам, барам!!

Вәли *(мыскыл итеп).* «Барам, барам!» Ә үзе һаман терәлеп тора. *(Сәгатен чыгарып карап.)* Син, шулай итеп маташып, мине уеннан калдырмакчы була торгансыңдыр, ахры. Уен башланырга бары ярты гына сәгать калган.

Гафифә. Мин хәзер булам. Өстемә күлмәк кенә киям.

Вәли. Ну, бар, зинһар, тизрәк бул.

Гафифә *(ишектән керә башлый да, янә борылып).* Нинди күлмәгемне киим икән: асылмы, җонмы?

Вәли *(үз-үзенә).* Асыласың килсә, асыл инде. *(Гафифәгә.)* Зинһар, мине йөдәтмә. Асылмы, җонмы, сатинмы, батисмы, ситсымы — минем өчен бар да бер.

Гафифә. Ярый, алайса, мин зәңгәр асылымны киям. *(Китә башлый.)*

Вәли. Әй, юк, тукта әле, зәңгәр асылыңны кимә, нинди булса да берәр җон күлмәгеңне ки. Сезнең андый чачаклычуклы карават чаршавы шикелле асыл күлмәкләрегез белән кешегә көлкегә калыр хәлем юк. Без анда бүләк багарга бармыйбыз, уен карарга барабыз.

Гафифә. Алай булгач, нинди җон күлмәгемне киим?

Вәли. Теләгәнеңне ки.

Гафифә. Теге гармун итәкле кызыл җон күлмәгем ничек булыр?

Вәли. Шәп булыр.

Гафифә. Аның шул буе озын булган. Чәнчелеп беткән җөйче, шулкадәр әйттем: «Факиһәнеке төсле матур булсын,

яхшы итеп тек»,— дип. Бозып кына бирде. Юкка гына дүрт тәңкә акча әрәм иттем. Моннан ары, Алла боерса, гомердә ул хатынга тектермәм.

Вәли. Ярый, шулай итәрсең. Бар, тизрәк бул.

Гафифә. Соң кайсын киим?

Вәли. Башкасын.

Гафифә. Теге, буйга буф бөргән сирый күлмәгемне киимме?

Вәли. Ки.

Гафифә. Ул да шул бик килешеп бетми, чабулары бик тар булган.

Вәли. Алайса, бүтәнне ки.

Гафифә. Ал йон күлмәгем ничек булыр?

Вәли. Бик ал булыр.

Гафифә. Кызылы?

Вәли. Бик кызыл булыр.

Гафифә. Яшеле?

Вәли. Бик яшел.

Гафифә. Соң ниндине киим?

Вәли. Матурракны.

Гафифә. Теге шикалат төсле, тоташ буйлы, бантиклы күлмәгемне кисәм ничек булыр?

Вәли *(шатланган булып)*. Һу! Менә, менә әзли торгач таптың, ахры, бик һәйбәт булыр. Үзе шикалат төсле дә булгач, бигрәк шәп була инде ул. Чөнки шикалат — бик тәмле нәрсә.

Гафифә. Мин аны кияр идем киюен дә, аның шул җиңнәре сак җиң[1]. Килешмәс. Үзең дә, ичмаса, бер кеше төсле чибәр күлмәклек алып биргәнең дә юк. Бер җиргә бара башладың исә, киеп барырлык һичбер җүнле, матур күлмәгем юк.

Вәли. Соң бит аны хәзер генә тегеп булмый лабаса, уф Алла! Бар икән кылыну, ансы да ярамый, монсы да ярамый, белмим, боларга нәрсә генә ярый торгандыр, чәнчелеп бетегез шунда. Сезне көтеп, уеннан калыр хәлем юк. *(Чыгып китә башлый.)*

Гафифә *(артыннан барып җитеп, Вәлинең җиңеннән тотып, ялынган рәвештә)*. Җә инде! Ни эшләвең инде ул? Торасың да чыгып китәм дип куркыта башлыйсың. Мин

---

[1] Сак җиң — тар җиң.

сиңа бармыйм дип әйтмим ич! Мин синнән әллә нәрсә сорамыйм бит, бары тик нинди күлмәгемне киим дип кенә сорыйм.

Вәли. Мин сиңа әйттем бит инде. Теләсәң нәрсә ки дип. Миңа дисәң, бөтенләй бернәрсә дә кимә.

Гафифә. Соң шулай диген аны. Яхшылап кына сораганда, тотасың да ачулана башлыйсың. Алай булгач, ярый торган булса, мин бернәрсә дә кимим, шушы өстемдәге күлмәгем белән генә барам.

Вәли *(йөзләре яктырып)*. Һай, бәрәкалла! Бик яхшы булыр, бар. Зинһар, тизрәк. Өстеңә генә ки дә, хәзер китәбез. *(Гафифә ашыгып керем китә.)* Уф Алла, җаным чыга язды. *(Ишеккә барып карап.)* Яңадан тагы бер-бер нәрсә тапкан булып чыга күрмәсен,— ә, юк икән. *(Ишекне яба.)* Киенә икән, ахырында мең бәла белән көчкә җиңдем. Бу үзенә күрә инде кечкенә генә, бармак башы кадәр генә булса да бер революция булды. Ярый, ни булса да булды, минем максудым[1] булды. *(Кулларын угалап.)* Их хозур! Хәзер театрга китәбез. *(Таягын ике кулының бармак очлары белән генә тотып, сүз арасында төрле шатланган һәм мәсхәрә кылган кыяфәтләргә кереп җырлый.)*

Бүген театр була, трат-та-та, трат-та-та!
Шатлыктан күңлем тула, трат-та-та, трат-та-та!
Картның кәефе бик китә, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Уйнаучыларны тетә, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Барам мин театрга, трат-та-та, трат-та-та!
Хатыным белән бергә, трат-та-та, трат-та-та!
Каенатай кайтып кергәч, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Безнең киткәнне күргәч, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Ачуланса да курыкмыйм, трат-та-та, трат-та-та!
Барыбер сүзен тотмыйм, трат-та-та, трат-та-та!
Кайтып кергәчтен тузар, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Бөтен кәефне бозар, уй-уй-уй, уй-уй-уй!
Бозса бозар кәефне, трат-та-та, трат-та-та!
Хәзергә мин кәефле, трат-та-та, трат-та-та!

Гафифә *(ишектән өстенә киенгән көенчә чыгып)*. Йа, бар икән Ходаем, тагы нәрсә җүләрләнәсең инде?

Вәли. Әһә! Булдыңмы әле син, аппагым? Әйдә, алайса, киттек инде, былбылым! *(Гафифәнең култыгыннан култык-*

---

[1] **Максуд** — теләк.

лап чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Бераздан, бик кызуланып, уң як ишектән Факиһә килеп чыга.)

Факиһә *(як-ягына карап).* Монда да юк! Болар кая киткәннәр? *(Ишекне ачып кычкыра.)* Биби! Биби! *(Биби чыга.)* Син беләсеңме?..

Биби. Беләм!

Факиһә. Беләсең икән, әйт алайса: кая киттеләр җизниләр?

Биби. Алар, син сорасаң, ничек дип әйтергә икәнен миңа әйтмәделәр.

Факиһә. Соң ничек дип кенә әйттеләр?

Биби. Абзый сораса, «кодаларга киттеләр» дип әйтерсең, диделәр.

Факиһә. Ә башка кеше сораса?

Биби. Башка кеше кем сорасын? Фатих абый сораган иде дә, мин аңар әйтмәдем.

Факиһә. Менә мин сорыйм.

Биби. Син башка кешемени?

Факиһә. Йә, әйт инде, кая киттеләр?

Биби. Әй лә, әйтмим!

Факиһә. Театргамы?

Биби. Ә! Үзе дә белә икән. Аны сиңа кем әйтте?

Факиһә. Йә, бар. Алдыңа кара, эшеңне эшлә... *(Биби кереп китә.)* Шул, шул, театрга киткәннәр. Мин үзем дә сизгән идем аны сизүен. Җизни ул безнеке шикелле җебегән авыз түгел. Исенә бернәрсә төште исә, хәзер, шул минут ук эшли дә ала. Безнеке генә ул тегермән ташы шикелле, һич кузгатыр хәл юк. Тукта әле, мин дә алып бардырыйм әле. Кеше барган җирдән мин генә ни эшләп калып торырга соң? *(Бик кызуланып, сул як ишеккә кереп китә. Сәхнә бераз буш тора. Бераздан, кычкырышып, Хәбибрахман белән килеп чыгалар.)*

Хәбибрахман *(кулларын селтәп).* Бармыйм дигәч, бармыйм инде! Иң әүвәл мин аның, ул театрның кайда икәнен белмим.

Факиһә *(мыскыл итеп, бармакларын бөкләп санарга керешә).* Бу булды бер!

Хәбибрахман. Икенчеләй, кайдан керәсен, ничек керәсен белмим.

Факиһә. Ике, өч.

Хәбибрахман. Анда кергәч тә, нинди урынга утырырга?

Факиһә. Шуның белән була дүрт! Зинһар, ичмаса инде, эчеңдәге бар серләреңне сөйләп бетереп, кешене көлдермә; кеше ишетсә, «Моның белгән нәрсәсе бар микән?» ди башларлар. Кеше җаен тапканны, без генә табарбыз әле.

Хәбибрахман. Кирәкми, бармыйбыз; мин куркам.

Факиһә. Чү, чү, тагы куркуыңнан егылып китә күрмә! Шулкадәр зур гәүдәң белән «куркам» дип әйтергә сиңа кешедән оят!

Хәбибрахман. Кирәкми, бармыйм!

Факиһә. Нинди бармаган да нинди нитмәгән! Кеше барган җирдән без генә калып торырга! Әйдә, әйдә, барабыз! Җизниләр әле алар үткән атнаны плашкигә[1] дә чыктылар. Без анда да авызыбызны күтәреп калдык, кияве белән кызы барган булгач, эткәй дә бер сүз дә әйтә алмас. Әйдә, тотабыз да барабыз. Нәрсәгә соң без генә ул кадәр куркып торырга!

Хәбибрахман. Бармыйм дигәч, бармыйм инде.

Факиһә *(юмаларга керешеп)*. Җә инде дим! Барыйксана инде! Харап булган икән! Гомеремә бер мәртәбә бер җиргә барыйк дигәнмен икән инде, шуны да тыңламыйсың. Эткәйдән куркып торырга син кечкенә сабый бала түгел ич инде! *(Хәбибрахман эндәшми.)* Җә дим инде, нигә эндәшмисең? Орышса, кайткач бер орышыр да бетәр. Аның өчен сине ашый алмас бит ул. Әгәр дә бик каты дулый башласа, һич булмаганда, мин үзем аны көчләп алып бардым, диярмен. Орышса, мине орышыр, сине орышмас.

Хәбибрахман *(башын кашып)*. Белмим шул, ничек булыр икән? Минем үземнең дә бер күрәсем килә килүен ул театр дигән нәрсәне. Әле мин син йөдәтерсең дип әйтмәгән идем, Гайнулла җизнинең кияве Гаптерәхимнәр дә «барабыз» дигәннәр иде.

Факиһә. Соң алай булгач, тагын ни кирәк инде? Кеше бармый торган җирмени ул? Кеше баргач, бергә-бергә күңелле дә булыр. Әйдә, өстеңә киен дә, барабыз. Мин дә хәзер киенеп чыгам. *(Кызуланып, уң як ишеккә кереп китә.)*

Хәбибрахман *(ишеккә таба карап, үз-үзенә)*. Мин әле барам дип әйтеп бетерергә дә өлгерә алмадым, ә ул киенергә дә кереп китте. Нишләргә икән инде, шулай ук барырга туры килер микәнни? Эти орышмас микән? Без чыгып киткәнче, кайтып керсә генә ярар иде. Бармый калыр идек. Хатын ул

---

[1] Плашкигә — табигать кочагында күңел ачарга.

этинең гадәте начар икәнне белми. Беркөнне Гали хажи Гаптерахманы белән чәйгә кергән өчен дә колагымны шулай итеп борып алды. *(Борып күрсәтә.)* Күзләремнән утлар күренде. Аны кешегә сөйләп йөреп булмый. «Әти колакны борды»,— дип, хатынга әйтсәң, хатын хәзер ул: «Һәй, нәни бәби! Шул башың белән колагыңны бордырып торасыңмы?» —дип мыскыл итәргә тотына. *(Кесәсен капшап.)* Барабыз баруын да, әле кесәдә барырлык акча бар микән? *(Портмонетын алып, акчаларын өстәлгә бушатып саный.)* Унбиш тиен дә унбиш тиен — утыз тиен, тагын унбиш тиен, була кырык биш тиен. Тагын биш тиен, булды илле тиен; илле тиен дә егерме тиен, була җитмеш тиен. Тагын илле тиен. *(Бармаклары белән исәпләргә керешеп.)* Йөз, йөз ун, йөз егерме, булды бер сум да егерме тиен. Бусы өч тәңкә, барысы була... *(Яңадан исәпләп.)* Ике, өч, дүрт, дүрт сум да егерме тиен. *(Портмонетына сала.)* Өч тәңкәсенә билет алсак, каладыр бер сум егерме тиен. Анысы барырга-кайтырга булса; хәер, җитә икән җитүен, түлке бер дә барасы килми шул. Ичмаса, әти дә кайтмады. Әллә бармыйм микән? Ничек итеп бармый калырга? Ә, булды. Менә монда качып утырам да әти кайткач кына торып чыгам. *(Диван башына барып посып утыра. Факиһә килеп чыга.)*

Ф а к и һ ә *(үз-үзенә)*. Әле һаман теге ужым бозавы киенеп чыга алмаган икән. Нишләп тора икән инде тагын? *(Сул як ишеккә кереп китә.)*

Х ә б и б р а х м а н *(башын бераз күтәреп карап, бик шатланып)*. Аллага шөкер, котылдым, күрмәде. Әти кайтыр инде.

Ф а к и һ ә *(ишектән чыгып)*. Анда юк, әллә кая киткән, шундый чакларда, анасы кыйнамасын дип качкан балалар шикелле, кача торган гадәте бар иде, бер-бер җирдә качып тормыймы? *(Эзләргә тотына. Почмакта тора торган кресло артларын карый; Хәбибрахман бу вакытта, балалар шикелле, башын эчкә яшерә. Факиһә килеп күрә дә, акрын гына көлеп, диванның икенче башына барып, аягы белән идәнгә тибеп кычкыра.)* Һәй, бәдбәхет! Күсе бар!

Х ә б и б р а х м а н. Һай! *(Сискәнеп сикереп тора.)*

Ф а к и һ ә. Һа, һа, һа! Анда син бар иденмени? Мин белмәдем. Ул кадәр куркытмаган булыр идем. Анда ни эшләп утырасың?

Х ә б и б р а х м а н *(ни әйтергә дә аптырап торып)*. Акчам төште. Шуныаладыр идем.

Факиһә. Нинди акча?

Хәбибрахман. Менә театрга барырга акча җитә микән дип санап торадыр идем дә, берсе төшеп китте.

Факиһә. Шул гомердән бирле әле өстеңә киенмичә акча санап тордыңмы?

Хәбибрахман. Мин хәзер киенәм. Башыма бүрек киям дә тунымны гына киям. *(Кереп китә.)*

Факиһә *(кычкырып кала).* Кара аны, анда да кәнәфи башына акчаңны төшермә, анда да күсе булыр. *(Көзге каршына килеп, шәлләрен, калфакларын төзәтә башлап.)* Ну, ир соң! Ир димәсәң, хәтере калырлык бар. *(Ишеккә карап.)* Биби! Биби! *(Биби чыга.)* Әткәй безне: «Кая киттеләр?»— дип сораса, «Кодаларга киттеләр»,— диген.

Биби. Ник, анда җизниләр киттеләр бит. Сез дә шунда барасызмыни?

Факиһә. Без театрга барабыз, әмма син шулай дип әйт.

Биби. Ярый, әйтермен. Бая җизни, син әйтә белмисең дип, мине яңадан әйттереп карап маташа.

Факиһә. Әйтә белдеңме соң?

Биби. Ник белмәскә, белдем.

Факиһә. Йә әле, тагын әйтеп кара. Безне кая киттеләр диярсең икән?

Биби. Әллә белмәс дип беләсеңме? Мин инде Фатих абыйдан күптән өйрәнеп куйдым. «Театрга киттеләр» диярмен.

Факиһә. Һи, аңгыра! Җебегән авыз! Мин сиңа алай дип әйтергә куштыммыни?

Биби. Ник, үзең әйттең ич: «Җизниләр кодаларга киттеләр, сез дә шунда барасызмы?» — дигәч, «Юк театрга барабыз»,— дип...

Факиһә. Күп телеңә салынма. Яхшы тыңла, әгәр дә әткәй сораса, «Кая киттеләр?»— дип, «Кодаларга киттеләр»— диген.

Биби. Ярый, ярый, аңладым. «Икесе дә шунда киттеләр»,— диярмен.

Факиһә. Кая?

Биби. Кодаларга.

Факиһә. Бар, эшеңдә бул! *(Биби кереп китә. Хәбибрахман тунының югары төймәсен төймәли-төймәли чыга.)*

Хәбибрахман. Әйдә, булдым.

Факиһә. Әйдә, әйдә, булсаң, тизрәк атла аягыңны *(Ишектән чыкканда Хәбибрахманның аркасыннан этә.)*

Хәбибрахман. Тукта! Тәрткәләмә инде ул кадәр! Чыгам ич. *(Чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Бераздан Фатих килеп керә.)*

Фатих *(як-ягына каранып).* Абзый кая икән әле? Кеше бәйрәм итә дә итә, мин дә бераз бәйрәм итеп аласы иде. Һәммә кеше йөри дә йөри, мин генә тик ябылып ятам, миңа ни бәйрәм юк, ни җомга юк. Бәйрәм булды исә, ишек төбе сакла. Көне буе байга килгән кешене өйгә алып кер дә чәй эчерт, җомга булды исә, ишегалдында утын яр да кар көрә! Юк инде, булмас болай итеп. Әһем, әһем. *(Тамак кыра.)* Әллә бөтенләй өйдә дә юкмы? *(Ишекләрне карана.)*

Биби. Әһем, әһем. *(Ишектән чыга.)* Нәрсәгә тамак кырып йөргән буласың?

Фатих. Абзый өйдәме?

Биби. Өйдә...

Фатих. Ни эшли?

Биби. Тире җыеп, күн эшли.

Фатих. Йә, шаярма әле, чынлап әйт әле, өйдәме?

Биби. Ни эшкә ул сиңа?

Фатих. Кирәк.

Биби. Әүвәле әйт ни эшкә икәнен, аннан соң әйтәм.

Фатих. Йә, әйт инде, шаярма.

Биби. Нәрсә бирәсең, әйтәм.

Фатих *(шаярып).* Әйтсәң, сине үземә хатынлыкка алырмын.

Биби. Һи, мәхәббәтсез!

Фатих. Мәхәббәтсез? Мин нишләп мәхәббәтсез булыйм? Кара бу мыекларны! *(Мыекларын борып күрсәтә.)* Кызларның калфак чугына ярарлык.

Биби. Йә, йә, бар, мыскыл итмә! Бар, чык! Абзый кайтыр, абыстай да хәзер менәр.

Фатих. Күптән шулай диләр аны, мин синнән баядан бирле: «Абзый өйдәме?» — дип сорыйм ич. Өйдә булмаса, хуш, сау бул. *(Чыгып китә.)*

Биби *(үз-үзенә).* Ялганлый торгандыр ла ул, мине алдар өчен генә, юри генә әйтә. *(Кереп китә. Бераздан Хәмзә бай кайтып керә. Күрмиенчә, ишек төбенә җәеп куйган паласка сөртенә.)*

Хәмзә *(кычкырып).* Гөнаһ шомлыклары! Аяк астына әллә нәрсә җәеп куйганнар. Мал кадерен белмиләр. Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да бернәрсә дә күреп булмый.

(Күзлеген сөртә.) Беркөн мәдрәсәгә кергәч тә, әчелектәге[1] башмакларга сөртенеп, лаканга егылган идем. *(Ишек янындагы урындыкка утырып.)* Әй, кая, кайсыгыз бар анда? Аякны тартыгыз әле. *(Биби килеп чыга.)* Кая, кил, нәрсә терәлеп торасың, тарт аякны! *(Биби салдыра башлый.)* Чү, чү, чү, карап тарт! Абыстаң кая? *(Биби киез итекнең берсен салдыра.)*

Биби. Аш өендә.

Хәмзә. Нишли анда?

Биби. Аш пешерә.

Хәмзә. Ник, килен кая?

Биби. Алар Хәбибрахман абый белән ни... ни... әй... кодаларга киттеләр.

Хәмзә. Ныграк тарт! Кулың чергән мәллә? *(Биби, кинәттән тартып җибәреп, Хәмзәне егып төшерә.)* Һай, бәдбәхет! Күзең чыккан нәрсә! Бар, кит, күземә күренмә! *(Биби кереп китә. Хәмзә, мәшәкатьләнеп, аягын салып бетерә.)* Башка кеше булса, мин аңар кирәген биргән булыр идем булуын, әллә ничек, кыз балага сугарга ул кадәр кул барып җитми. *(Тунын салып, чөйгә элеп куя.)* Бүген иртә белән чәч алучыга кергән идем, бөтенләй ишегеннән керер хәл юк. Җыен кызыл авыз кибетчеләр тулган. Байларына бөтенләй әйләнеп тә карамыйлар, чәч алучысы да һич санга санамый: «Хаҗи, син әле башка көнне дә керерсең, син бай кеше, һәрвакытта да вакытың бар; болар бит бай кешесе, җомга көннән башка вакытта вакытлары булмый»,— дип, авызын ерып тик тора. Алары да шул кибетчеләр яклы. Аларга кибетчеләр яклы булмыйча ярыймы соң? Кибетчеләр бит аларга унар, унбишәр тиенләп яудыралар. Аларга бай акчасы кызганычмыни... Биби, Биби! *(Ишектән Биби чыга.)*

Биби. Нәрсә дисез, абзый?

Хәмзә. Бар әле, берәрсенә әйт әле, мәдрәсәдәге Коръән укый торган шәкертне чакырып чыксыннар. «Абзый чәч алырга чакыра»,— дисеннәр.

Биби. Нинди мәче алырга?

Хәмзә. Һай, аңгыра, җебегән нәрсә! Мин сиңа мәче алырга дидеммени? Чәч алырга дим! Чәч! *(Үз чәчен тарткалап.)* Менә, менә шушыны алырга дим! *(Биби чыгып китә.)* Бу

---

[1] Әчелек — мәдрәсәдәге чишенү бүлмәсе.

кадәр аңгыра булырлар икән. Җыен аңгыра безгә җыелган. Беркөн Хәбибрахманга: «Бар, агач базарына Хисмәткә бар да аны тизрәк монда алып кайт»,— дип җибәргән идем, барган да бер зур кисмәк алып кайткан. Менә бу сакалымны шулар гына агартып бетерделәр инде. Әле ярый хәзергә үзем исән-сау. Үзем үлгәч, болар дөньяда ничек итеп көн күрерләр? *(Биби ишектән килеп чыга да тик тора. Аңа карап.)* Нихәл, нишләп терәлеп торасың анда?

Биби. Абзый, Миңлебай абзыйга әйткән идем: «Коръән укый торган шәкертне алып чык»,— дип, «Нинди шәкерт ул, мәдрәсәдәге шәкертләр алар бар да Коръән укыйлар, анда Әфтияк укучы юк»,— ди.

Хәмзә *(аяк тибеп)*. Һай, ахмаклар! Әрәмтамаклар! Бар, тизрәк чыгып әйт, мәчеттә Коръән укый торган шәкертне — Гайфулланы чакырып чыксын!

Биби. Икесен дә чакырсынмы?

Хәмзә. Нинди икесен дә?!

Биби. Коръән укучыны да, Гайфулланы да?

Хәмзә. Үләм инде мин сезнең белән, җәфаланып үләм! Аңгыра. Соң шул Коръән укучы шәкерт белән Гайфулла икесе дә бер ләбаса инде! Бар тизрәк! Гөнаһ шомлыгы! *(Биби чыгып китә.)* Менә инде син сөйләш алар белән. И Алла! И Алла! Ахры инде, дөньяда акыллы кеше үк калмагандыр. Ничә елдан бирле өйрәтеп тә, игә китерер хәл юк. Һәр көн шулай башымны катырып бетерәләр. Тукта инде, әүвәл тизрәк чәчемне алдырыйм да аннан соң, тәһарәт алып, догаларымны укырмын. *(Ишеккә таба борылып.)* Әй! Кая сез? Башымны чылатырга сабын, су бирегез. *(Ишектән кереп китә. Бераздан чынаяк, подносларкүтәреп, Биби керә.)*

Биби. Үзләре юньләп йомыш куша белмиләр дә кешене орышалар. *(Чәй урыны хәзерли.)* Көне-төне эшлисең дә эшлисең, аның өстенә тагын һәр көн орыш та талаш. Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга киткәннәрен әйтәм. Мине генә орышмасын әле, аларны да орышсын. *(Ишектән Хәмзә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән. Бер кулына яшел кәләпүшен, бер кулына күзлеген тоткан.)*

Хәмзә. Бар, миңа муенга салырга эскәтер китер! *(Биби чыгып китә. Хәмзә, өстәл янына килеп, кәләпүшен, аның янына күзлеген куя. Биби бер каралган кызыл эскәтер китереп*

бирә. Бибигә карап.) Кая, миңа урындык бир әле. *(Кызыл эскәтерне муенына бәйли, Биби урындыкны китереп бирә. Янә Бибигә карап.)* Бар әле, теге якта камут тартмасында минем плитувам бардыр, шуны монда китер. *(Биби чыгып китә, Хәмзә урындыкка утыра.)* Заманалар бозылды. Әле менә бүген теге урыс сымак нәрсәләр театр уйнап, динне мәсхәрә кылмакчы булып йөриләр икән. Шуны булдырмаска йөреп, бүген ясигъка[1] бара алмый калдым. «Уйнатмагыз, рөхсәт юк!» — дип, Җамали үндергә әйткән идек, ул: «Минем эшем түгел, пристефкә үзенә әйтегез»,— диде. Пристефне өйдә туры китереп булмады, галавага менгән идек, ул да алар яклы булырга кирәк: «Минем эшем түгел, сез палисәмистергә барыгыз»,— диде. Аңа барган идек, бакзалга киткән. Губирнаторга да барган идек, бутишник[2]: «Ул бу вакытта кеше кертми, иртәгә сәгать уникедә килеңез»,— диде. Шулай итеп, ахрысы, бәдбәхетләрне туктатып булмады. Алла боерса, икенче вакыт уйнатмабыз әле, пристефне алдан ук күреп куярбыз. *(Ишектән Биби килеп керә, аңа карап.)* Нихәл, булдымы?

Биби. Менә булды. *(Бритваны өстәлгә китереп куя.)* Коръән укучы шәкерт өйдә юк, ди, иптәшләре белән театрга киткән, ди.

Хәмзә *(ачуланып)*. Ходай орган икән! Йөзләре генә кара булсын, бар, чакыр монда Фатихны!

Биби. Фатих абый ул син кайтканчы ук чыгып китте.

Хәмзә. Кая?

Биби. Шунда китте.

Хәмзә *(ачуы тагын да кабарып)*. Кая шунда?

Биби. Шунда инде, театрга китте.

Хәмзә. Ә? Театрга? Кемнән сорап китте?

Биби. Берәүдән дә сорамады. Вәли кияүләр белән Хәбибрахманнар да киткәч, мин генә нишләп калыйм, диде дә китте.

Хәмзә. Ә? Ни дисең? Вәли кияү дә китте дисеңме?

Биби. Китте. *(Хәмзә урыныннан сикереп тора.)*

Хәмзә. Хәбибрахман да киттеме? *(Бибинең өстенә бара.)*

Биби *(кире чигенеп)*. Китте.

---

[1] Ясигъ — йокы алдыннан укыла торган намаз.

[2] Бутишник — каравылда торучы полицейский.

Хәмзә *(яңадан өстенә барып).* Гафифә? Факиһә?!

Биби *(яңадан кире чигенеп).* Алар да киттеләр. *(Хәмзә кулларын йомарлап, иреннәрен тешләп, «эмммм!» дип, Бибинең өстенә килә башлый, Биби чыгып кача.)*

Хәмзә *(Биби чыгып киткәч, халыкка таба карап, кулларын сузып).* Йә, әйтегез инде, зинһар, нишләтим инде боларны? *(Гайрәтләнеп.)* Юк! Боларны болай гына калдырырга ярамый, йөзе караларны! Барам да якаларыннан тотып, өстерәп алып кайтам. *(Кәләпүшен алып кия.)* Һай, йөзе каралар икән! Акылымнан шаштырасыз инде! *(Тиз генә эскәтерне муеныннан тартып алып, башын сөртә-сөртә, киемнәргә таба бара.)* Мин сезгә бирим әле кирәгегезне! *(Өстенә кия башлый, кычкыра.)* Кая киез ката? Китерегез тизрәк, ә менә монда икән! Йөзе караларны! *(Ашыгып-ашыгып кия.)* Бәдбәхетләрне, муены астына килгәннәрне!.. *(Чыгып китә.)*

Пәрдә төшә.

Комедиягә анализ

Дәреслектә бирелгән әсәрләрнең жанрына игътибар итик: алар — икесе дә комедия. Ә комедия жанры сатира әсәрләре төренә керә. **Димәк, Галиәсгар Камал көлеп тәнкыйтьләргә яратучы язучы дип, беренче нәтиҗәне ясый алабыз.**

Көлеп тәнкыйтьләүчеләр күп. Галиәсгар Камалның алардан аермасын белү өчен, кемнәрдән көлүен һәм ничек көлүен ачыкларга кирәк.

Әсәрнең жанр үзенчәлеген искә төшерик.

Юмор-сатира жанрына төп сәнгать алымнарының икесе хас.

1. Әсәр өлешләре арасындагы каршылык һәм чамадан тыш арттыру.

Комедиядә автор бер үк сүзне үз эчендә каршылыкка китерә: «Хисмәт» дигән сүзгә «кисмәк» сүзе охшаган. Биби бу сүзләрне буташтырып көлкегә кала.

> Бер сүзне икенче шуңа охшаган сүз итеп кабул итү аркасында эчтәлекләр каршылыгы тудыру алымына **каламбур** диләр.

Биремнәр

1. Пьесадагы шул рәвешле каршылыкка килгән сүзләрне табыгыз.

Юморны каламбур алымы белән тудыру — җиңел алым, ул әллә ни югары бәяләнми. Әмма Галиәсгар Камал аны көлке тудыру өчен генә файдаланмаган, каламбур яки, татарча итеп әйтсәк, **сүз уйнату** алымы белән персонажларының холкын ачкан һәм көлкеле вакыйга тудырган.

Драматургның юморист буларак бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт: аның әсәрләрендә хәтта сүз уйнату алымы да очраклы күренеш түгел, әсәрнең эчтәлеген тудыруга хезмәт итә.

Юньсез кешеләрне көлеп тәнкыйтьләүнең сатира булуын беләбез.

> Сатираның төп алымы кире персонажның дәрәҗәгә дәгъвасы белән эчке бушлыгы арасында каршылык тудырудан гыйбарәт.

2. Хәмзә байның дәрәҗәгә дәгъвасы (үзен милләт әхлагын саклаучы көрәшче итеп хис итүе) белән эчке бушлыгы арасындагы каршылыкны мисаллар белән исбат итегез.

2. Галиәсгар Камал чамадан тыш арттыру алымын да яратып куллана.

Гафифә — үзе куркак, шул ук вакытта матур күренергә яратучы хатын. Автор, Гафифә холкының бу сыйфатларыннан көлү өчен, аның куркаклыгын һәм кием сайлавын каткат кабатлый. Бер үк гамәлне чамадан тыш күп кабатлау да арттыру алымына керә.

3. Әсәрдән чамадан тыш арттырылган башка вакыйгаларны да табыгыз.

Пьеса язылган заманда, Хәмзә бай кебек искелеккә ябышып ятучы властьлы кешеләр күп булган. Алар теләсә нинди яңалыкка каршы көрәшкәннәр. «Театр» вакыйгасы — шундый каршылыкка очраган бик күп яңалыкларның берсе генә. Шуңа күрә Хәмзә байның театр куюга каршы булуын киңрәк мәгънәдә аңларга кирәк. Хәмзә бай кебек кешеләр көчле, усал, куркыныч. Андый кешеләр теләсә нинди яңалыкка каршы, шулай зәһәрләнеп, үзләренә ярдәмгә власть вәкилләрен дә кушып көрәшәләр. Шуңа күрә Г. Камалның бу комедиясендәге тема бүген дә актуаль.

Бүләк өчен

(Комедия бер пәрдәдә)

УЙНАУЧЫЛАР:

Әхмәтҗан — Казан бае, 45 яшьләрендә.

Хәмидә — Әхмәтҗанның хатыны, 45 яшьләрендә.

Габдуллаҗан — Әхмәтҗанның улы, 22 яшьләрендә.

Мәхүпҗамал (Мәхүп) — яучы хатын, 60 яшьләрендә.

Бәдриҗамал — асрау.

Казанда, Әхмәтҗан байның өендә. Өй җиһазлары иске заман нәрсәләре белән кара-катыш. Стенада рамкалы язулар. Пәрдә ачылганда Әхмәтҗан белән Хәмидә күренә. Габдуллаҗанны өйләндерү хакында киңәш итәләр.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәтҗан, Хәмидә.

Әхмәтҗан. Теләсәң нәрсә диген, хатын, мин бер дә төшенмим.

Хәмидә. Бер дә төшенәсе-нитәсе юк, кызы — менә дигән кыз. Ул матур, ул сылу, күрсәң — исең китәр. (*Урта бармагын күрсәтеп.*) Урта бармак шикелле бер кыз инде.

Әхмәтҗан. Тукта әле, хатын, мин тагы да төшенмәдем; үзең әйтәсең: «Бик матур, бик сылу»,— дип, ә үзең тагы әйтәсең: «Урта бармагың төсле»,— дип. Синең урта бармагың төсле буынтыклы-буынтыклы булса, бер дә матур булмый инде ул.

Хәмидә. Җә, ярар инде. Мыскыл итеп утырган булма. Бар кеше дә синең шикелле итеп сөйләшә белми. Син генә ул бик матур итеп сөйләшәсең. Алай мыскыл итмә. Урта бармак шикелле дигәнне яратмасаң, шәм шикелле инде, алайса.

Әхмәтҗан. Монысы инде тагы да начар булды. Шәм шикелле иелми-бөгелми торган, үрәгә каткан нәрсә булгач, безгә бер дә мәгъкуль[1] кеше түгел икән. Ул, алай булгач, мине дә, сине дә, Габдуллаҗанны да искә-санга алмас.

Хәмидә. Бар икән, Ходаем! Мине һаман мыскыл итәсең, мин сиңа чынлап сөйлим, ә син һаман миннән көләсең.

Әхмәтҗан. Бер дә көлмим, бары тик син шәм шикелле дигәч, иелми-бөгелми торган бер кыздыр дип кенә әйтәм.

---

[1] Мәгъкуль — лаек, яраклы.

Хәмидә. Юк, юк, атасы, бик чибәр, бик әйбәт кыз, бөтенләй менә, каймак шикелле бер кыз инде.

Әхмәтҗан. Чәйгә салып эчәргә дә яраклы икән, алайса.

Хәмидә. Тагын көләргә тотындың инде! Каймак дигәнне яратмасаң инде, алайса, кәләвә шикелле, бал шикелле, кәнфит, прәннек шикелле.

Әхмәтҗан. Хатын, инде алай булгач, мин бернәрсә дә әйтә алмыйм. Ул кадәр баллы нәрсә булгач, бик төче нәрсә булып, безне бөтенләй үтләтеп бетермәсә ярар иде дип куркам.

Хәмидә. Бер дә хафаланма, атасы, килешерләр әле, Габдуллаҗан да бик яратыр. Менә үзебез бит әле егерме биш елдан бирле бик әйбәт, бик килешеп торабыз.

Әхмәтҗан. Торса бит, син алай кәнфит шикелле баллы гына түгел идең, синең әчкелтем-төчкелтем чакларың да бик күп буладыр иде. Син бит кайсы вакытта керән, гәрчитсә шикелле әче булып, бөтенләй күзләремнән яшьләр китерә торган идең.

Хәмидә. Ансы өчен бер дә хафаланма, денья булгач, аларның да әче вакытлары булыр әле. Озак торгач, бал да чымырдап әчи, безнең Габдуллаҗан үзе дә әче суганнан бер дә ким булмас.

Әхмәтҗан. Җә, сүзем бетте инде, алайса, үзегез Габдуллаҗан белән теләсәгез ничек килешегез. Әле тик беркөннәрдә үзең, Хәйриләрдән аштан кайткач: «Хисаминың кызын күрдем, бигрәк конарсыз[1] нәрсә икән — үзе озын, үзе чыра шикелле, шадра, авызы кыек, чепи күзле, кәкре аяклы, шулай да булса, тагын әллә кем булган булып, бүксәсен киереп утырган була»,— дип сөйләгән идең. Үзең шулай дип сөйләгәнгә күрә генә, безгә муафикъ[2] кеше булмас дип куркам.

Хәмидә. Юк, юк, атасы, бер дә курыкма! Бик әйбәт, бик сылу, бик уңган, җиләк шикелле бер кыз. Эшкә-кешкә дә оста, бик булган, бик чибәр, бик купшы, ди. Вәгъдә бирнәсенә дә, кәбен бирнәсенә[3] дә, актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт, калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар, ди. Безгә дигән намазлыкларын да, кияүгә дигән аякчу, намаз-

---

[1] Конарсыз — ямьсез.

[2] Муафикъ — яраклы.

[3] Кәбен бирнәсенә — никах укытканнан соң бирә торган бирнә.

лыклар белән бергә, моннан үрнәкләр җибәреп, иллешәр тәңкәгә Мәскәүдән эшләтеп китерткәннәр, ди. Вәгъдәгә дә өч төрле как-төш бирәчәкләр, ди. Кияүгә дигән кәләпүшне мыскалы егерме бишәр тәңкәлек кырык мыскал энҗедән эшләтәчәкләр, ди. Кияүгә булачак сәгатьне Хисами кода үзе...

Әхмәтҗан. Тукта әле, Хисами безгә әле кода булып җитмәгән.

Хәмидә. Җә, ярар ла, җураган җуп килә, диләр. Кода булачакка күрә авызыма шулай туры килеп торадыр инде. Нәрсә әйтәдер идем соң, ә, әйе, кияүгә дигән сәгатьне Хисами кода үзе...

Әхмәтҗан. Хисами кода түгел!

Хәмидә. Ярар ла инде, Хисами бай үзе Мәскәүгә барып, ике йөз тәңкәгә алып кайткан, ди. Ул чипүшкәсен[1] күрсәң, менә бөтенләй искитәрлек, ди. Әсма кодагый...

Әхмәтҗан. Тфү! Әсма да кодагый түгел бит әле.

Хәмидә. Җә, җә, Әсмабикә...

Әхмәтҗан. Кичә генә «курнус Әсма» дип йөриләр иде әле, хәзер инде бүген бикә дә булып җиткән.

Хәмидә. Бикә булмый ни, бикә шул! Әсмабикә кияүгә берлиант[2] кашлы йөзек тә алдырып бирмәкче була, ди.

Әхмәтҗан. Уф, тыңлап торып та арып беттем инде.

Хәмидә. Арырсың да шул, ул кадәр күп нәрсә биргәч. Син үзең әле Газизәне биргән вакытта гомердә Хисами кода...

Әхмәтҗан. Кода түгел дим!

Хәмидә. Хисами бай шикелле итеп бирә алмассың.

Әхмәтҗан *(халыкка карап)*. Бай, имеш, Мәскәү малы белән кибетен тутыргач та, хатын аны бай дип белә тагын.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп)*. Карават чаршаулары да плүштән булачак. Караватын да Хисами кода, әй, ялгыш әйтәм, Хисами бай, Мәкәрҗәгә барганда, йөз егерме тәңкәгә алып кайткан. Ул савыт-саба, урын-җир, түшәк-ястык, сөлге, эскәтер, тастымал, намазлык, чаршауларның бер дә иге-чиге юк, ди.

Әхмәтҗан *(халыкка карап)*. Тәмам бер талчук кибете ачарлык бар икән.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп)*. Ун сандык нәрсә мал белән дың тулы, ди. Хисами кода... әй, тфү, Хисами бай

---

[1] Чипүшкә (цепочка) — сәгать чылбыры.

[2] Берлиант — *бриллиант* — асылташның бер төре.

приданны да бик яхшы итеп хәзерләтмәкче була, ди, «Кызларым байлыгым бар вакытта рәхәтләнеп калсыннар, һәммә җирләрен җитеш итеп бирәм, үз исәнлегемдә урнашып калсыннар»,— дип әйтә, ди. Ун табынлык савыт-саба алган.

Әхмәтҗан *(халыкка карап).* Әүвәлгеләре мануфактур кибете булган иде, инде монысы белән чынаяк кибете ачарга мөмкин булачак.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Чәнечке, пычаклары — һәммәсе дә көмеш саплы булачак. Самовары, чәйнекләре, куфи савытлары бары да көмештән.

Әхмәтҗан *(халыкка карап).* Йа, Алла, башым катты инде.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Горкы шкафы бик зур, бик әйбәт, кызыл агачтан ясалган, ике дүжинә урындыклары, көзгеләре — һәркайсы кызыл агачтан, ди. Ике өстәл, турицкий диван, кәнәфи белән йомшак эскәмияләр...

Әхмәтҗан *(халыкка карап).* Йа, Алла, кайчан гына туктар икән!

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Гелдируплар (гардероб), кантур өстәлләре дә бирәчәк, ди. Ул шарлы лампаларының матурлыгына бер дә чама юк, ди. Ләгән-комганнары һәммәсе никельдән булачак, ди. Тагы көмеш...

Әхмәтҗан. Уф! Йә, зинһар, җитәр инде, тыңлап торып та арып беттем. Ул әйткән нәрсәләрнең бары да булса, зур кибет ачарлык мал булыр. Без аны кайда куеп бетерербез? Ул нәрсәләрне куярга аңар үзенә бер йорт салырга кирәк булыр.

Хәмидә. Аның өчен бер дә кайгырма, малы булгач, куярга урыны табылыр. Хисами кода...

Әхмәтҗан. Кода түгел әле!

Хәмидә. Ялгыш әйтәм. Хисами бай Габдуллаҗанны бик яраткан, ди. Шуңа күрә бер сүз дә әйтмиенчә бирмәкче була, ди.

Әхмәтҗан. Йә, ярар, хәерле булсын. Әнә үзең теләсәң ничек итеп Габдуллаҗанны күндер дә, ул үзе риза булса, алырбыз. Габдуллаҗанны чакырт та үзең сөйләш. *(Чыгып китә.)*

ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Хәмидә ялгыз, үзалдына сөйләнә.

Хәмидә. Безнең өйдә бер дә акыллы кеше юк. Шулкадәр бай кеше «кызымны бирәм» дип торган чакта, сакалыңны салпырайтып, «мин белмим» дип утыр имеш. «Кыз матур

түгел»,— диләр. Аның матурлыгы пычагымамыни? Мәхәббәтләре генә булсын. Үзебез әле менә егерме биш елдан бирле торабыз. «Син ямьсез» дип, урамга чыгарып ташлаган кеше юк. Матур да булса, буе-сыны да кешенеке төсле булса, андый бай кешеләр шулкадәр бүләкләр бирә-бирә, кызларын безгә этеп-төртеп бирмәсләр иде. Баланы егерме ел үстереп тә, бер юньле, яхшы бирнә дә киеп калмагач, дөньяда торганың ни дә, тормаганың ни! Әнә Гыйльми Бәдриенең кызы бик чибәр дә бит, матурлыгына карап аны алып булмый. Аларның җүнле бирнә бирәселәре дә юк, күп булса бер асыл бирнә бирерләр. Кодагый булган кешенең ашлы-сулы, бай булганы күңелле. Улыңны өйләндереп тә, бер рәхәтләнеп кунакка йөреп калмагач, дөньяның ни рәхәте бар, дөнья ике килми ул. *(Ишектән, кулына бер китап тотып, Габдуллаҗан килеп керә.)*

ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Хәмидә, Габдуллаҗан.

Габдуллаҗан. Әни, аш тиз буламы? Минем учительгә барасым бар.

Хәмидә *(артына борылып карап).* Әйдә, кил әле монда, учительгә барырга аннан ары да өлгерерсең. Урыс сабагы укып йөрергә син кечкенә бала түгел инде. Кил әле, утыр менә монда, без сине хәзер өйләндермәкче булабыз.

Габдуллаҗан. Кемне?

Хәмидә. Сине.

Габдуллаҗан. Кит аннан, мин өйләнмим! *(Чыга башлый.)*

Хәмидә. Тукта, кайда барасың? Мин бит сиңа уйнап сөйләмим, син бит инде бала түгел.

Габдуллаҗан. Әле беркөн генә үзең Гыйльми Бәдриләреннән яучы килгәч: «Әле улыбыз бик яшь, бала гына әле, өйләндермибез»,— дигән идең.

Хәмидә. Йә, күп телеңә салынып торма, кил, утыр! Менә хәзер яучы киләчәк, вәгъдә куеп җибәрәбез. Атаң да бик мәгъкуль күрде.

Габдуллаҗан. Кемнән киләчәк?

Хәмидә. Хисами байдан, Хисами бай сине күреп бик яраткан да сиңа бик зур придан белән кызын бирмәкче булган.

Габдуллаҗан. Мин ул кызны бер дә күргәнем юк бит.

Хәмидә. Җүләр, кызны күреп алалармыни аны? Менә мине дә атаң күреп алмады.

Габдуллаҗан. Мин беркөн «Өйләнү» дигән бер китап укыдым. Анда алачак кызның ни төстә икәнен, холкын-фигылен белеп алырга кушкан.

Хәмидә. Куй ул юк сүзләреңне, бетмәс андый сезнең такмаза китапларыгыз. Син шуны әйт: ризамы, юкмы?

Габдуллаҗан. Тукта әле, әни, ул кыз соң нинди, ни төстә, буе-сыны ничек, матурмы?

Хәмидә. Ансын бер дә тикшереп торасы юк, кыз бик һәйбәт, бик матур.

Габдуллаҗан. Буе озынмы?

Хәмидә. Озын, озын, бик озын, бик зифа!

Габдуллаҗан. Мин укыган китапта хатынның буе иреннән бераз кыскарак булсын дигән.

Хәмидә. Озын дигәч тә, синең шикелле үк озын түгел инде. Синнән бераз кыскарак булыр.

Габдуллаҗан. Кашы ни төсле, карамы?

Хәмидә. Һәммә кешенең дә кашы кара булып бетми инде. Кара булмаса да, бик матур, бик нечкә. Кара кирәк булса — буярсыз. Бу чагында инде кашны гына түгел, чәчне дә буяп йөриләр.

Габдуллаҗан. Төскә ничек, түгәрәк битлеме?

Хәмидә. Җә инде, күп сөйләнеп торма, адәм фәрештә булмый. Кеше кешедән артык булмас. Мәхәббәтегез генә булсын, мәхәббәтегез булса, хур кызыннан да артык булыр. Син бигрәк менә, нәрсәләр бирәләр, дип сора. Сиңа дигән чикмәнлекнең аршынын унике тәңкәдән алганнар, ди. Кәләпүшләре кырык мыскал энҗедән эшләнгән булачак, ди. Алтын сәгатьләрен ике йөз тәңкәгә алганнар, ди. Сиңа бик һәйбәт берлиант йөзек бирәчәкләр, ди. Ул башка приданнарының исәбе дә юк, ди. *(Әхмәтҗан килеп керә.)* Әнә атаң да кереп килә. *(Шыпырт кына.)* Күп терәлеп торма, тизрәк риза диген.

ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әхмәтҗан, Хәмидә, Габдуллаҗан.

Әхмәтҗан. Нихәл, килешәсезме?

Хәмидә. Килештек, килештек, Габдуллаҗан да риза, ди.

Габдуллаҗан. Әле мин... мин риза дип әйтеп бетермәдем ич.

Хәмидә. Ул ни дигән сүз тагын? Риза, риза, атасы, бик риза. Ата-анасы риза булган кешегә риза булмаска, ул ни дигән сүз?

Әхмәтҗан. Тукта әле, сиңа әйтәм, ата-анасы риза дип, эшне бетереп куйма әле син. Әле бит минем дә риза булып җиткәнем юк. Бая мин әле аларның нәрсә сорыйсыларын да белеп бетерә алмадым. Алар мәһәргә нәрсә сорыйлар соң?

Габдуллаҗан. Әле мин дә сорашып бетерә алмадым, ул кыз ни төсле соң?

Хәмидә *(Габдуллаҗанга)*. Тик тор син, атаң алдында әдәпсезләнеп сорап торма! Синең шикелле юләргә ярамаган тагын! Кыз кыз булыр инде, фәрештә булмас. *(Әхмәтҗанга.)* Инде дус-иш арасында оятка калырлык итеп биреп булмас. Үзләре шулкадәр зурлый торып та, бик кечкенә итеп җибәрергә ярамас.

Әхмәтҗан. Бик күп акча чыгып, кыйммәткә төшәрлек булса, нишләрбез?

Габдуллаҗан. Бик ямьсез, бик аңгыра булып, аяклы каза булырлык булса, мин нишләрмен?

Хәмидә *(Габдуллаҗанга)*. Каза, каза! Син үзең әле аяклы каза, күп лыгырдап торма! *(Әхмәтҗанга.)* Инде, акча күп чыга дип, улыңны өйләндерми тора алмассың, хәлдән килгән кадәрле тырышырсың. Дус-иш арасында биткә оят китерерлек итмәссең. Күп дип әйтергә, алар әллә нәрсә сорамыйлар: эче-тышы, өйләнәсе белән камзуллык чатма[1], аннан соң хәзерге заманча булсын дип, бер озын сак[2]. Егерме биш мыскалдан калфак — анысын инде егерме мыскалдан эшләтсәң дә ярар,— аннан ары ике зур сандык. Аннан кала, бер аксыл сирый җефәкле, чите каймасыз мамык шәл белән бер җефәк шәл, кырык мыскал энҗедән бер муен энҗесе. Аннан ары бер көзге сорыйлар. Көзгесе арты шкафлы булсын, хәзер инде баганалы көзгенең мудысы бетте, дип әйтәләр, ди.

Әхмәтҗан *(халыкка карап)*. Монысы әле аның баласы, мичтә калгандыр анасы. *(Хәмидәгә.)* Ничек тә шул дүрт-биш мең тәңкәсез котылып булмас.

Хәмидә. Нинди дүрт-биш мең тәңкә? Булса тагы, әлхәмделиллаһи, аңар гына чыдарлык хәлебез бар әле.

---

[1] Чатма — алтын яки көмеш җеп кушылып тукылган ефәк.

[2] Сак — хатын-кыз пальтосы.

Әхмәтҗан *(халыкка карап).* Ул инде, мөгаен, кибеттәге малның барысы да минеке дип белә торгандыр.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Мин башка вакытта үзем дә сине борчымыйм. Вакытлы-вакытсыз әйбер сорап җөдәткәнем юк, асыл күлмәкләрем саргаеп, саташып беткән. Шулай да синнән асыл күлмәк алып бир дип сораганым юк.

Габдуллаҗан *(халыкка карап).* Алдалый, валлаһи, алдалый, ышанмагыз, сандыкта һич киелмәгән биш-алты асыл күлмәге череп ята.

Әхмәтҗан. Бөләр хәлем юк, улымны өйләндерәм дип, бар сумамнан язар хәлем юк. Дүрт-биш мең тәңкә тотып өйләндерергә минем хәлемнән килми. Безгә нигә ярамаган уртачарак кеше? Тотарбыз да Гыйльми Бәдриенең кызын алырбыз. Аның кызы укымышлы да, төскә дә матур, диләр.

Габдуллаҗан *(үзалдына).* Менә монысы өчен әтигә рәхмәт!

Хәмидә. Алды, ди, алмый ни, ул хәерчеләрнең кызларын алып торырга кирәк! Аның анасы дөньяда бер ямьсез хатын. Кияү йөртергә бер җүнле атлары да юк. Аларның бирнәгә биргән асылларының да үтәсеннән көн күренерлек булыр. Аның шикелле сидрәп беткән асыллар минем үземдә дә бетәсе юк.

Әхмәтҗан. Кызны бит синең өчен алмыйбыз. Менә Габдуллаҗан ни әйтер? *(Габдуллаҗанга карап.)* Габдуллаҗан, син кайсын алырга риза? Хисами кызынмы, Бәдри кызынмы?

Габдуллаҗан. Бәдри кызын.

Хәмидә *(йодрык күрсәтеп).* Оятсыз, атаң алдында Бәдри кызын дип әйтеп торырга ничек оялмыйсың? Әбәү, оятсыз!

Әхмәтҗан. Соң, ничек дип әйтсен, «Хисами кызын алам» дип әйтсенмени?

Хәмидә. Алай дип әйтсә бер хәер, аларның, ичмаса, кешеләре кеше төсле. Мин ул Бәдринең хатынын гомеремдә дә «кодагый» дип әйтәсем юк.

Әхмәтҗан. Кодагый дип әйтмәсәң, башкача әйтерсең, аннан безгә ни зарар?

Хәмидә. Монысы да тагы улы белән бер яклы булган булып, миннән көлеп маташа. *(Габдуллаҗанга.)* Йә, әйт тизрәк, Хисами кызына ризамы?

Габдуллаҗан. Мин аны белмим бит. *(Мәхүпҗамал керә.)*

Хәмидә *(тиз генә урыныннан сикереп торып, Әхмәтҗанга карап, кашларын җимереп, күз кыса, аннан Габдуллаҗанга барып, акрын гына).* Кара аны, минем сүздән чыгасы булма, «риза» диген.

БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр һәм Мәхүпҗамал.

Мәхүп. Исәнмесез!

Хәмидә *(каршына барып, Мәхүпнең башыннан чапанын алып)*. Мәхүпҗамал абыстай, исән-сау килдеңме? Әйдә, түргә уз! *(Ишек янына барып.)* Бәдриҗамал! Кая, самовар куеп җибәр!

Мәхүп. Хәмидә, бер дә мәшәкатьләнмәгез, минем бер дә эчәсем килми, әле Әсмабикәләрдән килешем, аларда бик озаклап чәй эчтем. Инде, Алла боерса, алар эшне башларга торалар. Сездән вәгъдә алуга гына эшләре терәлеп тора. Мин сезнең нәрсәләр бирмәкче булганыгызны аларга барып сөйләдем, бик яраттылар. Хәмидә кодагый ул...

Әхмәтҗан. Әле Хәмидәнең кодагый булып җиткәне юк.

Хәмидә. Җә, зинһар, кешенең сүзен бүлмә әле. Кодагый булмыйча нәрсә булсын соң? Кызын биргәч, билгеле, кодагый була инде. Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, сөйлә, аңар карама! Ул әле бүген кире ягы белән торган.

Мәхүп. Әсма кодагыең әйтә...

Әхмәтҗан. Әсма да кодагый түгел әле.

Габдуллаҗан *(үз-үзенә)*. Һәм булмас та, Алла боерса, теләсәләр нишләсеннәр, мин аны алмыйм!

Хәмидә. Җә, җитәр инде, зинһар, әллә тилердеңме инде югыйсә?

Мәхүп. Җә, аның дигәненчә булсын инде, алайса, Әсмабикә әйтә: «Хәмидә — ул бик булган, бик мәнле кеше, Алла боерса, кеше арасында битебезгә оят китермәс әле»,— ди. Әле соң сез инде нинди киңәштә торасыз? Кичәге вәгъдәгездән, шаять, кайтмагансыздыр бит? Мин инде, Алла боерса, иртәгә вәгъдә бүләге итәргә килермен. Бүген шуны кереп белешеп чыгыйм дидем.

Әхмәтҗан. Ул ничек «кичәге вәгъдә»? Мин бит әле бу эшне бүген генә белдем.

Габдуллаҗан. Мин дә хәзер генә ишеттем.

Мәхүп. Ничек ул алай?

Хәмидә. Җә, сөйлиләр шунда, вәгъдәбез вәгъдә инде, Мәхүпҗамал абыстай.

Әхмәтҗан. Юк әле, анасы, син алай димә! Мин ул кадәр зурдан кубып, күп акчалар чыгарырга риза түгел.

Габдуллаҗан. Мин бөтенләй кызны алырга да риза түгел.

М ә х ү п. Сөбханалла, эстәгъфирулла! Бу ни дигән сүз! Сез мине алай итеп кеше алдында көлкегә калдыра күрмәгез. Мин инде аларга тәмам вәгъдә куеп килдем.

Габдуллаҗан. Мин андый белмәгән кызны алмыйм.

Хәмидә. Алабыз, Алла боерса, алабыз. Хәерле сәгатьтә булсын. Син дә, Габдуллаҗан, олы кешеләр алдында алай әдәпсезләнеп торма. Менә кияү булып кергәч күрерсең. Ул вакытта аны син күрмичә, әллә кем күрмәс. Кызны кияүгә күрсәтеп бирмиләр.

Мәхүп. Шулай шул, кызны инде аны кияүгә биргәндә күрсәтеп бирмиләр. *(Халыкка карап.)* Күрсәтерлек урыны булмагач, нәрсәсен күрсәтсеннәр.

Габдуллаҗан. Мәхүпҗамал абыстай, мин бит аны бер дә белмим. Чибәрме соң ул кыз?

Мәхүп. Чибәр, улым, бик чибәр. *(Халыкка карап.)* Күрсәң — гайрәтең чигәр.

Габдуллаҗан. Укыган кызмы соң ул?

Мәхүп. Укыган, улым, укыган, бик зур укыган. *(Халыкка карап.)* Әлифне таяк дип тә белми, миңа аның нигә кирәге бар? Бары тик эш кенә булсын да, үземә тиешле сәдака-хәерне генә күбрәк алыйм.

Хәмидә. Мин ул кызны кече-кечедән беләм. Бик инсафлы, бик бастырынкы, бик чибәр бала, укымышы да зур, диләр, бик озак укыды.

Габдуллаҗан. Урысча да укыганмы?

Мәхүп. Урысча да... Әһем, әһем...

Хәмидә. Укыган, укыган, бик яхшы укыган. Атасы өйләренә марҗа китертеп укыткан. Укымаган булса тагын, алгач менә үзең укытырсың.

Мәхүп *(халыкка карап)*. Бу миңа караганда да ялганларга остарак икән. Ул кадәресен әйтергә минем телем бармаган иде.

Хәмидә. Шул инде менә, алайса, Мәхүпҗамал абыстай, иртәгә вәгъдә бүләге алышырбыз диген.

Габдуллаҗан. Мин әле һаман риза булып җиткәнем юк.

Әхмәтҗан. Мин дә күп акча тотарга риза түгел!

Хәмидә. Җә, җә, Мәхүпҗамал абыстай, аларның сүзләренә карама, риза, риза, иртәгә алардан да вәгъдә бүләге китерерсең.

Мәхүп. Алар инде күптән хәзер, намазлык, чолгауларны күптән хәзерләп куйганнар. Ходай боерса, вәгъдә бирнәләрен дә бик һәйбәт итәчәкләр, сиңа күлмәклек җон, кияүгә...

Хәмидә *(урыныннан сикереп торып.)* Нәрсә дисең?

Мәхүп. Сиңа күлмәклек җон, кияүгә...

Хәмидә. Күлмәклек асыл диген!

Мәхүп. Ялган булмасын, миңа күлмәклек җон дип әйттеләр. Хәтта, ялгыш булмасын дип, кайтарып-кайтарып сорадым, җон, диде.

Хәмидә *(авызын бүлтәйтеп, бик ачу белән бер торып, бер утырып).* Ишкәннәр икән, вәгъдә бүләгендә үк алай итеп мыскыл иткәч, башкаларында алар тагын да изәрләр. Җон бирнә киярлек булгач, Хисами кызын алалар иде, ди. Аның карачкы шикелле кызын алмасам, дөньяда кыз беткән иде, ди.

Габдуллаҗан *(үзалдына).* Аллага шөкер, әни үзе дә кызның күркәм сыйфатларын саный башлады.

Әхмәтҗан *(үзалдына).* Ходайга шөкер, кыйммәтле туйдан котылам ахры.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итә).* Аның тилиграм баганасы шикелле озын, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы кызын алмасам да, дөньяда киленсез калмам әле.

Габдуллаҗан *(үзалдына кулларын уып, шатланып).* Шөкер, эшләр уңайлана.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Аның селте көянтәсе шикелле сыгылып төшкән кызына җефәк шикелле улымны әрәм итәмме соң мин!

Бәдриҗамал *(ишектән кереп).* Мәхүп абыстай, сезне Хисами байларның асравы чакыра, монда гына чыгып керсен әле, ди. *(Мәхүп чыгып китә.)*

АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр, соңра Мәхүп.

Хәмидә *(сүзендә дәвам итеп).* Бай дигәч тә, бик исләре киткән, аның кеше чыкмаган өрәк шикелле кызын, бүләге дә булмагач, шайтаным ала. Улым, син бер дә хафаланма! Алла боерса, менә дигән кыз алырбыз.

Габдуллаҗан *(Хәмидә янына килеп).* Юк, әни, бер дә хафаланмыйм, бәлки булмый калганына шатланам гына...

Әхмәтҗан *(Хәмидәнең аркасыннан сөеп).* Хатын, акча күп чыкмаганлыгы өчен мин дә бик шатланам.

Хәмидә. Шулай булмый ни, аларның колга шикелле озын, шадра, төссез, ямьсез, кыек авызлы, кәкре аяклы

кызларына, бүләге дә булмагач, эт барсынмыни? Аңгыралар, эш башламас борын ук үзләренең мәнсезлекләрен белдерделәр, мәнсезләр, эштән чыккан шыр тилеләр!

Мәхүп *(ишектән ашыгып кереп)*. Менә син, ә, харап булдым бит, ялгышлык белән харап булдым бит? Әсмабикә, үзенең каушавыннан зиһеннәре таралып, сиңа күлмәклек җон дип сөйләп җибәргән. Җон түгел икән, чачагы-чугы белән күлмәклек ука тирәкле асыл икән. Әле асравын шуны әйтергә җибәргән. Кодагый, зинһар, гаеп итә күрмәсен, үземнең зиһенсезлегем белән бик зур оятлы булдым, кодагый, зинһар, үпкәли күрмәсен, дигән.

Әхмәтҗан *(кулларын җилпеп)*. Очты инде ул кодагый булулар. *(Көлә.)*

Габдуллаҗан *(нос ясап, мыскыл итеп)*. Үтүт инде хәзер кодагый булырга! *(Көлә.)*

Хәмидә *(уынгалап)*. Менә син, ә, мин дә ашыгычлыгым белән ачуланып ташладым, оятлы булдым, оятлы булдым. *(Ялынганрак кыяфәттә.)* Карагыз әле, атасы, улым, әле дә эш узмаган бит, мин ул сүзләрне ачуымнан гына ялгыш сөйләп җибәрдем. Кодагый — бик мәнле, бик һәйбәт кеше, эшнең җаен бик белә торган кеше, кыз да ямьсез түгел, бик сөйкемле кыз...

Габдуллаҗан. Кодагыең эшнең җаен белсә, мин дә бик яхшы белдем инде. Син, үзеңә асыл бирнәләр килсен өчен, минем башымны колга, тилиграм баганасы, белмим, тагын әллә нәрсә шикелле озын, ямьсез, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы бер кызга бәйләмәкче булган икәнсең. Юк инде, хәзер торып тор, ул эшләр бик тиз генә әләкмәс! Хуш, сау булыгыз! *(Ишекне бик каты ябып чыгып китә.)*

Әхмәтҗан. Рәхмәт, анасы, рәхмәт, мине дә күп акча тотудан коткардың. *(Чыгып китә.)*

Хәмидә *(югары карап, елаган тавыш белән)*. Әй Раббем, нинди гөнаһ шомлыкларым булды икән? Тәмам булган эшне тараттым.

Мәхүп *(халыкка карап, елаган тавыш белән)*. Монда иң бәхетсез кеше мин! *(Хәмидәне төртеп күрсәтеп.)* Шушы юләрнең тиктормас теле аркасында ничә күлмәкләрдән, иллеалтмыш тәңкә сәдака-хәер акчаларыннан коры калдым.

Пәрдә төшә.

1908 ел

Биремнәр

1. «Бүләк өчен» комедиясендә дә «Беренче театр» пьесасындагы сатира-юмор алымнары кабатлана. Шуны исбат итегез.
2. Хәмидә гаиләсе белән Хәмзә бай гаиләсен чагыштырыгыз. Андагы кешеләрнең уртак сыйфатларын күрсәтегез.

Йомгак ясыйк

Галиәсгар Камалның ике әсәрен өйрәнгәннән соң, мондый нәтиҗәгә килә алабыз:

1. Галиәсгар Камал үткен фикерле әдип булган. Комедияләре өчен кызыклы сюжетлар уйлап тапкан. Театр куйдырмас өчен җан атып йөргән Хәмзә байның хәтта үз балалары да качып театрга киткәннәр. Ямьсез кызны ярсый-ярсый мактаган Хәмидә кечкенә генә бер вакыйгадан соң кызны пыр туздырып яманлый һәм шул ук кызны кабат мактарга керешә. Шундый кызыклы сюжет эченә әдип хисапсыз көлкеле эпизодлар чәчеп чыга.

«Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» комедияләрендә дә ул диалогларның һәрберсен диярлек фикерле каршылыклар белән бизәгән. Хәтта «Бәхетсез егет» исемле драмасында да кызыклы вакыйгаларны сюжет эченә табигый рәвештә кертеп җибәргән.

2. Галиәсгар Камал үткен күзле әдип булган. Үзе яшәгән заманда татарларның төп гаебен күреп алган. Кешеләрне ахмак бәндәләр әрсезлегенә каршы тора алмауда, мескенлектә, куркаклыкта гаепләгән. Заманга хас әрсезләрне, куркакларны күреп алган. Аларны көлкегә калдырып сурәтләгән. Шуның белән бергә, әдип бу кешеләрнең үзләренә генә хас холыкларын да күргән. Аның персонажлары үзләренчә әрсезләр, үзләренчә наданнар һәм үзләренчә мескеннәр.

3. Галиәсгар Камал да, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов кебек, татарларның артталыгына чын күңелдән борчылган. Бу артталыкның сәбәпләрен эзләгән. Төп сәбәпне халыкның ваемсызлыгында күргән.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3

КАБАТЛАУ 5

Җанлы кояшлар. *Хәсән Туфан* 6
Егетләре Казан артының. *Сибгат Хәким* 7
Малайлыкта кунакта. *Ибраһим Гази* 8
Шүрәле гаеплеме? *Марсель Галиев* 11
Дуслык. *Резеда Вәлиева* 12

ХАЛЫК ИҖАТЫ ЖАНРЛАРЫ 13

Әйтемнәр 13
Мәкальләр 15
Халык җырлары 17
Мөнәҗәтләр 19
Анага бала — күкрәк сагышы 20
Ялгыз ана 21
Сагыну хәле 21
Бәетләр 22
Гайшә матур белән гашыйк Камил бәете 22
Тукай бәете 23
Әкиятләр 25
Көнкүреш әкиятләре 26
Мактанчык бай 26
Саран белән Юмарт 28
Хайваннар турындагы әкиятләр 31
Әтәч патша 31
Кыңгыраулы тычкан баласы 32
Тылсымлы әкиятләр 34
Унөч 34
Алтын алма 38

ӘДӘБИ ЖАНРЛАР 47

Мәсәлләр 47
Ике эт. *Габдулла Тукай* 47
Мәрхәмәтле Төлке. *Габдулла Тукай* 49
Хикәяләр 50
Ул үксез бала шул! *Фатих Әмирхан* 51
Корбан. *Фатих Әмирхан* 54

Балачак әсирлегендә. *Марсель Галиев* 58
Мөстәкыйм карт йокысы. *Мирсәй Әмир* 64
Сөенечле хәбәр. *Роза Хафизова* 67
Безнең ишегалдында. *Ләбибә Ихсанова* 74
Лирик шигырьләр 77
Милли моңнар. *Габдулла Тукай* 77
Кояшта тудың микән. *Хәсән Туфан* 78
Давыл. *Хәсән Туфан* 78
Пар ат. *Габдулла Тукай* 81
Драмалар 83
Ак калфак. *Мирхәйдәр Фәйзи* 85
Повестьлар 105
Агыйдел. *Мирсәй Әмир* 106

ЯЗУЧЫ ИҖАТЫНА АНАЛИЗ 131

Сибгат Хәким 133
Шигырь ничек туа? 136
Көз 138
Давыл чәчәкләре 139
Бу кырлар, бу үзәннәрдә.......... 140
Фазыл чишмәсе 141

Шәехзадә Бабич 142
Дөньяга 144
Бәхетсез мин 144
Хәсрәт сагызы 145
Кышкы юл 145
Язгы җыр 145

Шәриф Камал 147
Әүвәл-әүвәл заманда 148
Акчарлаклар 151

Фатих Әмирхан 170
Хәят 172

Галимҗан Ибраһимов 197
Уты сүнгән җәһәннәм 199
Карт ялчы 206

Галиәсгар Камал 222
Беренче театр 224
Бүләк өчен 241

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник по татарской литературе для 7 класса татарской средней общеобразовательной школы

Издание третье, переработанное

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныфы өчен дәреслек

Яңадан эшләнгән өченче басма

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ф. К. Гумерова*
Компьютерда биткә салучысы *Г. Р. Галимҗанова*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, Г. Г. Мөхәммәтҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.08.2006.
Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 16,0 + форз. 0,25.
Нәшер-хисап табагы 14,56 + форз. 0,39.
Тиражы 4600 д. Заказ К6/211.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

КОНФЛИКТ